МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№ 1

2012 ЕЛ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ

БОЛГАР

И ТАШ, СӨЙЛӘ...

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ
2012 ЕЛНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАСЫ ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТҮ ТУРЫНДА

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең тарихи һәм рухи традицияләрен, мәдәниятләрен һәм телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләренә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү, мәдәни мирас объектларын торгызу, реставрацияләү һәм популярлаштыруга ярдәм итү максатларында карар бирәм:

1. 2012 елны Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бер ай вакыт эчендә 2012 елда Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елын уздыру буенча, аларны үткәрү вакытын, җаваплы башкаручыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, төп чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, "Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенә, республика һәм урындагы массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н.МИҢНЕХАНОВ
Казан, Кремль
2012 ел, 24 гыйнвар

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№ 1

Эчтәлек

**Оештыручы
иҗат төркеме**

Бу санда авторларның, Д.Бунтуков һәм А.Эшкининның шәхси архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Журнал «Татмедиа» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Заказ №6943.
Тираж — 2000 данә.
Формат 60 х 90 $^1/_8$
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 12.05.2012

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

2 Чорлар кисешкәндә...
3 Мирас — халык хәтере. *Әхмәт Мазһаров*
6 **ТАРИХ.** Татарны, бер-ике башка югары булмаса, танымыйлар. *Индус Таһиров*
8 Алтын Урдада Ислам дине кабул ителү мәсьәләсе. *Дамир Исхаков*
13 Киләчәккә илтүче мирас. *Разил Вәлиев*
14 Сызлаулы хәтерне яңарту. *Зиннур Мансуров*
16 **МИЛЛИ БАСМА.** Без булганбыз, бар һәм булачакбыз! *Равил Фәйзуллин*
21 Тарих таңы... *Гамил Афзал*
22 Россиядә төрки-татар басмасының беренче үрнәге хакында. *Миркасыйм Госманов*
34 Болгарда төн. *Равил Фәйзуллин*
Шәһре Болгарда. *Роберт Миңнуллин*
36 **ӘДӘБИЯТ.** Гомәр Дашкин һәм аның шигъри иҗаты. *Хатыйп Миңнегулов*
46 Уйгану вә яңалык тарихы. *Ризаэтдин Фәхретдин*
53 Бөек шәхесләр мәхәббәте. *Азат Ахунов*
57 Борынгы Болгарда. *Разил Вәлиев*
58 Әхмәтҗан Бикмиевнең татар авыл хуҗалыгы әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге. *Ленар Гобәйдуллин*
62 Әмирхан Еникинең прототиплар дөньясы яки чынбарлыктагыча гадәти каһарманнар. *Әлфия Мотыйгуллина*
66 Шәһре Болгар. *Ркаил Зәйдулла*
Болгарда. *Газинур Морат*
68 **ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ.** Рухи мирасыбызны саклауга кагылган кайбер фикерләр. *Фәнзилә Җәүһәрова*
74 **ХУШЛАШУ**
76 Туфан Миңнуллин: «Кеше белән язылмаган законнар идарә итәргә тиеш, аның эчке дөньясы, аның рухы...»
78 Туфан Миңнуллинны озату мәрәсимендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе *ИлфакИбраһимовның* ясаган чыгышы
80 **ЧАЛ ГАСЫРЛАР АВАЗЫ.** И таш, сөйлә... *Ирек Һадиев, Раиф Мәрданов*
88 Скифлар — ерак бабайлар... *Мөхәммәт Мирза*
90 **МӨНБӘР.** Кол Шәриф мәчете — яңарыш символы. *Динара Әхмәтова*
95 Болгар. *Әхмәт Рәшит*

ЧОРЛАР КИСЕШКӘНДӘ...

Тамырлары ерак гасырларга барып тоташкан бөек татар халкының бәяләп бетергесез бай тарихи үткәне, тирән эчтәлекле әдәбияты, мәдәни җәүһәрләре — милли мирасы бар. Борынгы бабаларыбыз заманында үз ата-бабаларыннан килгән әлеге хәзинәләрне бөртекләп туплаган, саклаган, киләчәк буынга тапшырган. Билгеле сәбәпләр аркасында татарның хак үткәнен чагылдырган аерым сәхифәләр тарих тәгәрмәченнән төшеп калган. Инде шул ак тапларны киметү, ата-бабалар эшен дәвам итү безгә — хәзерге чор вәкилләренә йөкләнә. Көчле фәнни егәре, алыштыргысыз галим-галимәләре, әдипләре һәм кабатланмас шәхесләре булган җөмһүриятебездә, гомумән, татар галәмендә бу эшне эзлекле рәвештә башкарып, милли мирасыбызны киң җәмәгатьчелеккә кайтару, Европа һәм дөнья халыклары даирәсендә татарның тоткан урынын билгеләү катлаулы да, мактаулы да гамәл. Шуңа күрә сезне, мөхтәрәм милләттәшләребез, безнең белән бергә булырга, әлеге эшчәнлектә актив катнашырга чакырабыз.

Журналда ерак гасырлардан сакланып килгән тарихи материаллар һәм документлар, дини-иҗтимагый характердагы хезмәтләр, борынгы һәм хәзерге заман әдәбияты үрнәкләре, сәнгать әсәрләренә бәйле мәгълүматлар урын алачак.

Әйе, һәр узган елыбыз, көнебез, сәгатебез, хәтта минут-секундыбыз үткәнгә, тарихка күчә, безнең мирасыбызга әверелә. Аның нинди бәһагә ия булуын бүген аңламасак та, еллар үткән саен, кыйммәтенә төшенербез, киләчәк буыннар без калдырган мирасны өйрәнер. Бу — табигый күренеш.

Без — китаплы, белемле, бай мираслы халык. Төрки җәмәгатьчелек кенә түгел, әлеге хакыйкатьне инде Европа, дөнья халыклары да таный. Иксез-чиксез Җир шарына сибелеп яшәүче бөек татар улкызлары милләтнең йөз аклыгы булып калсын, үз тамырларын онытмасын иде. Мирасыбызны бөртекләп туплау, саклау һәм киләчәккә илтеп җиткерү безнең максат булуын һәрчак истә тотыйк.

Ак юл сиңа, милли басмабыз!

Оештыручы иҗат төркеме

МИРАС – ХАЛЫК ХӘТЕРЕ

Әхмәт Мазьаров,
Татарстан Фәннәр академиясе президенты

Адәм баласын хәтер яшәтә, ди халык. Хәтерен җуйганның бүгенгесе — мәгънәсез, үткәне — караңгы, киләчәге билгесез була. Мирас исә, халык хәтере, милләт хәтере. Мирасын югалтканнарның тарихы юк, мәдәнияте юк, ерактан килгән барыр юлы юк. Шуңа да һәр халык үз мирасын, үз кыйбласын, үз рухын сакларга, киләчәк буыннарга тапшырырга омтыла.

Без, татарлар — тарихлы һәм мираслы халык, дип мактанырга яратабыз. Ләкин мирас халык күз алдында һәм күңелендә, өстәл түрендә, китап киштәсендә булганда гына яши. Йозакларга бикле, чит җирләрдә яшерен икән ул, хәтер кебек үк, көтмәгәндә югала. Шуңа күрә кайгыртып торганда, халыкка кайтарганда, саклаганда, өйрәнгәндә-тикшергәндә, бәяләгәндә

генә мирас бар! Тарихи-мәдәни хәтерен барлаган һәм өйрәнгән, белгән һәм бәһаләгән халык кына мираслы була!

2012 ел мәдәни-тарихи мирас елы дип игълан ителгән вакытта, мирасны барлау һәм кайтару максаты куйган «Чын Мирас» журналының кабат мәйданга чыгуы — бик кирәкле һәм мөһим адым. Без бу журналның, чын мәгънәсендә, фәнни, әдәби-мәдәни, тарихи чыганакларны, аларны өйрәнгән гыйльми хезмәтләрне, тарихыбыздагы билгесез сәхифәләрне аңлатырлык вакыйга һәм фактларны укучыга җиткерә торган басма булуын телибез.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең иң көчле гуманитар институтлары — Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татар энциклопедиясе институты әдәби-мәдәни мирасны барлау һәм өйрәнү өлкәсендә искиткеч зур эш алып бара. Галимнәребез тырышлыгы белән соңгы егерме ел эчендә генә дә халкыбызга никадәр исемнәр, никадәр хезмәтләр, никадәр яңа, билгесез кала килгән мәгълүматлар кайтты! Безнең галимнәр тарафыннан 15 томлык китап булып әзерләнеп дөнья күргән Гаяз Исхакый иҗатын, Шиһабетдин Мәрҗани, Йосыф Акчура, Муса Бигиев, Риза Фәхретдин, Габдерәхим Утыз-Имәни, Габденнасыйр Курсави, Зыя Камали һ.б. бик күп мөхтәрәм шәхесләребезнең мирасын телгә алу да бу эшнең колачын, тирәнлеген күрсәтеп тора. Тарихыбыздагы Болгар чорына, Алтын Урда заманына, аннан соңгы гасырларга карашның үзгәрүе дә шушы эшчәнлеккә барып тоташа. Без бүген Евразия тарихында үз урыныбызны билгелибез, бик ерак, борынгы тарихыбызның тамырларын барлау белән шөгыльләнәбез. Галимнәрнең ачышлары, табышлары халыкка, бүгенге һәм килер буыннарга кирәк, димәк, аларны җиткерер журнал, трибуна булу мөһим. Озын гомерле булсын!

«...Бу якты көннәргә китергән
Тарихның юллары чытырман».
Гамил Афзал

Тарих

ТАТАРНЫ, БЕР-ИКЕ БАШКА ЮГАРЫ БУЛМАСА, ТАНЫМЫЙЛАР

Индус Таһиров,
тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы

Тарихи мирас, аны саклау турында сөйлибез икән, без һич кенә дә беркатлы караш та булырга тиеш түгелбез. Мәсәлән, кадимчелек һәм җәдитчелек мәсьәләсенә карата кайберәүләр беркатлы гына фикер йөртә. Берсен мактый, икенчесен сүгә. Безнең максат — кемдер ягында булу түгел, ә объективлыкны саклау. Кадимчелекне ни өчен сүгәргә ярамый? Чөнки бу чор 1552 елдан соң камалышта калган милләтебезне, Ислам динебезне аякка бастыруда, коткаруда алыштыргысыз вазифа башкара. Милләт өчен кичәге биеклектән түбәнлеккә төшү җиңел булмый. Аны саклап калу, үз эчендә генә бикләнеп ятмыйча, тышкы дөньяга чыгу мөмкинлеге туа.

Ә көрәш аңлашыла. Ике карашны яклаучылар да адәм балалары бит, җәдитчеләр кадимчеләрдән үсеп чыга. Ләкин җәмгыять, кеше үзгәргән инде. Бары тик кадими караш та гына яшәп булмый. Шулай булса, халкыбыз Европа, рус культурасы эчендә эреп беткән булыр иде. Ислам дине дә шул катлаулы чорда халык өчен зур таяныч була.

Татарлар — Россиянең иң укымышлы халкы. Камалышта калып, үз дөньяла-

рына «бикләнгәч», мәктәп системасы барлыкка килә. Гади халык та гарәп графикасында укый-яза белә. XIX-XX гасырлар чигендәге кискен үзгәрешләр дә шуның белән аңлатыла: татар укый-яза белә, китапка күнеккән, үз басмаханәләре эшли һ.б. Татар солдатлары, башка милләтләргә караганда, рус графикасына да тизрәк өйрәнә торган була. Халкыбыз үзенең рухы нык икәнен күрсәтә, рухи яктан берәүгә дә буйсынмый, буйсыну бары сәяси якка карый.

Татарстанда 2012 ел тарихи-мәдәни мирас елы дип игълан ителде. Бу унике ай эчендә без күпкә җитешергә тиешбез. Әле күптән түгел генә Г.Ибраһимовны искә алдык, зур халыкара конференция уздырылды, Г.Тукай укулары үтте. Озакламый М.Солтангалиевкә багышланган чаралар үткәрәчәкбез. Әлеге халыкара чара кысаларында әдипкә истәлек тактасы, барельеф кую планлаштырыла. Кайбер чаралар Мәскәүдә дә узачак.

М.Солтангалиев — дөньяга таныш фигура. Заманында марксизм-ленинизм тәгълиматларын тәнкыйтьләп чыга, 1919 елда ук дөньякүләм революциянең булмаячагын әйтә, Ленинның карашлары белән килешми. Шәрык уяначак, киләчәк Көнбатышта түгел, ә Шәрыкта, ди. Без Кытай дәүләте мисалында гына да моны яхшы аңлыйбыз. М.Солтангалиев Шәрыкның көчәеп китүе Көнбатыш өчен бер дә кулай булмаячагын да билгеләп үтә, Һиндстан, Төркия турында үз фикерләре белән уртаклаша. Революцияне дә ул, социалистик булудан бигрәк, милли азатлык өчен көрәш буларак кабул итә. 1924 елда үзенең тәгълиматларын махсус тезислар рәвешендә туплап чыгара. Арадан берсе болай яңгырый: әгәр дә панрусистлар Россиянең элекке бөеклеген торгызырга тырышсалар, бу — булмый торган эш. Әлеге сәясәт дәвам итә икән, СССР рәвешендә аякка баскан илнең гомере озын булмаячак.

Шуңа да М.Солтангалиевне дөньякүләм таныйлар, «идеолог третьего мира», дип атап йөртәләр. Ул — безнең милләт өчен Тукай кебек бөек шәхес.

В.В.Путин программасында милли мәсьәләләргә бәйле фикерләр дә бар. Без алар белән килешәбезме? Ризамы, түгелме? Шулай ук бу истәлекле ел кысаларында чара уздыру планлаштырыла. Татарның дөньядагы ролен күрсәтергә, башка милләтләргә аңлатырга кирәк. Гасырлардан-гасырларга күпме халык аның ярдәмен тоеп, файдасын күреп яшәгән, тик болар күләгәдә кала. Рус-татар мөнәсәбәтләре дә аерым өйрәнелергә тиеш.

Татарның хак тарихын булдыру юнәлешендә дә эшләр алып барыла. Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында зур эшләр башкарыла. Фәнни томлыклар төзелә. Алар — җыеп бирелгән тарих. Кыйммәтләре дә шуның белән аңлатыла. Әйе, хезмәтләр күбәя, ләкин объектив тарих дигән әйбернең максатчан төшенчә булуын онытырга ярамый. Ныклы дәлилләр булдырмыйча, бер тарихи күренешкә дә нокта куеп булмый. Ә менә хезмәтләрне халыкның укуына килгәндә, мәсьәлә сораулар уята. Зур күләмле булмаган, аңлаешлы китаплар кирәк. Аеруча балалар өчен. Рус халкының «Плач Ярославны» әсәре бар. Мәсәлән, безнең «Сөембикәнең Казан белән саубуллашуы»н аерым тарихи-мәгълүмати китапчык итеп биреп булыр иде. Гади халык өчен укылырдай хезмәтләр кирәк.

Мәктәп системасыннан хак тарихны кысрыклап чыгарырга тырышалар. Күптән түгел Чувашиянең Комсомол районы Тукай авылында булырга туры килде. Биредә балалар мәктәпкә мәдрәсә аша үтеп керә. Беренче сыйныфка килә, мәктәптә урын аз. Шуннан ата-ана баласын мәдрәсәгә бирә. Монда ул дин тарихын да күпмедер үзләштерә. Күрәбез ки, дин әһелләре мәктәп балалары белән кече яшьтән башлап эшләргә, мәктәп бирә алмаганны бирергә тиеш. Мөселманлыкны, татарлыкны ныгыту, аерым шартларга

каршылык күрсәтү кирәк. Мисал өчен, чит төбәкләрдә татар гимназияләренә ихтыяҗ зур булуны искәртү мөһим. Саратов өлкәсендә бер урынга — алты кеше. Билгеле, башка милләт вәкилләре дә үз балаларын монда укырга бирергә омтыла, сыйфатны күрә. Бездә дә сыйфат югары булсын иде. Татарны, бер-ике башка югары булмаса, танымыйлар. Ә без чын татар проблемасы, дини тәрбия белән шөгыльләнәсе урынга, юк нәрсәләрне кузгатабыз. Әйе, барсны кая кую, Кол Шәриф мәчетен бүлешү — болар да безнең чор мәсьәләләре, тик эш анда түгел, ничек саклау, үстерү, камилләштерү беренче урынга чыгарга тиеш. Шул ук Бөек Болгарның татарлыкка керткән өлешен билгеләү мөһим. Бөтенесе безнең тарих, берсен дә башкаларга бирергә теләмибез. Борынгы чыганакларны, аеруча да Кытайныкын өйрәнергә кирәк. Тарихны аз беләбез.

Бүген фәнебездә әле һаман татарның килеп чыгышына карата бәхәсле карашлар яши. Без чыганакларга мохтаҗ, башлыча чит илләрдә — Төркия, Гарәп илләре, бигрәк тә Кытайда сакланган материалларга таянырга тиешбез. Татарлар берничә төрки компоненттан тора. Безнең тел, нигездә, кыпчак теле. Әйе, Болгар безгә күп нәрсә бирде, бу үсеш чоры булды. Ләкин без болгар түгел, без борынгы татар да түгел, без — бүгенге татар. Быелгы ел барча эшләребезгә дәрт-дәрман өстәсен иде.

Соңгы вакытларда Татарстанда безнең бабаларыбызның мөселман өммәтенә кушылу тарихын күбрәк Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителү белән бәйләү күзәтелә. Әмма чынбарлыкта татарларның этник бабалары бер тамырдан гына түгел һәм алар ислам динен берничә тапкыр үзләштергәннәр. Болгарлардан тыш, мәсәлән, Хәрәзем тирәсендә яшәгән кыпчакларның (кимакларның) X гасырда мөселманлашуы билгеле. Бу төркемнәр исә соңрак чорда Идел буена да үтеп кергәннәр (безнең фикер буенча, Биләр шәһәрлеге янындагы Хуҗалар тавында күмелгән Мәлүм хуҗа — аның кабере шунда, кыпчаклар белән бәйле). Ә инде Алтын Урда дәүләтендә Үзбәк хан дәверендә ислам динен нәкъ менә «татарлар» дип йөртелгән төп сәяси көч вәкилләре тарафыннан кабул итү тарихта яхшы билгеле. Шуңа күрә дә соңгы мәсьәләне ныклап өйрәнгән кайбер чит ил галимнәре, әйтик, күренекле Америка тарихчысы Девин Де Виз, хәзерге татарларның исламга бәйле тамырларын Алтын Урдадан эзләргә кирәк дип яза. Ләкин бу турыда Татарстанда әллә ни күп сөйләргә яратмыйлар. Хәлбуки, шушы бөек татар дәүләтенең элитасы тарафыннан ислам динен һиҗри белән 712 елны кабул ителүен истә тотсак, бу вакыйгага инде быел ук җәй ахырында 700 ел тулу мөмкинлеге бар. Әйтелгән мәсьәләдә чыганакларга бәйле рәвештә кайбер билгесезлекләр булса да, татар җәмәгатьчелеге күрсәтелгән әһәмиятле тарихи датаны игътибардан читтә калдыра алмый һәм тиеш тә түгел. Шулай ук татар халкында таралган ислам диненең төп традицион үзенчәлекләре Алтын Урда чорындагы исламга барып тоташуын исәпкә алып та. Шушы уңайдан без Алтын Урданың исламлашуына багышланган вакыйгаларны һәм аларны өйрәнүнең кайбер проблемаларын яктыртып китүне кирәк дип таптык.

АЛТЫН УРДАДА ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

Дамир Исхаков,
тарих фәннәре докторы, профессор,
Россия Табигый фәннәр академиясе академигы

Башлап шуны әйтергә кирәк: үз вакытында күренекле Шәрык тарихы буенча белгеч, Россия ватандашы В.В.Бартольд Җучи олысында, ягъни, Алтын Урдада, ислам диненең җиңеп чыгуын «күбрәк Идел буе болгарлары йогынтысы» белән түгел, ә Хәрәзем һәм Урта Азия төркиләре белән бәйләүне кулайрак күргән иде. Һәм шушы фикерне дәлилләү өчен, ул Беркә ханның (1257-1266) ислам динен кабул итүендә Урта Азия шәехләренең ролен дә күрсәткән иде. Инде бүген бу фикерне тирәнрәк тә нигезләргә була. Мәсәлән, Чыңгыз ханның улы Җучи — Алтын Урдага нигез салучы шәхес. Ул мөселманнар белән бик иртә контактка керә һәм кайбер чыганаклар буенча үзенең улы Беркәне мөселман хатынына тәрбиягә бирә, аңа «мөселман сөтен» имезергә боера (Джудджани). Ә ул бераз үскәч, ана белем бирү өчен, мөселман имамнары чакыртыла һәм Беркәгә Коръән укытыла. Үсеп җиткән Беркә мөселманга әйләнә һәм аның карамагына мөселманнардан торган 30 меңлек гаскәр бирелә. Исламны Беркә генә түгел, аның хатыны Чәчәк хатын һәм туганнарының бер өлеше дә кабул итә. Бу вакыйгалар Кубравийа тәрикате тарафдары Сәйф-ед-Дин Әл-Бохарзи катнашында бара.

Гомумән, монголлар Урта Азияне яулап ала башлагач, андагы кайбер шәехләр һәм аларның тарафдарлары монгол-татарлар ягына чыгып, аларның ышанычларын бик тиз казана. Үз чиратында, аларның үз-үзләрен шушы рәвешчә тотуларының геосәяси сәбәпләре була: Багдад хәлифе белән Хәрәзем шаһлары арасында бу чорда бик нык дошманлык булу сәбәпле (көрәш Иран җирләре өчен барган), хәлиф кушуы буенча, шәехләрнең бер өлеше, монголлар ягына чыгып, гарәпләрнең көндәшләре — Хәрәзем шаһла-

рының дәүләтләрен җимерергә ярдәм итәләр. Булган мәгълүматларга караганда, бу шәехләр арасында Әхмәт Ясәви тарафдарлары төп урынны тоткан. Шуңа күрә, болай да зур-зур төбәкләрендә мөселманнар яшәгән Алтын Урдада (Урта Азиядә, Болгар олысында, Төньяк Кавказның кайбер районнарында) Беркә хан заманында ук ислам йогынтысы көчәя башлый.

Ләкин бу әле яңа дәүләттә ислам тарафдарлары XIII йөздә үк җиңеп чыкканнар дигән сүз түгел, чөнки монгол-татарлар арасында иске дин (мәҗүсилек белән бәйле шаманлык) белән бергә «уйгырлар дине», ягъни буддизм көчәя башлый. Шулай да ислам диненең йогынтысы ил эчендә көннән-көн арта бара. Әйтик, күп кенә гарәп чыганаклары Алтын Урда тәхетенә 1280 елны утырган Туда-Менгуның 1283-1284 елларны ислам динен кабул итүе турында язалар. Инде Беркә хан дәвереннән үк ислам дине тарафдарлары белән башка дин тотучы татар-монгол аристократиясе арасында каршылыклар көчәя башлый — бу турыда Токта хан (1290-1312) белән атаклы Ногайның көрәше вакытында соңгысының ислам диненә таянырга тырышуы да сөйли. Әмма Токта хан да гел «потларга табынып, уйгырларны, ягъни ламаларны һәм сихерчеләрне яратып, аларга ихтирам күрсәтеп кенә» яшәмәгән, ахрысы. Эш шунда ки, күптән түгел табылган кайбер һиҗри белән 706 һәм 707 елларда сугылган тәңкәләр (1306-1307, 1307-1308) Токта ханның «гыйас ад-дин»(динне коткаручы) һәм «солтан ал-а'зам гыйас ад-дөнья» («дөньяны коткаручы иң бөек солтан») дигән мөселман ләкабләре бар! Ә гарәп елъязмачысы Әл-Мөфаддаль инде һиҗри белән 704 елны ук (1304-1305) бу хан турында: «Ул мөселман иде», — дип язган. Димәк, бу мәсьәлә әле тагын тикшерүне таләп итсә дә, Токта ханның XIV йөз башларында ислам динен кабул иткән булуын инкарь итеп булмый. Билгеле булганча, ул хан аннан соң тәхеткә утырган Үзбәк ханның агасы була һәм, күренә ки, инде XIV йөзнең башында ук Сарай әһелләре арасында ислам дине шактый киң таралган була. Ләкин татар-монгол элитасы әле тулаем ислам динендә булмаган, ул диннең дәүләт диненә әйләнүе Үзбәк хан (1312-1342) дәверенә туры килә. Менә шул турыда күбрәк мәгълүмат биреп китик.

Дөресен әйтик, Үзбәк ханның кайчан ислам динен кабул итүе турында анык кына бер хәбәр дә юк, ул вакыйганы төрле документаль чыганаклар 1312 елдан 1320 елга кадәр барган дип күрсәтә. Әмма аларга ныклы анализ ясап карасаң, бу тарихи датаны төгәлрәк итеп тә билгеләргә була. Түбәндә сүз шул юнәлештә барыр.

1312 елның 9 августында Токта хан, Идел елгасы буенча корабта йөзеп барганда (Сарай шәһәреннән ерак булмаган урында), кинәт кенә үлеп китә. Фарсы тарихчысы Кашани мәгълүматлары буенча, аксөякләр җыелып яңа ханны сайлау турында сөйләшү башлыйлар. Шул җыенда (корылтай булса кирәк) «Сарай әмире» дип аталган шәхес (аның исеме «Котлыг-Тимер»дип бирегә, дөресе, «Бай-Тимер» булырга тиеш) тәхеткә Токта ханның Илбасмыш исемле улын күтәрергә тәкъдим итә. Ләкин моның өчен башта Үзбәкне юкка чыгарырга кирәген әйтә (ул вакытта Үзбәк гаскәр белән башка җирләрдә була). Үзбәк тиз арада дәүләтнең башкаласына килә, анда мәҗлескә кергәндә, үзенә куркыныч янау турында кисәтү ала һәм гаскәр урнашкан җирләргә качып китә. Чыганаклардан күренгәнчә, аны үтерергә теләүчеләр Үзбәкнең ислам динен кабул итүенә каршы чыгучылар була. Кашани хәбәренчә, Үзбәк, гаскәр белән кире кайтып, бик күп Чыңгызи солтаннарны үтереп (араларында Токта ханның уллары да була), үзе тәхеткә утыра. Икенче бер фарсы елъязмачысы Хафиз-и Абру күрсәтүенчә, Үзбәк хан «Токта ханның улы белән бергә Чыңгыз хан ыруыннан булган 120 солтанны үтерә». Башка бер гарәп елъязмачысы сөйләвенчә, Үзбәк хан аксөяк

татарлар белән бергә «күпсанлы уйгырларны, ягъни, лама һәм сихерчеләрне үтертә, ислам динен тотуны игълан итә» (Шәех әл-Бирзали). Бу вакыйгаларны тасвирлаганда, әле Үзбәк ханның ислам динен кабул итүенең төгәл елы күренми, ләкин каршылыкларның дин тирәсендә барганлыгын ачык билгеләп була.

Әйтик, фарсы тарихчылары Кашани һәм Хафиз-и Абру тасвирлаганча, Үзбәк тәхеткә килгәч, бер өлеш әмирләр аңа болай диләр: «Әй падишаһ, син бит безнең буйсынуны телисең, синең безнең динебездә һәм ышануыбызда ни эшең бар? Һәм ни өчен без, Чыңгыз ханнан калган ясактан (ясадан) һәм тордан (ёсуннан) баш тартып, гарәпләрнең иске диннәрен (шәригатьне) кабул итәргә тиеш?» Димәк, Алтын Урдада барган ике төркем арасындагы көрәш идеология өлкәсендә булган. Бу көрәштә Үзбәк ханга үзенең ныклы позициясен белдерү кирәк була. Ул моны эшли дә. Ләкин чынбарлыкта Үзбәкнең ислам динен кабул итүе бераз башкачарак барганга охшый.

Гарәп тарихчысы ибн-Дукмак күрсәткәнчә, «Токта хан дәверендә дәүләт эшләре белән идарә иткән Котлыг-Тимер *(бәкләр бәге — Д.И.)* [хан үлгәннән соң] Үзбәкнең атасы, Тогрылдҗаның хатыны булган (ягъни, Токта ханга кияүгә чыкканчы) өлкән хатынга *(исеме — Баялун булган — Д.И.)* мөрәҗәгать итеп, тәхеткә аны күтәрү турында килешкән… Аннан алда ук тәхеткә утыргач, мөселманлык кабул итү һәм ислам дине юлы буенча бару турында вәгъдә ала». Күренә ки, Үзбәк тәхеткә утырганчы ук ислам дине тарафдарлары тарафыннан чорнап алынган була. Бу юкка гына түгел, кайбер бик ачык булмаган чыганаклардагы язмалардан күренгәнчә, Үзбәк солтанның тәхеткә килгәнче гаскәр белән Хәрәзем олысында яшәгән булуы мөмкин. Эш шунда ки, Кубравийа тәрикате шәехе ‘Ала ‘ад-Давлах Симани мәгълүматлары буенча, һиҗри белән 710 ел тирәсендә (1310-1311) ислам тарафдары булган исеме билгесез «Хәрәзем әмире» белән бер солтан (Үзбәк түгел дип уйлыйбыз) арасында дошманлык булуы билгеле. Ә бу әмир Токта хан тарафыннан инде һиҗри белән 709 елны ук (1309-1310) армия белән җитәкчелек итәргә билгеләнгән Котлыг-Тимер булса кирәк. Кайбер башка чыганаклардан күренгәнчә, Токта ханның варисы итеп билгеләнгән Илбасмыш нәкъ менә Хәрәземдә үтерелә дә. Бу очракта фетнә коручыларны Котлыг-Тимер белән бәйләү дөрес булыр. Иң кызыгы шунда: бу Токта ханның варисын юк итүчеләр Хәрәземдәге мөселман шәехләре белән тыгыз бәйләнештә булганнар.

Үзбәк ханның ислам динен кабул итүе төгәл кайсы елны булган соң? Гомумиләштереп әйткәндә, бу вакыйга аның тәхеткә күтәрелүе белән бәйле булырга тиеш. Ләкин монда кайбер проблемалар бар.

Беренче чиратта, бу төрле чыганакларда күрсәтелгән вакыйганы төрле даталар белән бәйләү аркасында килеп чыга. Мәсәлән, «Шәҗәрәт әл-әтрәк» (XV гасыр уртасы) хезмәтендә Үзбәк ханның исламны кабул итүе һиҗри белән 720 елда (1320-1321) дип күрсәтелә. Әмма, безнең фикеребезчә, монда бирелгән дата дөрес түгел. Ни өчен? Беренчедән, урыс елъязмаларындагы традиция буенча Үзбәк ханның мөселманга әйләнүе («обесерменился») 6821 елга, ягъни 1313 елга карый. Икенчедән, көнчыгыш чыганакларында һәм нумизматик материалларда да без шушы елга якын даталарны очратабыз. Әйтик, Кашани елъязмасында Үзбәк ханның ислам динен кабул итүе турындагы мәгълүмат Алтын Урдадан 1313 елның 8 апрелендә (һиҗри белән 712 ел 10 зөлхиҗҗә) аннан илчеләр килүе белән бәйле контекстта килеп чыга. Илхани елъязмачылары (фарсы тарихчылары) Банаканти һәм Кашани хезмәтләрендә дә бу хәбәр 1315-1317 еллардан да соң дип билгеләнми, ягъни «Шәҗәрәт әл-әтрәктә» булган датага каршы килә.

Шушы бәхәсле ситуациядә нумиз-

матик мәгълүматлар беренче урынга чыга. Күптән түгел табылган Мухшы шәһәрендә һиҗри белән 713 елны (1313-1314) сугылган көмеш дирһәмдә Үзбәк ханның мондый титулы бар: «Аллаһы мәрхәмәте буенча гадел солтан». Ә шуңа өстәп тагын ханның ләкабе дә бирелә: «гыйас ад-дөнья вә-д-дин» «дөньяны һәм динне коткаручы/яклаучы». Бу Үзбәк ханның инде ислам динендә булуы турында сөйли түгелме соң?! Инде соңрак вакытларда сугылган тәңкәләр әлеге мәсьәләдә шөбһә калдырмый. Мәсәлән, һиҗри белән 717 елны (1317-1318) Сарай шәһәрендә сугылган Үзбәк хан исеме язылган тәңкәдә «ләә иләһә илләл-Лаһу, Мөхәммәдүр рәсүллаһу», дигән юллар бар. Аннан ике ел алдарак (һиҗри белән 715 елда) сугылган тәңкәдә дә Казанда XIX йөздә яшәгән галим М.Х.Френ язганча, ахрысы, «сөнни символикасы» китерелгән юллар язылган булган. Шулай ук Кырымда табылган мәчет порталына (ул сакланган) аның һиҗри белән 714 елны (1314-1315) «Бөек хан Үзбәк Мөхәммәд *(соңгысы ханның мөселманча исеме — Д.И.)* дәверендә» куелганлыгы уелып язылган.

Шулай итеп, Үзбәк ханның ислам диненә күчүен аның Алтын Урда тәхетенә күтәрелүе белән бер үк вакытта булган дип карау тарихи яктан дөрес булыр. Тәхеткә менү вакыйгасы исә 1312 елның августы белән 1313 елның башы арасында булган дип әйтергә урын бар. Димәк, быелның икенче яртысында безнең милли дәүләтебез булган бөек империя — Җучи Олысында (аның төгәл исеме —«Олуг Урда») ислам дине кабул ителүгә 700 ел тула.

Бу грандиоз вакыйга булган: кайбер төрки чыганаклардан күренгәнчә,«солтан Мөхәммәд Үзбәк хан үзенең иле һәм олысы белән Аллаһның мәрхәмәтенә ирешкәндә», хан белән бер үк вакытта ислам динен 70 мең кеше кабул иткән. Сүз, һичшиксез, дәүләтнең өстен катлавы, нәкъ менә татарлар турында бара. Шушы дәвердән башлап безнең бабаларыбыз — урта гасыр татар этносы вәкилләре, инде ислам дине кысаларыннан чыкмаганнар. Татар-нугайда сакланган «дин Үзбәктән калган» дигән сүзләр дә шул турыда сөйли. Сөйләнелгән вакыйгаларда суфи тәрикатьләре әһелләре бик актив катнашкан һәм бу турыда аерым язма кирәк. Ләкин шуны әйтеп китик: бу суфилар Әхмәт Ясәви тәрикате әһелләре булган һәм алар Хәрәзем якларыннан (Төркестан, Бакырган шәһәрләре тирәсеннән) килгәннәр. Казан ханлыгы дәверендә анда соңгы сәет булган Кол-Шәриф тә Үзбәк ханны исламга күндергән Әхмәд сәет (аның кушаматы — Сәет-Ата) нәселеннән була. Ләкин кабатлап әйтәбез, бу турыда аерым зур мәкалә кирәк.

Инде Үзбәк хан ислам дине кабул итеп, ул динне дәүләт диненә әйләндергәч, Алтын Урда тирәләрендә 1330 елларда булып киткән гарәп сәяхәтчесе ибн-Баттута илдә күпсанлы мәчетләр, суфи завияләре, алар каршындагы сансыз шәехләр һәм дәрвишләр турында язып калдырган. Шулай ук ул җәй айларында Бештау янында оештырылган бик зур бер бәйрәмне тасвирлаганда, Үзбәк ханның мәчеткә җомга намазына килүе турында да яза.

Билгеле, ислам динен кабул итү бер нәрсә, ә чын мөселманча яшәү — башкачарак. Шуңа күрә дә Үзбәк хан вакытында күп кенә дәүләт структураларын исламлаштыру эшләре башлана. Аның иң әһәмиятле элементларының берсе — һәрбер татар кабиләсенә аерым бер мөселман шәехен беркетеп кую була (үзенә күрә алар эчке «комиссарларга» әйләнгәннәр). Бу адымнар исә дәүләтне үзәкләштерүгә дә хезмәт иткән. Юкка гына Үзбәк хан һәм аның улы Җанибәк (1342-1357) дәверләре Алтын Урда дәүләтенең иң югары ноктасы дип саналмый.

КИЛӘЧӘККӘ ИЛТҮЧЕ МИРАС

Разил Вәлиев,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе

Һәр кешегә чын бәяне үзе исән чакта кылган игелекле гамәлләренә, үзеннән соң калдырган мирас микъдарына карап бирәләр. Кешеләргә генә түгел, халыкларга, милләтләргә дә шулай бирелә бәя.

Ә ул мирас кемнәр кулына кала, аның кадерен беләләрме, аны, әрәм-шәрәм итмичә (бәлки әле, тагын да ишәйтеп) киләсе буыннарга тапшыралармы? Монысы инде мәңгелек сорау…

Бу очракта сүз рухи мирас, бигрәк тә язма мирас турында барганга, мәсьәлә тагын да катлаулана төшә. Чөнки, матди мирастан аермалы буларак, рухи мирас банк сейфларында иясен көтеп ятмый, аны әби-бабаларыбыз сандыкларыннан, өй чормаларыннан, дөньяның биш кыйтгасындагы меңләгән архив һәм китапханәләрдән берәмтекләп эзләп табып, җыеп, галимнәребез тарафыннан җентекләп өйрәнеп, халык хәзинәсенә әверелдерәсе бар… Бу — гаҗәеп четерекле һәм милләтнең үз-үзенә һәм элгәрләренә булган мөнәсәбәтен күрсәтә торган, дәүләт дәрәҗәсендә башкарылырга тиешле олы бурыч.

Ә татарның рухи мирасы искиткеч бай. Шунысы бәхәссез — бетмәс-төкәнмәс бу байлыкны җыеп-туплап рухи хәзинәбезгә өстәгән саен, халкыбызның тарихи тамырлары ныгыячак, куәте артачак, гомере озаячак. Димәк, рухи мирасыбызны барлау һәм өйрәнү эше халкыбыз мең еллар кичергән тәрәккыятъ юлы буйлап үткәнгә һәм бик борынгы чорларга сәяхәт кылу гына түгел, ә милләтебезнең киләчәге турында кайгырту да. Кыскасы, рухи мирас ул халкыбызның үткәне белән киләчәген тоташтыручы илаһи күпер сыман.

Әлеге биниһая игелекле эш белән шөгыльләнүче галимнәребезгә, зыялы затларыбызга, бу басманы дөньяга чыгаручыларга яңа ачышлар һәм иҗади уңышлар телим.

СЫЗЛАУЛЫ ХӘТЕРНЕ ЯҢАРТУ

Зиннур Мансуров

Күтәрелеп Кече манарага,
Тарих төпкеленә төшкән бар.
...Эскәнҗәдәй кысып язмышларны,
идән булып иңгән түшәмнәр.
Хакимият илаһ кыяфәтле
ташваткычның үзен он иткән!
Болгарымның көле борынгыда
гөл булганын әллә оныткан?!
Чәрдәкләнеп беткән таштабакның
китегендә тере нур калган!
Оешмасмы җырлы тәлинкәгә?! —
Ярчыкларның кайсы янган,
кайсы урланган...
Вәхшилекне күрдем культуралы
катлам читен бераз ачтым да.
...Каендагы карга оялары
Һаман тора кояш астында...



«...Чүлләрдә салына, тауларга сарыла
Халык юлы белән китап юлы...»
Гамил Афзал

Милли басма

БЕЗ БУЛГАНБЫЗ, БАР ҺӘМ БУЛАЧАКБЫЗ!

Равил Фәйзуллин,
«Казан утлары» журналының баш мөхәррире,
Татарстанның халык шагыйре

Моннан берничә, хәтта дистә мең еллар элек үк уртак кояш астында яшәп, иҗтиһат итеп, цивилизация тарихында гамәли якты эз калдырган кавем-халыклар бар. Без дә шулар рәтенә керәбез, дип уйлыйм. Чыннан да, мең еллар элек корылган шәһәр-калаларыбыз бар. Казаныбызның мең еллыгын билгеләп үтү дә шуңа бер дәлил. Урта Идел буенда ислам дине кабул ителүенә күптән инде мең елдан ашты. Әдәбиятыбызның мең еллык тарихы бар дип горурланып әйтәбез (шунысын да ассызыклап үтү урынлы булыр: XIII гасырдан башлап һәр чорның әдәби әсәрләрен санаганда, аның тәгаен авторларын атап сөйләшә алабыз). «Кыйссаи Йосыф» әсәренең дөньяга тарала башлавына да хәтсез гасырлар. Быел татар телендә басма китап чыга башлавына 400 ел тула. Безнең өчен зур истәлекле дата. Меңнәр димәктән, моннан 6 ел элек бездә, элекке СССРда яшәгән халыклар арасында әдәби журналлардан беренче булып, «Казан утлары»ның меңенче санын чыгардык. Һәм, ниһаять, журналыбызның тыйнак санлы тагын бер юбилее килеп җитте. Безгә бу айда — 90 яшь. Мең еллык тарихы булган әдәбият өчен бу сан азрак түгелме, дияр кемдер. Әлбәттә, XX гасыр башында ук чык-



кан «Әлгасрелҗәдид», «Шура», «Аң» кебек әдәби-иҗтимагый басмаларны чишмә башы дип санасак, юбилеебыз саны йөздән күпкә артык булыр иде. Нишлисең, заманында матбугат басмаларын Совет чоры белән башлап санау гадәткә кергән. Хәер, юбилей санын йөзле түгәрәкләр белән күрергә теләү үзмаксат түгел. Журналның 90 еллык гомере дә халкыбызның иҗтимагый эстетик фикер үсеше, әдәбият-мәдәниятебезнең үткәне һәм бүгенгесе турында уйланып, киләчәкне анык күзаллап, бәйрәм хисе белән билгеләп үткәрерлек олы вакыйга.

Журнал максатны баштан ук зурдан куйган: беренче санда ук үзенең колачлы басма — аерым җөмһүрият кысаларына гына чикләнмәгән киң даирәгә юнәлтелгән басма икәнлеген язып чыккан. «Безнең юл» идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә *(сөючеләргә — Р.Ф.)* мөрәҗәгать» дигән язмада болай диелгән: «Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, «Безнең юл» журналын чыгара башладык. «Безнең юл»ның чыгуы Татар җөмһүриятенең мәркәзендә — Казанда булса да, бу мәҗмуга Россиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала». Журнал инде бер гасырга якын шушы максатны тормышка ашыру юлында нәтиҗәле эшләп килә.

Журнал 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп шрифтында, алда әйтелгәнчә, «Безнең юл» исеме белән чыккан. 1930 елдан «Безнең юл», икегә бүленеп, «Яңалиф» (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет Язучылар оешмасы органы) һәм «Атака» (Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе органы) атамалары белән басылган. 1933 елдан 1965 елга кадәр — Совет әдәбияты (Татарстан Язучылар оешмасы органы) латин, кириллица имлаларында дөнья күргән. Соңгы 43 елда журнал «Казан утлары» исеме белән чыгып килә. Заман сәясәте һәм аның шаукымнарына бәйле рәвештә, журналның оештыручылары да, структурасы да, редакциянең эш урыннары да үзгәреп, алышынып торган. Оештыручылар һәм басманың мәсләк тамгасы төрле чорда, төрле сүз тезмәләрендә бирелсәләр дә, аларда төп ике төшенчә һәрчак сакланып килгән — «әдәби һәм иҗтимагый». Димәк ул — иҗтимагый әһәмияткә ия әдәби басма дигән сүз.

Мәгърифәтле халык, киләчәккә карап, Хәтер белән яши. Безнең халыкның рухи тарихы, нигездә, басма сүздә — китапларда, әдәбиятта. Журнал — китапның үзгә бер универсаль төре бит ул. «Казан утлары» – матбугатыбыз тарихында уникаль басма: афәтле репрессия, дәһшәтле сугыш елларында илдә күп газета-журналлар ябылып, тукталып калганда да, ул — язмыш тарафыннан нәселне саклап калырга тиешле таза күзәнәкле зат кебек, сәяси катаклизмнарга бирешмәде. Күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклап, халык тарихы елъязмасы рәвешендә өзелмичә яшәвен дәвам итә алды. Бу урында чит илдә яшәүче бер мөхтәрәм укучыбызның безгә котлау рәвешендә җибәргән хатыннан берничә юл китереп узам: «Социаль-мәдәни тетрәнүләр фаҗигасен башыннан кичергәндә дә бирешмәгән, сау-сәламәт яшәргә тырышкан һәм шактый дәрәҗәдә шуңа ирешкән журналыбызның эшчәнлеген зур каһарманлык, могҗиза саныйм». Юбилей уңае белән бу хатта әйтелгән фикерләргә охшаш байтак тәбрикнамәләр алдык без. Сүз дә юк, горурландыра, күңелне үстерә торган тәбрикләр. Әмма алар безгә, редакция хезмәткәрләренә, гомумән, язучыларга гаять зур вазифа, гаять зур җаваплылык өсти. Ышанычны акларга иде! Һәммәбез белә: унбиш-егерме еллар эчендә җәмгыятьтәге чиктән-чиккә ташланулар, берөзлексез «реформа»лар, парадокс хәлләр матбугат дөньясында да чагылыш тапмый калмады. Бу яктан, шөкер, «Казан утлары» үзенең күркәм традицияләрен дәвам итеп, вакланмыйча,



очсыз реклама-шоудан, түбән инстинкт уята торган язмалардан өстен булып, акча кубызына биемичә, милләтебезнең традицион әхлак кодексына лаек әсәрләр язып, халкыбызның төп җитди журналы булып кала алды. «Казан утлары», чын мәгънәсендә, халык журналы — игенчеләр, укытучылар, эшчеләр, укучы яшьләр, зыялылар журналы. Журнал халык тормышын чагылдыра, шөкер, аның язмышы халык язмышы белән тәңгәл бара.

«Казан утлары» — әлбәттә, иң әүвәл язучылар журналы. Әдипләребезнең яңа язылган иң яхшы әсәрләре

шушы журналда дөнья күрде. Алар әдәбиятыбызның алтын фондына керде, соңрак күп телләргә тәрҗемә ителеп, татар әдәбиятын дөньяга танытты. Татар халкы, аның тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, хыял-омтылышлары белән бүтән ил халыкларын таныштырды һәм, киресенчә, чит ил һәм күрше-тирә кардәш халыклардагы иң яхшы әдәби үрнәкләрне мөмкин булганча яктыртып килә.

Шунысын да өстәп әйтик: журнал яшьләр иҗатына киң урын бирергә тырыша. Соңгы елларда сәләтле яшь каләм ияләренә игътибар аеруча артты. Алар өчен яңа рубрикалар ачыла, конкурс-ярышлар оештырыла, әсәрләре тәфсилләп анализлана... Һәм бу хәл аңлашыла да. Яшь көчләр үзләре дә иҗатлары белән шактый активлык күрсәтә, безнең журналда басылуны дәрәҗә саный. Аңлыйлар: «Казан утлары» дигән Әдәби Капканы үтмичә, зур иҗат мәйданында танылу кыен. Үткәнең нинди генә данлы булмасын, әгәр киләчәгеңә өмет булмаса, тормышта яшәүнең, иҗат итүнең мәгънәсе югалыр иде.

Күпләр «Казан утлары»н әдәби-мәдәни тормышыбызның тарихи елъязмасы дип саный. Әйе, мондый бәя хаклыкка шактый ук туры килә. Ә бит безнең рухи тормыш әдәбият белән генә чикләнми. Шуңа күрә дә журналга төрле тармакларга «таралып җигелергә» туры килә. Нәфис әдәбияттан тыш, әйтик, фән дөньясын алыйк: гуманитар өлкәдә, бигрәк тә әдәбият, тарих, тел белеме фәннәрендә академикларыбыз, йөзәрләгән фән кандидатлары һәм докторларыбыз бар икән, моңа кадәр аларның күбесе шушы журналда язмышын, хезмәтләрен бастырып, гыйлем үрләрен яулады. Моңарчы театр, музыка, рәсем сәнгате мәдәният тарихы буенча махсус басмаларыбыз булмады диярлек. Шуңа күрә рәссамнар, композиторлар, артистлар, гомумән, сәнгать кешеләре иҗатына журналда шактый мул урын бирелә.

Әйе, журналыбызга 90 яшь. Юбилей бәйрәмнәре вакытында, гадәттә, проблемалар турында бик үк сөйләшмиләр. Шулай да ачык булыйк: алар бар. Хәзерге чорда язучыларга, сәнгать әһелләренә җиңел, дисәләр, андыйлар үзләре җиңелрәк холыклы кешеләр булыр. Безнең өчен хәзер иң мөһим проблемаларның берсе — укучыларыбызны югалтмау, мөмкинлек булганда, ишәйтү. Электрон мәгълүмат чаралары, интернет заманында бу җиңел нәрсә түгел. Укучыларыбызны саклап калу юнәлешендә безгә турыдан-туры кагылган ышанычлы юлларның, берсе — яхшы әсәрләр язу, булдыра алсаң бөек әсәрләр иҗат итү. Каләмгә тотынган һәр кеше моны онытмаска тиеш.

Моннан дүрт гасыр ярым элек үзенең дәүләтен югалткан халык тарихында, аның рух дөньясында әдәбият үзгә бер миссиягә ия: ул рәсми беткән, ә күңелдә мәңгелеккә уелып калган дәүләтчелек хисен сүндерми сакларга ярдәм иткән, Ил-дәүләт эшләргә тиеш булган кайбер функцияләрне дә үтәп килгән. Казан бөтен дөньяга сибелгән татар кешеләренең өмет кыйбласы булса, «Казан утлары» — бөтен татарның төп калын журналы. Бер гасыр буе диярлек ул төрле кыйтгаларга таралган халкыбыз тормышын сүз сәнгатендә объектив чагылдырырга, милләттәшләребезне үзара якынайтырга, берләштерергә, цивилизация дөньясында халыкның үзенә лаек урынын алырга булыша. Иншалла, киләчәктә дә шулай булыр!

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ

ГАМИЛ АФЗАЛ

(23.05.1921 – 20.08.2003)

***

Тарих таңы, яулап алган якты иртә.
Кирәк икән, йолдызга да кулым җитә.
Акыл көче галәм иңләп очкан илдә
Кеше түгел, машина да телгә килә.
Халыкларга хөрлек биргән туган илем,
Сине җырлап, итәгеңә башым идем.
Җырла, диеп, бирде миңа туган җирем
Тукай телен, Такташ телен, Җәлил телен.
Шуны җуйсам, булам телсез бәрән генә,
Бәрәннәргә җан азыгы әрәм генә.
Өстәлемә карап кына яшәү кала,
Шөкер итеп ипи белән бәрәңгегә.
Ил төзүче алтын куллы оста үзем,
Җырым белән, сүзем белән якты йөзем.
Туган илем, бетсә телем – бетә сүзем,
Якты көн дә кирәк түгел, чыксын күзем!

1965

* Татар халкының күренекле шагыйре Гамил Афзалның кайбер сүз-энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

РОССИЯДӘ ТӨРКИ-ТАТАР БАСМАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ҮРНӘГЕ ХАКЫНДА

Миркасыйм Госманов*

Һәр халыкның басма сүзе барлыкка килүе һәм үсүе билгеле бер дәрәҗәдә, беркадәре көзгедәге кебек үк, шул халык тарихына хас төп үзенчәлекләрне чагылдыра. Ерак үткәндәгесен дә, хәзергесен дә. Моны татар басма сүзе язмышы мисалында күзәтергә мөмкин.

Татар басма сүзенең башлануы, авырлык белән аякка басуы, алга таба гөрләп үсеп китүе күп яктан Россия дәүләтчелегенең чынбарлыгына бәйле иде. Чөнки татар халкы XVI гасыр урталарыннан алып шул дәүләт составында гомер кичерде һәм кичерә килә. Татар телендәге беренче басманың барлыкка килүе дә көчле үсеш кичерә торган мәмләкәтнең ихтыяры һәм ихтыяҗлары белән билгеләнүе һич тә очраклы түгел. Әмма алга таба аның тоткарлануы, вакытлы басмаларның теге яки бу рәвештә нормаль яшәеше өчен көрәшнең йөз елга якын сузылуы да әлеге дәүләтнең империячел сәясәтеннән килеп чыккан иде. Идел буе — Казан татарлары өчен вакытлы матбугат оештыру фикерен алга сөрүчеләр арасында рус зыялыларының да шактый булуына карамастан, патша хөкүмәте мондый омтылышларны даими рәвештә тыеп килде. 1808 елда ук көн тәртибенә куелган мәсьәлә бары 1905 елгы революция нәтиҗәсендә генә хәл ителә алды [1].

Шул ук вакытта Идел буе һәм Урал алды татарларының урта гасыр әдәби телендә беренче басма сүз үрнәге бар-

*Миркасыйм Госманов (1934-2010) — академик, тарихчы, археограф, публицист. Казанда яшәде.

лыкка килүе ул, чынбарлыкта халыкның үз язма-әдәби традицияләре белән әзерләнгән һәм тәэмин ителгән күренеш иде. Чөнки аның ерак һәм якын ата-бабалары моннан мең ярым еллар элек үк, Төрки каганлык чорында, язудан файдаланганнар. X-XI гасырларда яшәгән болгарлар мөселман Көнчыгышының китап культурасы белән шул чорда ук танышканнар. 922 елда ислам динен рәсми рәвештә кабул итү нәтиҗәсендә, Идел-Болгары дәүләтендә төрле әсәрләр иҗат ителә башлаган, алар, табигый, кульъязма китап рәвешен алган.

Болгарларда әсәр-китаплар булуы турында иң элгәреге мәгълүматларны Андалусиядән килгән гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнати калдыра. 1135 елда Болгарда ул Әбү әл-Мәгали әл-Җүвәйнинең шәкерте казый Йагкуб ибне Ногман тарафыннан күчерелгән (язылган?) «Болгар тарихы» исемле әсәрнең кульъязмасы белән шәхсән танышкан [2].

Әлбәттә, бу бердәнбер очрак түгел. Яңа заман татар фәнни-тарихи фикеренә нигез салучы Шиһабеддин Мәрҗани үзенең Болгар дәүләте вә Казан ханлыгы тарихы турындагы мәгълүм хезмәтендә илаһият, фикер (мөселман хокукы) һәм фәлсәфә буенча Болгар һәм Казан чоры галимнәре һәм акыл ияләре язып калдырган әсәрләрнең, исемнәрен китерә [3]. Билгеле булганча, андый хезмәтләрнең текстлары сакланмаган. Дөресрәге, XIX-XX гасыр галимнәренең [4] эзләнүләренә карамастан, аларның әлегә кадәр табылганы юк. Табигый ки, бу аларның, чыннан да, булуларын беркадәре шик астына куя.

Шулай да соңгы вакытта әлеге мәсьәләне ачыклауга мөһим өлеш кертә торган әһәмиятле ачышлар ясалды. Мәсәлән, 1996 елда Иран ислам җөмһүриятенең Сенат китапханәсендә үз заманының мәшһүр табибы Таҗеддин әл-Хәсән ибне Йуныс әл-Болгариның фармакология белеменә караган «Зур тирйак» исемле хезмәтенең күчермәсе табылды. Аның тексты инде басылып та чыкты [5]. Шул ук авторның «Мохтасар фи мәгърифәт-әл-әдвия» дигән икенче хезмәте 1999 елда Төркиянең Маниса шәһәрендә табылды (Ә.Б.Халидов белән берлектә). Боларның һәммәсе болгар укымышлылары тарафыннан китап культурасының чагыштырмача тирән үзләштерелгән булуын раслый. Әгәр дә 615/1219 елда язылган беренче әсәр XVII гасыр күчермәсендә — Шәрекънең урта гасырлардагы мәшһүр табиблары (Мөхәммәд әр-Рази, Ибне Сина, Насреддин Туси, Шапур ибне Сахл һ.б.) хезмәтләреннән торган җыентыкта сакланган булса, беренчесе шикелле үк, Таҗеддин үзе әйтеп яздырган һәм хәзер Маниса шәһәрендә саклана торган икенче әсәр исә безгә 619/1222 елда, ягъни монголларгача чордагы күчермәдә килеп җиткән [6].

Шиһабеддин Мәрҗани хезмәтендә аталган китап исемнәреннән, шулай ук Таҗеддин әл-Болгари хезмәтләреннән күренгәнчә, урта гасыр Идел буе укымышлылары тарафыннан китап культурасы да, «Көнчыгышның латин теле» дип танылган гарәп әдәби теле дә үзләштерелгән икән.

Шуның белән бергә Идел буенда яшәүче төрки-мөселманнарның гарәп телендәге китаплар белән бергә болгар телендә дә, угыз-кыпчак сөйләшләрендә дә төркичә текстлар иҗат итүен исәпкә алырга кирәк. Беренче төргә караган лапидар текст үрнәкләре күпсанлы эпитафияләрдә сакланып калган [7]. Икенче сөйләшнең ачык мисалы ул — Кол Галинең 1233 елда, ягъни монгол яуларына кадәр иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасы [8]. Идел буе һәм Урал алды татарлары арасында аның күп сандагы күчермәләренең мөстәкыйль кульъязма китаплар [9] рәвешендә күпләп таралуы ата-бабаларыбызның үз телләрендәге китап культурасын тирән үзләштерүләре хакында сөйли.

Төбәктә төрки телле китап культурасының алга таба үсеше, дәвам итүе Алтын Урда чорына карый. Евра-

зия киңлекләрендә барган төркиләшүнең көчле яңа дулкыны нәтиҗәсендә [10], уйгыр-карлук язма культурасының бай традицияләренә һәм Хәрәзем, Болгар төбәкләренең тәҗрибәсенә таянып. Шулай ук җирле тел күренешләре нигезендә угыз-кыпчак әдәби теле [11] формалаша, шул телдә зур күләмле әдәби әсәрләр иҗат ителә. Мәсәлән, алар арасында кульязма китап рәвешендә яши алырлык «Нәһҗел-фәрадис», «Хөсрәү вә Ширин», «Гөлестан бит-төрки» һ.б. әсәрләр [12] бар.

Җучиләләр дәүләтендә, ягъни Алтын Урдада, матур әдәбият [13] белән бертигез дәрәҗәдә төрки-татар телендә югары сыйфатка ирешкән канцелярия-эш кәгазьләре культурасы да үсә; бу телдә дәүләтнең эчке эшләренә караган актлар гына түгел, бәлки тышкы, ягъни халыкара, милләтара мөнәсәбәтләргә нисбәтле документлар да язылган [14].

Бу чорда төрки-татар теле Төньяк-Көнчыгыш Русьнең Сарай хөкемдарларына буйсынган рус кенәзлекләрендә дә кулланылышка керә. Моны рус грамоталарындагы уйгыр язулы карарлар [15], бөек кенәзләр Дмитрий, Иван III тәңкәләрендәге татарча язулар [16] кебек аз өйрәнелгән күренешләр дәлилли. Бөек кенәз Иванның (булачак Грозный патша), үсмер вакытында Казан ханбикәсе Фатыйма солтан белән очрашканда, татарча сәламләшү йоласын үтәве дә билгеле [17]. Боларның һәммәсе элекке дәверләрдә идарә иткән рус кенәзләренең озак вакытлар үз сюзереннары ставкаларында, кайчак алар белән туганлык бәйләнешенә дә кереп, яшәү һәм аралашу тәҗрибәләрен чагылдыра [18]. Алар ханнар белән сөйләм телендә дә, язма телдә дә аралашканнар. Вассал телен сюзерен түгел, киресенчә, сюзерен телен вассал үзләштерә.

Мондый тәҗрибә һәм ихтыяҗ Мәскәүнең бөек кенәзе, соңрак патша сарае каршында табигый рәвештә татар телен белүче тәрҗемәчеләр һәм тылмачлар төркемен барлыкка китерә. Алар Мәскәү-Урда мөнәсәбәтләре буенча да, еш кына вәкилләр (хәбәрчеләр) һәм илчеләр сыйфатында да йомыш башкаралар. Йомышлы татарлар һәм татар телен белүче руслардан нәкъ менә шундый «арадашчылар» алга таба Илчелек (Посольский) приказы составында оешкан «Татар канцеляриясе»ндә хезмәттә булалар [19]. Шуңа да Россия дәүләтенең көнчыгыш һәм көньяк күршеләре белән язышуында татар теле, төгәлрәге, төрки-татар теле актив кулланылуын дәвам итә [20], һәлак булган Патша архивында, аның исән калган тасвирламасыннан (опись) күренгәнчә, Батый һәм башка ханнар заманыннан ук калган борынгы төрки телдәге йөзләрчә документлар сакланган була. Аларның иң борынгылары уйгыр язуы белән башкарылган булса кирәк, исемлекне төзүче күрсәткәнчә, «боларын беркем дә тәрҗемә итә алмый» [21]. Илчелек приказы архивында исә (соңрак ул да шулай ук өлешчә юкка чыга), әлеге исемлеккә караганда, андый документларның тагын да күбрәк булганлыгы мәгълүм. Әле соңрак та, XIX гасырның беренче чирегенә, хәтта аның уртасына кадәр андый документлар туплану дәвам иткән [22].

Н.И.Веселовский, гомумән, рус-шәрекъ мөнәсәбәтләрендәге шушы үзенчәлекләрне, җөмләдән күп кенә рус чыганакларында аталган «татар теленең» урынын да күздә тотып, рус кенәзләре һәм патшаларының илчеләр кабул итү тантанасы тәртибенә бәяләмә биреп, түбәндәге гомуми нәтиҗәне чыгара: Петр I гә чаклы бу тантана «тулысынча диярлек татарларга, яки, дөресрәге, Азия халыкларына хас сыйфатларга ия иде» [23]. Төрки телнең шәрекъ илләре белән бәйләнеш тарихындагы әһәмиятен раслый торган әлеге фикер белән тюркология тарихы буенча зур белгеч академик А.Н.Кононов та килешә [24].

Гасырлар дәвамында рус-шәрекъ бәйланышларында актив кулланылган язма төрки телнең әлеге «варианты» йөзләрчә рус чыганакларында, алда әйтелгәнчә,

татар теле дип атап йөртелә. Абруйлы тюркологлар һәм тарихчыларның берсе дә әлеге «татар теленең» Алтын Урда (Җучи Олысы) дәверендәге, шулай ук Җучилеләр империясе таркалу нәтиҗәсендә барлыкка килгән татар ханлыклары чорындагы язма төрки телнең турыдан-туры, ягъни генетик дәвамы булуын шик астына куймый. Нигезе һәм килеп чыгышы белән угыз, кыпчак телләреннән булган әлеге язма тел, вакыт-вакыт XVIII-XIX гасырларда чыгытай [25], шулай ук госманлы-төрек әдәби телләренең күпмедер йогынтысына дучар булып, Идел буенда (ягъни татарлар арасында) «XX гасыр башына кадәр яшәвен дәвам итә» [26]. Төрки халыкларның урта гасырлардагы язма культурасы тарихы буенча төпле һәм этрафлы белгеч Ә.Н.Нәҗип әнә шундый фикердә тора.

Чыннан да, Идел буе һәм Урал алды регионын Рус дәүләтенә көчләп кушканнан соң, җирле төрки халыкның иҗтимагый-сәяси аерымлануы, электән үк килгән язма традиция тукымасына даими рәвештә җирле сөйләш элементлары үтеп керү нәтиҗәсендә XVIII гасыр һәм XIX гасыр башында элекке традицияләрнең акрынлап кына, җай гына яңаруы, баюы күзәтелә. Капиталистик мөнәсәбәтләр урнашкан чорда җәдитчелек үсеше киң мәгънәдәге мәгърифәтчелек хәрәкәте белән бергә барган, иҗтимагый-этник үзаңның активлашуын булдырган процесс тизләшә, XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башында хәзерге татар милли әдәби теленең тәмам формалашуына, гөрләп дигәндәй үсүенә китерә.

Ата-бабалары Җучи Олысына, ягъни Алтын Урда составына кергән төрки телле башка халыкларда, этносларда да милли төрки телләр оешу һәм үзгәрү шул рәвешчә бара. Аерма бары шунда гына: кайбер этносларда бу процесс иртәрәк, башкаларында беркадәре соңрак күзәтелә. Кардәш төрки халыкларның ата-бабалары 300 ел дәвамында бер империя составында булуның соңгы нәтиҗәсе менә шундый. Башка язма төрки телләрдән, мәсәлән, госманлы-төрек, чыгытай, уйгыр телләреннән аерылып торган Алтын Урда чоры язма теленең соңгы язмышы да шундыйрак.

Яңа чор фәнни әдәбиятта Алтын Урда язма төрки теле «вариантына» карата төрле атамалар: төркичә, Идел буе төркичәсе, иске татар теле һ.б. төшенчәләр кулланыла. Бу атамалар күренешнең асылын өлешчә генә ачалар, төгәллектән һәм тарихи дөреслектән ераграк торалар, чөнки «төркичә» дигән төшенчәнең мәгънәсе бик киң: бу сүз белән төрки әдәби телләрнең башкаларын да, хәтта теләсә кайсы вариантларын атап булыр иде. Гәрчә Алтын Урда «варианты»ның барлыкка килүе, төгәлрәк әйтсәк, формалашуы, нигездә, Идел буенда барса да, ул шактый киң территориядә гамәлдә йөргән. Шушы ук фикерне билгеле бер дәрәҗәдә «иске татар» атамасына карата да кулланырга мөмкин. Шуңа да аны — Алтын Урда чорындагы язма телне — төрки-татар композитасы (кушылмасы) белән атау дөресрәк булыр иде: сүзнең беренче өлеше нәсел-ыруны аңлатса, икенчесе тел-шивәнең төрен күрсәтә. Нәтиҗәдә, бер тарафтан, гомуми нигез буларак аның генетик асылы билгеләнә, икенче яктан, бу әдәби тел барлыкка килгән, башка регионнарга караганда озаграк вакыт үсеш кичергән, гамәлдә булган билгеле тарихи-географик һәм этник мохит исәпкә алына.

Көнчыгыш телләрдәге беренче җыелма хәрефле басмалар тарихыннан күренгәнчә, Россиядә төрки-татар теле мөмкинлекләренә, Азия чынбарлыгының аерылмас бу «кисәгенә» — көнбатышчылыкның эзлекле тарафдары, шуның өстенә татарларның аяусыз дошманы булган (аның татар җирбиләүчеләренә карата кулланган катгый икътисади санкцияләрен генә дә искә төшерик) император Петр I еш кына мөрәҗәгать иткән.

Мондый басманың барлыкка килү тарихы кыскача менә болай.

Петр I тышкы сәясәтендә, билгеле булганча, илнең территориясен көньяк һәм көнчыгыш юнәлешләрендә киңәйтү омтылышы, һәрхәлдә, анда Россия империясе йогынтысын көчәйтү максаты шактый зур урын били. Шуңа да ул Һиндстанга һ.б. Шәрекъ илләренә географик шартларны, элемтә юлларын өйрәнү максаты белән разведка экспедицияләре (Бекович-Черкасский, Тәфкилев, Соймонов һ.б.) оештыра. Сәүдә бәйләнешләрен хуплаудан тыш, әрсезлек һәм үзсүзлелек күрсәтеп, башка империяләр белән килешүләрне боза, аларны үзләренә буйсынган җирләрдән кысрыклап чыгарырга тырышып, экспансия юлына баса. Аның гамәлләре башкалар, аеруча статус-кво дәрәҗәсен саклап калырга тырышкан «карт империя» вәкилләре карашынча, еш кына дорфалык белән аерылып тора. Госманлылар Төркиясендә, Төньяк Кавказ һәм Кара диңгез буеннан кысып чыгарылган төп көндәшләре арасында рус патшасы исеменә «дорфа, башбаштак, буталчык» мәгънәсендәге deli (тиле) кушаматын тагалар. Шуңа да госманлы-төрек сәясәтчеләре һәм тарихчылары телендә Deli Petro якынча «тупас, аңлап булмаслык Петр» рәвешендә яңгырый.

Империянең көньяк-көнчыгышында Петр I алып барган экспансив тышкы сәясәтнең төп максаты Каспий алды төбәкләрендә рус йогынтысын көчәйтүдән, мөмкинлек булган очракта әлеге җирләрне, шул исәптән Шәмәха, Дәрбәнд һәм Баку шәһәрләрен басып алудан гыйбарәт иде. Мондый планнарны гамәлгә ашыру өчен сылтау да табыла: 1720 елда лезгиннар һәм кумыклар Дауыт бәк һәм Сорхай җитәкчелегендә Иран шаһына каршы баш күтәрәләр. Алар Шәмәханы һәм фарсылар хакимиятендәге башка кайбер шәһәрләрне кулга төшерәләр һәм талыйлар. Алардагы рус сәүдәгәрләре дә зыян күрә. Бу исә Петр I гә шактый киң колачлы яу башлар өчен мөмкинлек тудыра. Әлеге походны ул чорда «Шәмәха экспедициясе», фәндә исә Петр I нең Фарсы походы дип атыйлар [27].

Бу яуны оештыручыга, походны башлау алдыннан гына булса да, Иран хакимиятендәге Кавказ халыклары алдында шаһ биләмәләрендәге гамәлләренең «законлы» икәнлеген юридик җәһәттән нигезләргә була. Шул максаттан Петр I махсус указ-манифест чыгара, анда ул үз гамәлләрен «безнең зур дустыбыз һәм күптәнге галиҗәнап күршебез (...)» шаһның фетнә күтәргән подданныйларына җәза бирү, шулай ук аларның Шәмәхадагы рус сәүдәгәрләрен талауларына карата чара күрү дип аңлата. Шуңа күрә «ике кыйтга падишаһы, ике диңгез хөкемдары» бөтенроссия императоры Петр I, рус гаскәре басып кергәндә җирле халык үз өйләреннән чыгып качмасын һәм гаскәргә коралды каршылык күрсәтмәсен өчен аларны тыныч калырга өнди. «Бу манифест 1722 елның 15 июлендә Әстерханда татар, төрек һәм фарсы телләрендә басылып чыга» [28]. Шулай итеп, Шәрекъ илләре хакимнәре белән язышканда, Петр I үзенең күпсанлы элгәреләре үрнәгендә Алтын Урда заманнарыннан ук яхшы таныш булган, элек-электән рус-шәрекъ багланышларында кулланылган «татар теленнән» файдалана. Югарыда китерелгән күзәтүдән күренгәнчә, бу тел нәкъ менә төрки-татар язма теле, ягъни милли татар әдәби теленең урта гасырлардагы элгәресе була да инде.

Шунысын да истән чыгармыйк: Петр I моңа кадәр дә башка телләрдәге текстларны бастырып чыгара. Мәсәлән, 1711 елдагы Прут походы вакытында күп кенә телләрдә, шул исәптән, Кара диңгез буйларының төньягында яшәгән халыкка адресланган «универсалы» «татар телендә» бастырыла. Ф.Е.Корш ачыклаганча, универсалның соңгысы «казан-татар» телендә булып, ксилографик ысул белән күбәйтелгән [29].

1722 елгы манифестның фарсы варианты — иранлыларга, фарсы телендә

аралашкан халыкларга һәм югарыда телгә алынган шәһәрләрдәге чиновникларга, ә төрек версиясе азәрбайҗаннарга һәм Төньяк-Көнбатыш Кавказдагы госманлы-төрек кешеләренә атап чыгарылган. Төрки-татар версиясе исә төбәктәге төрле телләрдә сөйләшүче халыкларга багышланган. Чөнки татар теле аны туган тел «дәрәҗәсендә диярлек белгән» кумыклардан, нугайлардан һәм балкарлардан кала, башкаларга да элек-электән этносара аралашу чарасы буларак хезмәт иткән. Шушы хакта рус-шәрекъ багланышларына нисбәтле документлар шаһитлык итә. Мәсәлән, Шибут җәмәгате тарафыннан 1657 елда патша Алексей Михайловичка юлланган хат төрки телдә язылган, анда барыннан да элек иске татар теленә хас булган грамматик элементлар бар [30]. Алексей Михайлович үзе дә 1667 елда калмык юлбашчыларына җибәргән бер грамотасын татар телендә яздырган [31]. Татар тылмачлары, тәрҗемәчеләре һәм илчеләре кабарда һәм башка Төньяк Кавказ кенәзләре белән багланышлар үстерүдә актив катнашканнар [32].

Димәк, Кавказ халыкларына төркитатарча мөрәҗәгать итеп, Петр I элек-электән яшәп килгән традицияне генә дәвам иткән. Монда бернинди очраклы нәрсә дә, яңалык та юк. Күпсанлы документаль чыганак мәгълүматларыннан күренгәнчә, совет чорындагы кайбер авторлардан аермалы буларак, Шәрекъ илләре белән багланышлар буенча җаваплы Россия чиновниклары төрле төрки язма телләрне үзара буташтырмаганнар, татар телен төрек теленнән җиңел аера белгәннәр.

Петр I манифестын өч телдә бастырып чыгаруның тарихи яктан мөһим яңалык буларак та зур әһәмияте бар: бу төркитатар текстын җыелма хәрефләр белән бастыруның беренче үрнәге иде.

Шуңа игътибар итик: бу факт — 1612 елда Лейпцигта чыккан, нигездә, Балкан төркиләренә хас тел-шивә үзенчәлекләрен чагылдырган китаптан һәм госманлы-төрек басмаларыннан аермалы буларак — татарча беренче басманың чыганак белән тамырлары һәмтәүге адымнары ниндилеген күрсәтү өстенә аның югары технологиягә таянганлыгына да шаһитлык итә.

Моңа махсус игътибар бирелү һич тә очраклы түгел. Кешеләрнең үзара аралашуында гомумкешелек цивилизациясенең иң мөһим казанышларының берсе язу уйлап табу, алга таба китап культурасын үзләштерү булса, китап басу, гомумән, хәреф җыеп басма сүз тудыру ысулы чын мәгънәсендә революцион яңарыш була. Нәкъ менә даһи Иоһанн Гутенберг заманнарыннан алып, гомумкешелек цивилизациясе тарихында күпкатламлы, ягъни этнос эчендәге, этносара, халыкара, гомумпланетар аралашуда яңа эра — Басма сүз, Басма китап галиҗәнаплары эрасы хакимлек итә башлады!

Гыйльми әдәбиятта хәрефләрнең беренче коелмалары турында төрле карашлар яши: алар Гутенбергка кадәр үк Шәрекъта (Кытайда, Кореяда) кулланылган, бу юнәлештә Үзәк Азиядә яшәүче уйгырлар да кайбер адымнар ясаганнар, Европада исә җыйма хәрефләрне башка кешеләр уйлап тапкан дигән фикерләр һ.б. әйтелгәләде. Булгандыр, бәлкем. Әмма биредә бәхәс өчен урын юк. Чөнки теге яки бу башлангычтан түгел, бәлки нәкъ менә Гутенберг эшчәнлегеннән, аның тарафыннан 1445 елда бастырылган Библиядән башлап, Җир шарында җыйма (күчмә) хәрефләр ярдәмендә барлыкка килгән басмалар тантаналы рәвештә алга атладылар. Басмаларның электрон, компьютер чаралары, ягъни яңа техник казанышлар ярдәмендә башкарылуын гамәлгә керткән чираттагы яңа эрасы башлангач та, китап басудагы «иске» ысулның төп идеясе — «күчмә», алмаштырылучан хәрефләр идеясе сакланып калды.

Шулай итеп, текстларны җыйма хәрефләр ярдәмендә нәшер итү XV гасыр уртасында Европада тормышка ашы-

Манифест



рылган иде. Ләкин төрле халыклар һәм цивилизацияләр бу мәдәни-техник казанышны төрле дәверләрдә үзләштерделәр. Әйтеп үтелгәнчә, бу һәр халыкның, һәр илнең конкрет тарихи язмышы, реаль мөмкинлекләре белән тыгыз бәйләнгән. 1722 елда төрки-татар телендәге беренче җыелма басманың дөньяга чыгуы, бәхәссез фактлардан күренгәнчә, татар халкының аңа кадәрге чорларда ирешкән тарихи һәм мәдәни үсеш дәрәҗәсен чагылдыра икән.

Гарәп графикасында төрки телләрдә басылган китапларның әлгәреге үрнәкләрен, бигрәк тә беренче татар басмасын ачыклау эшен, китапчылык тарихы белгече, гомумән, татарларда китап басу тарихы буенча фундаменталь тикшеренүләр һәм, аерым алганда, фәнни-библиографик хезмәтләр биргән күренекле галим Әбрар Кәримуллин (1925-2000) [33] башлап җибәргән һәм этрафлап өйрәнгән иде [34].

Ә.Кәримуллинның гаять бай архив материалларына нигезләнгән хезмәтләре гарәп графикасында чыккан татар басма китабы тарихын, аның чишмә башыннан, ягъни XVIII гасырдан алып ахырына кадәр, 1926 елда латин графикасына күчү чорынача бербөтен хәлдә күзаллау мөмкинлеген бирә. Галим, гомумән, татар басма китабы, үсешендәге кыенлыклар һәм казанышларны ачыклый; төрле нәшриятларның, аерым наширләрнең эшчәнлеген һәм керткән өлешләрен җентекләп тикшерә; шулай ук типография техникасының үсеш тарихы мәсьәләләрен дә яктырта. Ә.Кәримуллинның бу өлкәдә фәнгә керткән бер мөһим өлеше аның «милли китап» төшенчәсен төгәл аныклавы булды. Аңа кадәр бу төшенчәне аңлатуда каршылыклар һәм буталчыклыклар яшәп килгән иде, мәсәлән, элегрәк әсәр авторының этник чыгышы белән китап басылган этник-мәдәни мохитне, китап бастыручыларны үзара аера, ачыклый алмау хөкем сөргән иде. Галим әсәрнең теле һәм эчтәлегеннән генә чыгып, аны башка мәдәни шартларда бастырылган китап рәвеше — физик гәүдәләнеше белән тәңгәлләштермәде [35]. Ул, әлбәттә, татар басма китапларының репертуар үзенчәлекләрен ачыклап, патша цензорларының, төрле киртәләр тудырып, китапларның эчтәлекләренә йогынты ясарга омтылуларын да яктырткан иде.

Шулай итеп, Ә.Кәримуллин тара-



фыннан, бер кеше гомерендә мөмкин булган кадәр, татар басма китабының революциягә чаклы тарихы хакында төгәл-тулы дип әйтерлек дәрәҗәдә манзара тудырылган иде. Революциягә кадәр 10 меңнән артык исемдә татар басма китабы нәшер ителгән булса, күләме буенча ул, гомумән, Русия империясендә төрле телләрдә чыккан китап дөньясында алдынгы урыннарның берсен биләп торган иде. Икенче төрле итеп әйткәндә, әлеге фидакарь галимнең хезмәтләрендә гарәп графикасында басылган татар китабының тарихы тулысынча диярлек яктыртылган. Бу нәтиҗәне тамырдан үзгәртерлек эре ачышларның киләчәктә булуы шикле. Әмма өстәмәләрнең, аерым фактларны аңлатудагы төзәтмәләрнең булуы ихтимал һәм бу — табигый күренеш.

Петр I манифестының төрки телдәге версиясе оригиналын тикшергәндә, Ә.Кәримуллин бу басманың тарихын ачыклау һәм аныклауда шактый зур эш башкара. Манифестның басма версиясе турында элегрәк тә мәгълүм булса да [36], ул беренчеләрдән булып аның Россиядә гарәп графикасында дөнья күргән төрки телдәге басмалар арасындагы урынын һәм әһәмиятен билгели. Галим Петр яу сәфәре вакытында эшләгән типографиясе, гарәп шрифтларын кою тарихын яктырта, манифестның шәркый версиясен тудыручыларны ачыкларга омтыла. Шулай итеп, Россия империясендә гарәп графикасында нәшер ителгән беренче басмаларның үзенчәлекле, катлаулы язмышларын ачыклау буенча кызыклы фаразлар ясала, нәтиҗәләр чыгарыла. Соңгыларын биредә кабатлауга ихтыяҗ юк, чөнки алар Россиядә беренче төрки-татар басмасының дөнья күрүенә 285 ел тулуга багышлап Татарстан Республикасы Милли китапханәсе тарафыннан чыгарылган әлеге китапның кушымта өлешендә урын алды.

Шуңа күрә кызыксынучан укучыны манифест текстының укылыш версияләре, хәзерге татар, рус телләрендә чагылган эчтәлеге, шулай ук белешмәләр һәм тикшеренү материаллары белән таныштыру барышында ахыргача хәл кылынып җитмәгән һәм ачыкланып бетмәгән кайбер мәсьәләләргә кыскача тукталуны кирәк табам. Кызганычка каршы, андыйлар да җитәрлек.

Беренчедән, Россиядә татар басмасы барлыкка килү «XVIII гасырның беренче чирегендә (...) очраклы күренеш иде, ул 1722 елда барлыкка килде һәм бетте» [37] дип раслау дөреслеккә туры килми. Чынбарлыкта ул басма Алтын Урда чоры төрки-татар теленең үткән дәверләрдәге, Петр I гә кадәрге генә түгел, бәлки аңардан соң да, рус-шәрекъ багланышлары тарихындагы урыны һәм әһәмиятенең закончалыклы нәтиҗәсе буларак оешкан иде.

Әгәр мондый күптәннән килә торган тәҗрибә-мирас булмаса, үҗәтләнеп көнбатышчылык юлына баскан Петр I дәһшәтле әлгәресе тарафыннан каты буйсындырылган һәм үзе үк максатчан рәвештә талаган, кимсеткән бер шәрекъ халкының теленә мөрәҗәгать итеп торыр идеме?! Димәк, мәсьәлә ул кадәр үк гади һәм очраклы түгел икән.

1722 елда техник яңалыкка — яңача

басма ысулына мөрәҗәгать итү дә очраклы түгел. Чөнки Петр I заманында беренче газеталар басылу, гражданлык шрифтын кертү, типографияләр, нәшриятлар оештыру да очраклылык булмады, ник дигәндә, Россия иҗтимагый һәм мәдәни үсешенең яңа баскычларына күтәрелә иде.

«1722 елда бетү» дә шулай ук закончалыклы: чит-ят, башка диннәрдәге халыкларга карата гына түгел, хәтта рус халкының зур күпчелеге мәнфәгатьләре белән дә исәпләшмәгән, крепостнойлык, ягъни ярым колбиләүчелек хөкем сөргән илнең милли-дини сәясәте башкача була алмый. Шулай итеп, монда да бернинди очраклылык юк икән.

Икенчедән, манифестның татарча тексты яки аның татар теленә тәрҗемәсе Д.Кантемир [38] тарафыннан язылган дип расларга тырышу да ышандырмый. Эш шунда ки, әле күптән түгел генә (1711 елда) рус хезмәтенә күчкән (шуңа күрә татарчаны белдеме икән әле ул!) Д.Кантемирдан башка да Россиядә төрки-татар телен белүчеләр җитәрлек була. Мәсәлән, Илчелек приказында 1689 елда — Петр I заманында ук диярлек, югарыда күренгәнчә, рус булмаган телләр буенча хезмәт күрсәтүче 22 тәрҗемәченең 8, ягъни барлык тәрҗемәчеләрнең 1/3 татар телен белүчеләр [39], араларында төрекчәне дә белүчеләр булганлыгы мәгълүм. Ләкин болай дип мин Д.Кантемирның поход типографиясен оештырудагы, гарәп хәрефләре пунсоннарын һәм шрифтларын әзерләүдәге ролен инкарь итәргә җыенмыйм. Мөгаен, Д.Кантемир 1722 елгы манифестның безгә билгеле төрек версиясен бәян иткәндер, ләкин аның поход вакытында төрек теле буенча бердәнбер тәрҗемәче булуы да шикле. Шулай итеп, монда сүз бары тик документның татарча тәрҗемәсе турында гына бара. Петр I заманында да, аңа кадәр дә Россиядә хөкүмәт хезмәтендә төрки-татар язма теле белгечләре җитәрлек иде. Гомумән, Россиядә көнчыгыш телләрен махсус өйрәнү, шул исәптән илдә гыйльми тюркологиягә нигез салыну, башка белемнәр белән беррәттән аерым гимназияләрдә һәм университетларда нәкъ менә XIV-XVI йөзләрдә оешкан төрки-татарчаның дәвамы булган татар язма телен [40] укытудан башлану да шулай ук очраклылык түгел иде.

Өченчедән, Ә.Кәримуллинның Шәрекъне өйрәнү институты Петербург бүлегендә саклана торган экземпляр буенча манифест теле хакында әйткән фикерләре дә ышандырмый (бу хөкем шулай ук манифестның күптән түгел РДБААда табылган [41] һәм элеккесеннән нибары тугра рәсеме белән генә аерылып тора торган типография вариантына да карый). Автор үзе манифестның «гарәп һәм фарсы сүзләре киң кулланылган югары стильдәге татар телендә язылган» [42] булуына ышана. Мин исә бу очракта безнең алда манифестның татар телендәгесе түгел, ә бәлки төрекчә тәрҗемәсе дигән караштә торам. Чөнки, гомумән алганда, документның теле, грамматик-фонетик формалары, аеруча стиле, шулай ук орфографиясе аны Россиядә Шәрекъ белән язышканда кулланылган традицион төрки-татар теленә түгел, бәлки госманлы-төрек теленә якынайта. Моны күрер өчен, әлеге текстны XVII-XVIII гасырларда Һиндстан, Иран хөкемдарларына, калмык башлыкларына һ.б. язылган патша грамоталарының [43] татарчага тәрҗемәләре белән чагыштырып карау да җитә. Шуңа да мин манифестның Шәрекъне өйрәнү институты Петербург бүлегендә сакланып калган моңарчы «бердәнбер» дип исәпләнгән экземпляры төрек телендә язылган [44] дип раслаган А.Н.Кононов белән килешәм.

Шуның белән бергә бу мәсьәләне мин хәзергә ярым ачык килеш калдырыр идем. Чөнки татар әдәби теле тарихыннан билгеле булганча, күп кенә авторлар үз әсәрләрен «урам телендә» түгел, ә «югары стиль»дә язабыз дип, төрекчә диярлек, ягъни угыз-төрек лексик-грамматик элементларын киң

кулланып иҗат иткәннәр. Мәсәлән, хәзерге халыкчан татар әдәби теленә нигез салучыларның берсе булган Габдулла Тукай (1886-1913) үзенең баштагы әсәрләрен «төрекчәгә якын» дип әйтерлек телдә язган; яңа басмаларда инде аларны хәзерге сөйләмгә яраклаштырырга яисә, гомумән, хәзерге стильгә күчерергә туры килә. Шуңа күрә бу мәсьәлә бик үк җиңелләрдән түгел һәм ул манифестның башка төрки телдәге, ягъни төрки-татарча версиясен тапкач кына тәмам хәл ителер. Ә ул, һичшиксез, табылачак! Чөнки хакыйкый мәгълүмат чыганакларыннан, шул исәптән вакыйгада катнашучыларның (Ф.И.Соймонов) сүзләреннән, «1722 елгы Поход журналы» мәгълүматларыннан (кара: югарыдагы 27-29 искәрмәләр буенча) күренгәнчә, аларда сүз киләчәккә исәпләнгән ният турында гына түгел, ә тулысынча тормышка ашырылган гамәл хакында бара. Манифестның өч телдә — төрки-татар, төрек һәм фарсы телләрендә басылган булуында шик юк. Шунысы кызык: саналган телләрдән «татар теле» беренче урында тора [45]. Димәк, хәзергә әле табылмаган хәлдә калса да, манифестның андый варианты, һичшиксез, булган.

«Татар» манифесты тексты табылмавын шуның белән дә аңлатып булыр иде. Төньяк Кавказ халыкларының шактый өлешенә аңлаешлырак телдә булуы сәбәпле, ул соңгы экземплярына кадәр халык арасында таралып беткән, шуңа күрә Россия архивларында сакланмаган. Әмма мондый нәтиҗә белән дә ашыгырга ярамый. Югарыда күргәнебезчә, төрки телдәге манифестның Петербург экземпляры соңгы елларга кадәр бердәнбер дип исәпләнгән иде, ә хәзер, бары бер мәртәбә максатчан эзләнү оештырылганнан соң, РДБААда аның икенче экземпляры да табылды. Димәк, Россия архивлары да әле тиешле дәрәҗәдә карап-тикшереп чыгылмаган икән.

Сабак алырлык башка мисаллар да бар. Бу язманың кереш өлешендә билгеләп үтелгәнчә, XIX гасырның башында ук Х.М.Френ тарафыннан монголларгача чордагы болгар авторларының хезмәтләрен эзләү башланган иде. «Борынгы язмаларны» эзләү соңрак та дәвам итә (Ш.Мәрҗани, С.Вахиди һ.б.). Ләкин XX гасыр ахырында гына, ягъни ике йөз ел узгач, монгол яуларына кадәр яшәгән болгар авторы Таҗеддин Болгари әсәрләренең текстлары табылды.

Иманым камил, киләчәктә борынгы кульъязмалар саклана торган мирасханәләрне киңрәк күләмдә барлап, эзләнүләрне максатчан рәвештә җәелдергән очракта манифестның башка вариантлары, ягъни төрки-татарча һәм фарсычалары белән бергә башка төрле әһәмиятле документлар да табылачак. Чөнки халкыбыз тарихына нисбәтле истәлекләр бер Россия архивлары белән генә чикләнми.

Кавказ, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре — Иран, Төркия, Сүрия мирасханәләренә дә ирешә алганыбыз юк хәзергә. Шул чор Иран һәм Төркия Тышкы эшләр министрлыклары, разведка хезмәтләре архивларында да бу юнәлештә эзләнүләр бик кызыклы булыр иде. Хәер, Россиянең үзендә дә. Ә эзлисе әйберләр җитәрлек.

Манифестның элекке бердәнбер басма вариантына төрекчә басылган икенче нөсхәнең өстәлүе нәтиҗәсендә киләчәктә эзләнүләр өчен яңа юнәлешләр барлыкка килде. Бу эзләнүләр Фарсы походы заманнары сәясәте һәм кыр типографиясе тарихын, Россиядә беренче мәртәбә шәркый телләрдә басмалар чыгару тәҗрибәсен, шул исәптән төрки-татар телендә хәреф җыеп, текст басуның башлангычын әтрафлы өйрәнү һәм җентекләп тикшерү, аңлау өчен аеруча мөһим.

Хәреф җыюга нигезләнгән төрки-татар басмасы Идел буе һәм Урал алды татарларының һәм элекке СССРда яшәгән башка төрки халыкларның милли китабы тарихының чишмә башын өйрәнү өчен дә зур әһәмияткә ия.

Борынгы акыл ияләре: «Кульъязмалар

янмый», — дип әйткән. Шулай булгач, күптиражлы басмаларның барлык нөсхәләре дә «янып бетәргә» тиеш түгел.

Беренче төрки-татар басмасының моннан 285 елдан элегрәк барлыкка килгән истәлегенә багышланган сүземне мин түбәндәге теләк белән тәмамлар идем: киләчәк буын галимнәренең эзләнүләре тагын да уңышлырак, бу эзләнүләрнең нәтиҗәләре янә дә тизрәк булсын иде!

(июль-август, 2006, февраль-март, 2007)

Искәрмәләр

1. Татар телендәге вакытлы басмаларның катлаулы оешу процессы турында кара: Корбут М.К. Проект первой татарской газеты в Казани // Вестник научного общества татароведения. Казань, 1926. № 5. С. 106-131; Чернышев Е.И. К истории татарской периодической печати в России — проект татарского журнала «Файда» («Польза») // Труды общества изучения Татарстана. Казань, 1930. С. 129-134; Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. Казань, 1971. С. 172-190 (в этом издании опубликованы различные прошения на издание газет и журналов); Усманов М.А. Заветная мечта Хусаина Фаизханова. Казань, 1984. С. 139-166; Он же. Судьба татарской периодической печати в XX столетии // Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX века: библиографический указатель. Казань, 2000. С. 10-33; Амирханов Р.У. Татарская дореволюционная пресса. В контексте «Восток-Запад» (на примере развития русской культуры). Казань, 2002. С. 34-39.
2. Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131-1153 гг.) /публикация О.Г.Большакова, А.Л.Монгайта. М., — 1971. С. 31.
3. Шиһабетдин Мәрҗани. Мостафадел-әхбар фи әхвәл Казан вә Болгар. Казан, 1885.
4. Мәсәлән, Х.М.Френ, К.Фукс, С.Г.Вахиди һ.б. кебек.
5. Таджаддин ал-Булгари. Большой тирйак (Большое противоядие) / издание текста, перевод с арабского, предисловие, комментарий А.Б.Халидова. Казань, 1997.
6. Кара: шунда ук. 12-13 б.
7. Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М., 1960; Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978.
8. Тулырак кара: Алмаз Дж.Д. «Кысса-и Юсуф» ‘Али - булгаро-татарский памятник // Труды XXV Международного конгресса востоковедов. М., 1960; Хисамов Н.Ш. Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Гали. Анализ источников сюжета и авторского творчества. М., 1979.
9. Истәлекнең күп сандагы (160 с. б. артык) элгәреге үрнәк нөсхәләре буенча төзелгән һәм басылган, кулъязма һәм басма күчермәләрен үз эченә алган тасвирламасын кара: Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе). Казань, 1983. С. 426-507. Әлеге басма чыкканнан соң, Казан университетының археографик экспедицияләре тарафыннан ядкәрнең тагын 50 артык яңа күчермәсе табылды һәм тупланды.
10. Бу турыда кара: Усманов М.А. Об особенностях раннего этапа этнической истории Улуса Джучи // Тюркологический сборник — 2001. Золотая Орда и ее население. М., 2002. С. 101-109.
11. Наджип Э.Н. О средневековых литературных традициях и смешанных письменных тюркских языках // Советская тюркология. 1970. № 1; Шул ук. Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV века. М., 1979. Кн. I
12. Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика. Казань, 1993. Бу чор әдәби теле хакында кара: Нуриева Ф.Ш. Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. Казань, 2004.
13. Аерым үрнәкләрне кара: Поэзия Золотой Орды / перевод Р.Бухараева. М, 2005. Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV-XVI вв. Казань, 1979.
14. Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV-XVI вв. Казань, 1979. С. 277-282 (бу дәвернең язма теленә карата «төрки-татар» атамасын куллану турында кара: шунда ук. 176.).
15. Мәсәлән, резолюцияләр: болайунъ гурдук, ягъни «шул рәвештә без хупладык» һәм алтмышда янбар аинда — «алтмышынчы (ел), гыйнвар аенда» бу «дөнья яратылганнан соң» дигән ел исәбе буенча 6960 елга туры килә. Кара: Оболенский М.А. Восточные надписи на старинных русских грамотах // Известия Имп. русского археологического общества. СПб., 1861. Т. П. Вып. 1. С. 22-24. Бу-русча ел исәбе буенча (Усманов М.А. Жалованные акты... С. 112-113).
16. Мәсәлән, Мәскәү акчасы будыр. Ибан. (Савельев П.С. Монеты джучидов, джагатаидов, джелаиридов и другие, обращавшиеся в Золотой Орде в эпоху Токтамыша // Записки Имп. археологического общества. СПб., 1858. Т. XII. Вып. 1. С. 148 һ.б.)
17. Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1.С. 306-307.
18. Кара: Вернадский Г.В. Монголы и Русь. Тверь; М., 2000. (С. 168, 175, 205, 207, 212) һ.б.
19. Белокуров С.А. О Посольском приказе. М., 1906.
20. Рус-шәрекъ язышуы белән бәйле, анда татар теленең урыны, аның Кытай, Һиндстан, Иран, шулай ук грузин, калмык, монгол, ягъни төрки булмаган илләр һәм башлыклары белән элегрәк язышуда кулланылу үзенчәлекләре, шулай ук «Татар канцеляриясе»нә кергән тәрҗемәчеләрнең составы турында документларга күзәтү хакында кара: Усманов М.А. О документах русско-восточной переписки на тюркских языках в XV-XVI вв. и их источниковедческом значении // Восточное историческое источниковедение и специальные исторические дисциплины. М., 1994. Вып. 2. С. 123-138. Андый документларның лингвистик үзенчәлекләре турында кара: Хисамова Ф.М. Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI - начало XIX вв.). Казань, 1999.
21. Описи Царского архива XVI века и архива

Посольского приказа 1614 года. М., 1960. С. 32.

22. Әгәр, Мәскәү һәм Петербург мирасханәләреннән кала, элекке Советлар Союзының башка шәһәр архивларында (мәсәлән, Алма-Ата, Әстерхан, Казан, Махачкала, Омск, Оренбург, Симферополь, Тобольск, Томск, Уфа h.б.) тупланган андый документларны исәпләсәң, аларның гомуми күләме әллә ничә мең берәмлеккә җитәр иде. Усманов М.А. О документах… С. 130-132.

23. Веселовский Н.И. Татарское влияние на русский посольский церемониал в Московский период русской истории. СПб., 1911. С. 1; Шул ук. Пережитки некоторых татарских обычаев у русских // Живая старина. СПб., 1912. С. 27-28.

24. Кононов А.Н. История изучения тюркских языков в России. Дооктябрьский период. 2-е изд. Л., 1982. С. 12 h.б.

25. Алтын Урда язма теленең чыгытай телен формалаштыруда баштагы йогынтысы турында кара: Кононов А.Н. Ценный труд по грамматике староузбекского языка // Общественные науки в Узбекистане. 1963. № 8. С. 65.

26. Наджип Э.Н. Кыпчакско-огузский литературный язык Мамлюкского Египта XIV века: автореф. док. дис. М., 1965. С. 16. Шулай ук кара: Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. Казань, 1972. С. 66-68.

27. Бу хакта киң мәгълүмат: Лысцов В.П. Персидский поход Петра I. 1722-1725. М.: Изд-во МТУ, 1951.

28. Соймонов Ф.И. Описание Каспийского моря и чиненных на оном российских завоевании… СПб., 1763. С. 58; цит. по: Лысцов В.П. Персидский поход… С. 118-119 (безнең тарафтан аерып күрсәтелде. — М.Г.).

29. Тулы мәгълүмат: Корш Ф.Е. Универсалы Петра Великого к буджацким и крымским татарам. М., 1893; Кононов А.Н. История изучения… С. 34-36.

30. Кушева Е.Н., Усманов М.А. К вопросу об общественном строе вайнахов (письмо 1657 г. из Шибутского джамаата царю Алексею Михайловичу) // Советская этнография. 1978. №6. С. 99-110.

31. Усманов М.А. Новый документ о Степане Разине (татарский перевод неизвестной грамоты Алексея Михайловича) // Вопросы историографии и источниковедения. Сб. IV. Казань, 1969. С. 321-328; документ кабат күчереп басыла: Крестьянская война под предводительством Степана Разина: сборник документов. Т. IV, дополнительный. М., 1976. С. 5-7.

32. Усманов М.А. О документах… С. 138. Примеч. № 65. XVII гасырның икенче яртысында Илчелек приказында күп кенә телләрне белүче тәрҗемәчеләр эшләгән. 1689 елда 22 тәрҗемәче исәпләнгән, алардан 8 кеше татар теленнән тәрҗемә иткән, кайбер тәрҗемәчеләр берүк вакытта төрек телен дә белгәннәр (Белокуров С.А. О Посольском приказе. С. 54, 55-57 h.б.). Татар тәрҗемәчеләре Идел буенда яшәгән кардәшләренә кадәр үк Рус дәүләте составына кергән Романов, Касыйм, Темников һәм Кадомнан чыккан татарлардан тупланган (Усманов М.А. О документах… С. 129). Нәкъ менә шуңа күрә төрки-татар телендә язылып, Шәрекъ хөкемдарларына юлланган Мәскәүрус документларында еш кына бары Казан татарлары теленә хас лексик элементлар очрый. Мәсәлән, 1675 елда Һиндстан падишаһы Аурангзебка юлланган, 1695 елда Семен Маленькийга бирелгән патша грамоталарының татар версияләрен бастырганда язуны ачыклаучы (дешифровщик азәрбайҗан Рөстәм Алиев) татар теле өчен гадәти булган **biləmək** (биләү, идарә итү), bülək (бүләк), babamiz (бабабыз) кебек күп кенә сүзләрнең мәгънәләрен аңламый (унбиштән артык шундый сүзләр каршына сорау билгеләре куелган, кара: Русско-индийские отношения в XVII в.: сборник документов. М., 1958. Док. № 114. С. 207-208; Док. № 254. С. 364-365).

33. Манифест буенча аның тикшеренүләре: Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. От начала возникновения до 60-х годов XIX века. Изд. 2-е, неправ. и перераб. Казань, 1992. С. 62-75 (алга таба: Каримуллин А.Г. У истоков [II]…).

34. Галимнең 1995 елга кадәр басылган хезмәтләре исемлеге: Абрар Гибадуллович Каримуллин: библиографический указатель / сост. Р.Х.Тимергалина. Уфа; Казань, 1995.

35. Каримуллин А.Г. У истоков [II]... С. 57-62. Монда шуны да махсус билгеләргә кирәк: бу монографиянең 1971 елда чыккан беренче басмасында (49-50, 59-60 б.) автор 1612 елгы Лейпциг басмасын «беренче татар китабы» рәвешендә тәкъдим итәргә тырышкан иде. Әмма хезмәтнең төзәтелгән икенче басмасында автор ул омтылышыннан баш тартты. Моңа, ихтимал, 1971 елдан соң «милли китап» хакында үзе чыгарган нәтиҗә сәбәп булган булса кирәк.

36. Петр I шәркый телләрдә бастырылган манифесты турында шактый хезмәтләрдә искә алына. Шуларның иң элгәреләре буларак Б.Дорнның «Каталог»ы (Melanges asiatique tires du Bulleten de Г Academie Imperiale des Sciences de St.Petersbourg. T. V. St.Petersbourg, 1868. P. 587) һәм П.П.Пекарский хезмәтендә (История Ими. академии наук. СПб., 1873. Т. П. С. 526), шулай ук В.Пятницкий китабында (К истории книгопечатания арабским шрифтом в Европейской России и на Кавказе //Сб. Публичная библиотека СССР им. В.И.Ленина. М., 1928. Т. I. С. 132-133,153-157). Бу басмаларның яңа замандагы тәфсиллерәк тарихы хакында: Быкова Т.Д., Гуревич М.М. Описание изданий гражданской печати. 1708 — январь 1725 гг. М.; Л., 1955.

37. Каримуллин А.Г. У истоков [II]… С. 75. (курсив минеке. — МГ)

38. Шунда ук. 68-69 б.

39. Белокуров С.А. О Посольском приказе.С. 131-132, 135, 138; Усманов М.А. О документах… С. 129.

40. Кара: Кононов А.Н. История изучения…

41. ТР Милли китапханәсе йөкләмәсе буенча әлеге экземпляр РДБААда И.Мөстәкыймов тарафыннан табылган иде. Шушы документ сакланган — тәрҗемәче Г.Я.Кеер (1692-1740) фонды белән тарихчы Р.Галләм дә танышкан.

42. Каримуллин А.Г. У истоков [II]… С. 71.

43. Басылып чыккан үрнәкләрне кара: Русско-индийские отношения… С. 207-209, 363-365; Усманов М.А. Новый документ о Степане Разине… Архив чыганаклары урында кара: Усманов М.А. О документах… С. 136-137. Примеч. № 51.

44. Кононов А.Н. История изучения… С. 40.

45. Б.Дорн мәгълүматлары буенча (Каталог. С. 587. № 20) 1722 елда рус һәм татар телләрендә башка документлар да басылып чыга (кара: Быкова Т.А., Гуревич М.М. Описание… С. 498. № 34).

БОЛГАРДА ТӨН

Равил Фәйзуллин

Хәрабәләр түбәнәя,
Биегәя Болгар күге.
Зиярәт кылып йөргәннәр,
Ни дисәң дә, барыбер үги.
Монда вәхшәт эзе тирән,
Мыскыллаулар сүздән түбән.
Суда ухылдап чайкала
Ярга бәйләгән көймәм...

ШӘҺРЕ БОЛГАРДА

Роберт Миңнуллин

Карап йөрим изге Болгар җирен,
Үткәннәрне укыйм һәр таштан.
Болгарның бит монда һәрбер ташы
Чал тарихка барып тоташкан.
Мине монда бар да уйландыра,
Бер карасаң, берни ят түгел.
Томырылып чапкан толпарларның
Тояк тавышын эзли бу күңел.
Үткәннәрне эзли, тыңлый күңел.
Ерак калган еллар авазын.
Ә җанымда Болгарстан күргән
Һәлакәтнең тоям газабын...
Әсәрләнеп йөрим мин Болгарда —
Әйтерсең лә мин үз куышымда.
Нәселемнең изге биләве бу,
Шәҗәрәмнең башы шушында.

«Мин чәчәкләр җыям ил туена,
Мин матурлык эзлим гомергә».
Гамил Афзал

Әдәбият

ГОМӘР ДАШКИН ҺӘМ АНЫҢ ШИГЪРИ ИҖАТЫ

Хатыйп Миңнегулов,
Казан федераль университеты профессоры

I

Пенза ягы — электән үк татарлар Ватаны. Заманында ул күпгасырлык төрки-татар дәүләтчелек тарихында мөһим урын тоткан — Хәзәр каганлыгының, Болгар ханлыгының, Дәшти-Кыпчакның әһәмиятле җирләреннән саналган. Алтын Урда чорында исә хәзерге Пенза әтрафлары бу кодрәтле мәмләкәтнең мөһим мәркәзи төбәкләренең берсе була. Сарай шәһәрендә 1303 елда төзелгән коман (кыпчак, татар-фарсы-латин) сүзлегендәге лексик материалларның төп өлеше хәзерге Пенза, Мордовия тарафларында яшәүче мишәр-татарларның телендә саклануы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Бу яклардагы Наручат (Наровчат) шәһәре Үзбәк хан вакытында (1312-1342 елларда идарә итә) Алтын Урда башкаласы вазифасын да үтәп ала. Андагы ташпулатлар, мәһабәт мәчетләр чит ил сәяхәтчеләрен дә сокландырырлык була. Франциска һәм Доминика Пицигани төзегән географик картада (1367) хәзерге Пенза тарафларында латинча «Котоба» дип исемләнгән шәһәр дә теркәлгән. Кайбер галимнәр фикеренчә, бу кала Алтын Урда чорының мәшһүр шагыйре Котбның кече ватаны дип исәпләнә. Бу авторның атаклы «Хөсрәү вә Ширин» дастанында (1342) бу җирлеккә хас сүз-шәкелләр теркәлеп калган. XV-XVI гасырларда бу төбәкләр Казан, Әстерхан калалары белән тыгыз

икътисади, мәдәни, этник бәйләнешләрдә тора. Татар мәмләкәтләре Мәскәү тарафыннан бетерелгәч, Пенза, Мордовия якларындагы милләттәшләребез колониаль изелү, урыслаштыру сәясәтенә дучар ителәләр. Әмма күп югалтуларга да карамастан, аларның зур өлеше үзләренең милли аңын, телен, динен, гореф-гадәтләрен саклый, зур татар дөньясының мөһим бер кыйсеме булып кала килә. Бу төбәктән Муса Акъегетзадә (1864-1923), Заһир Бигиев (1870-1902), Гафур Коләхмәтов (1881-1918), Гадел Кутуй (1903-1945), Кәрим Тинчурин (1887-1938), Әдһәм Тенишев (1921-2004) һ.б. бик күп күренекле зыялыларыбызның чыгуы мәгълүм. XX йөздә биредә татар мәктәп-мәдрәсәләре эшли, татарча гәҗитләр, китаплар бастырыла.

Пенза төбәге шәхсән без фәкыйрегез өчен аеруча истәлекле. Мин биредә хәзер ярты гасырга киткән мөгаллимлек эшчәнлегемне башладым: 1962-1963 уку елында Белинский районы Качкару (Кутеевка) мәктәбендә балалар укыттым.

Пенза тарафларында зур-зур татар авыллары бар. Шуларның иң күренеклесе һәм татар дөньясында иң зурысы — Урта Әләзән (Городище районы). Ул электән үк татарның милли, дини, мәгърифәти үзәкләреннән берсе хисаплана, анда хәзер дә мәдрәсә, дистәдән артык мәчет бар. Авылның тарихы да язылган. Пенза өлкәсендәге 100 меңләп татарның уннан бере диярлек биредә гомер кичерә.

Урта Әләзән, иң беренче чиратта, үзенең тырыш, уңган, булган кешеләре белән мәшһүр. Шундыйларның берсе — Гомәр (үзләренчә, «мишәрчәләп» әйтсәң — Үмәр) Билал угылы Дашкин. Бу — тарихта билгеле атама. Акчурин, Тенишев, Бибарсов, Еникеев, Яушев һәм башка күренекле фамилияләр кебек, Дашкиннар нәселе дә хәзерге Мордовиядәге Темников, Арзамас төбәкләрендәге йомышлы татарлар,

Гомәр Дашкин. 1952 ел

кенәз-морзалар катламына барып тоташа. Чыганакларда бу нәсел шәҗәрәсенең башы итеп 1611 елда вафат булган «Дашка Худяк (Дамат)» күрсәтелә. Д.Пожарскийның 1612 елның 7 августында бирелгән грамотасында Дашка һәм аның улы Сүнчәләй (Сюнчелей) — кенәз, ә башка ике улы (Ишмәкәй, Алмакай) морза дип аталган. Петр I чукынмаган татар морзаларын христианлаштыру турындагы 1713 елгы Указыннан соң, Дашкиннарның бер тармагы чукынып, әкренләп урыслашып китә. Алар арасыннан күренекле шәхесләр дә чыга. Мәсәлән, Константин Сергеевич Дашкин (1858 елда туган) 1911 елда генерал-лейтенант дәрәҗәсен алуга ирешә, күп төрле рәсми бүләкләргә ия була. Дашкиннарның чукынмый калганнары төрле җирләргә, шул исәптән Пенза тирәләренә дә тарала. Боларның да кайберләре морза, дворян дәрәҗәләрен я саклап кала, я кабат алуга ирешә. Гомәрнең әтисе Билал (1870-1930)

Дашкиннарның Ишмәкәй… — Мостафа (1742-1819), Сөләйман (1767-1837) тармагы аркылы килүче нәселдән. Ул мәдрәсәдә белем ала, үзе дә шунда татар һәм гарәп телләрен укыта, дин сабаклары да бирә. Гомәр үз хезмәте белән көн күрүче, шактый укымышлы гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә. Аның туу вакыты рәсми документларда «1912 елның 7 июле» дип күрсәтелә. Ә автор үзе исә дөньяга килү вакытын «1911 ел» дип хисаплый *[«Туган елым унберенче егерменче» йөз елда (гасырда. — Г.Д.)]*. Гомәр кечкенә чактан ук укуга һәвәс була, әтисеннән күп нәрсәгә, шул исәптән гарәп, фарсы телләренә өйрәнә. Туган авылында әүвәл мәдрәсәдә, аннан мәктәптә укый. Бер шигырендә «остазыннан» «Һәфтияке фәза» (ягъни Коръәннең җидедән бер өлешен) өйрәнүен дә телгә ала. Гомумән, ул укуда тырышлыгы белән аерылып тора.

1927 елда Гомәр Дашкин бер төркем якташлары белән Донбасска китә. Шахтада эшләү белән бергә, рабфакта укыта да. Әтисе үлгәч, 1930 елда туган авылына кайта. Шул ук елны авылдашы Зәйнәп Алим кызы Мамлиева белән гаилә корып җибәрә. Аларның тугыз баласы була. Болардан кайберләре (Сәгадәт — 1933 елгы; Сәгыйд — 1937 елгы; Җәгъфәр — 1941 елгы; Рифгать) сабый вакытта ук дөнья куя. Калганнары үсеп, тормышта үз урыннарын таба, халыкка, илгә хезмәт итә. Мәсәлән, 1945 елда (әтисе язуынча — 1946) дөньяга килгән Асият Казан медицина институты һәм ординатурасын тәгәлләп, Республикабызның сәламәтлек саклау системасында табиб (пульмонолог) һәм Яңа бистәдәге поликлиникада баш врач булып эшләде. Аннан Пензага кайтып үз профессиясе буенча хезмәт кылуын дәвам итте. Асият Дашкин югары дәрәҗәле белгеч кенә түгел, ә милли җанлы, зыялы зат та. Казанда вакытта ул мәдәни тормышның үзәгендә кайнады. Татар зыялылары арасында дуслары, танышлары күп иде. Аның хакында «Социалистик Татарстан» гәҗитендә Габделбәр Ризвановның «Дустым Асият» исемле күләмле язмасы чыгуын да хәтерлим. Пензага кайткач та бу абруйлы табиб һәм сәләтле шәхес иҗтимагый, милли, мәдәни тормышның үзәгендә кайнады. Хәзер дә ул игелекле эшчәнлеген дәвам иттерә. Гомумән, Гомәр аганың балалары, нигездә, кешеләрнең сәламәтлеген саклау шөгылен үзләренең профессиясе итәләр: икенче бер улы Зөфәр — табиб, кызлары Сәгадәт (1948 елда туганы), Сания акушерка, шәфкать туташы булып эшли.

Донбасстан кайтып, кабат авылда яши башлагач, Гомәр Дашкин иген дә игә, маллар да асрый, йортлар да сала, хисапчы, кибетче дә булып эшли. Үзенең эш-шөгыльләрен ул шигырьләрендә дә телгә ала:

…Эшләдем, чәчтем, сукаладым, тракторлар белән,

Күп күрәштем авырлыклар, юклык, ачлыклар белән.

Бригадир булып та тагын ничә еллар эшләдем…

Авыр җәрәхәт алып, 1938-1939 елларда урын өстендә дә ята. Армиягә алынмаса да, сугыш чорының бөтен кыенлыкларын күрә. Нахакка гаепләнеп, хәтта ярты еллап Воронеж төрмәсендә дә утырып чыга. Гомәр ага колхозга да 50 нче елларда гына керә. Бу да аңа рәсми хакимиятнең кырынрак каравына китерә. Ул эчми, тартмый, «биш вакыт» намазын укый, гадел, намуслы тормыш алып бара. Әхлаксызлыкка, эчүчелеккә һәрчак каршы була. Динне, мәчетләрне яклап, күп мәртәбәләр партия Үзәк Комитетына, СССР Верховный Советы президиумына хатлар яза. Моның өчен җирле хакимият тарафыннан штрафларга, төрле кисәтү-куркытуларга дучар була. Әмма бу фидакарь һәм игелекле зат туктап калмый: үз мәсләгенә, кыйбласына һәрчак тугрылык саклый.

…Беркайчан да баш имәдем, кечерәймәдем көн-төштә дә,

Чигенмәдем, алга бардым, авырлыклар төшсә дә.

Бу юллар хыял җимеше генә түгел, ә автор табигатенең реаль чагылышы да. Гомумән, Гомәр ага сәләтле, күпкырлы шәхес була. Аның фотография, медицина, бакчачылык белән шөгыльләнүен авыл кешеләре хәзер дә риваять итеп сөйли. Ул авылда беренче булып 1954 елда ук телевизор сатып ала, башкаларга да аларны көйләшә, ватылган вакытта төзәтеп тә бирә.

Гомәр ага, югары уку йортларында белем алмаса да, үзлегеннән укып, күп тармаклардан белем-мәгълүмат туплый. Указлы мулла булмаса да, еш кына мәҗлесләрдә, мәчеттә вәгазьләр сөйли, авылдашларына, якыннарына Коръән серләрен, дини йолаларны аңлата. Авылдагы мәртәбәле аксакалларның берсе, күпләгән оныкларының (17) һәм аларның балаларының (25) хөрмәтле бабасы Гомәр Билал углы Дашкин 1988 елның февраль аенда мәңгелек йортка күчеп китә. Кабере — Урта Әләзән зиратында.

Гомәр Дашкин, башка тармакларда шөгыльләнү белән бергә, язу-сызуга, әдәби иҗатка да вакыт тапкан. Әмма ул аларны бастырмаган, үзе өчен, күңел ихтыяҗы өчен язган. Аның иҗат җимешләре белән якыннары, чагыштырмача тар даирә генә таныш булган. Мөгаен, Билал угылы шигырьләр язу белән бала, үсмер чакта ук шөгыльләнә башлагандыр. Улы Асият искәртүенчә, әтисе бу эшкә 15-16 яшьләрдә керешә. Күп кенә безгә билгеле шигырьләренең ахырына язылу вакытлары куелган. Аларга карап фикер йөртсәң, Г.Дашкин 30 нчы еллардан алып үлеменә кадәр, ягъни ярты гасыр буена әдәби иҗаттан аерылмаган.

Язамын мин, язамын мин, язамын,
Әдиб булып язарга яратамын, —

ди ул бер шигырендә. Мөгаен, бу еллар аның яшәү асылын да чагылдырадыр.

Мин Асият Дашкинны аның Казанда эшләү чорыннан, ягъни 70 еллардан бирле беләм. Сирәк-мирәк булса да, аралашып, хәбәрләшеп торабыз. Узган ел ул әтисенең шәхси архивындагы бер өлеш материалларны, иң беренче чиратта, шигырьләрен, Казанга алып килде дә, аларны карап, бәяләп, мөмкин булган кадәрен гарәп графикасыннан хәзерге язуга күчереп бирүне үтенде. Ул архивтагы язмалар берничә дәфтәргә теркәлгән (бер өлеше — оригиналда, икенче өлеше — фотокүчермәдә). Мәгълүм ки, башка авыллардагы кебек, Урта Әләзәндә дә янгыннар еш булып тора. Аларның кайберләре Гомәр Билал угылы архивында да теркәлеп калган. Мәсәлән, автор *«Утыз икенче ел кергәч, Иляһи бер бәла салды, Бар милкемдәге хәзинәм(не), жаль, Раббым хозурына алды»,* — дип яза. Шушы ук шигырьдә 1933 елның «баш июнендә» бер сәгатьтә авылның ике йөз өе янды» диелгән мәгълүмат та бар. Асият Дашкин әйтүенчә, мондый «пожарлар» вакытында әтисенең күп кенә язмалары янып юкка чыга.

Гомәр Дашкин архивының миңа билгеле өлешендә, әдәби әсәрләрдән тыш, узган гасырның 30-80 елларында теркәлгән башка төр язмалар да бар (алар барысы да диярлек иске имлада). Болар арасында «Коръән»нән өзекләр, гарәп һәм татар телләрендә дини вәгазь текстлары, ислам йолаларын (корбан чалу, ураза тоту...) аңлаткан язмалар, аерым нәсел шәҗәрәләрен, балаларының, туганнарының туган, яшәү вакытын чагылдырган белешмә-мәгълүматлар да бар. «Татар тарихы» дип исемләнгән берничә битлек текст та мәктәп дәреслекләренә, төрле китапларга нигезләнеп, халкыбыз тарихы бәян ителә. Анда Чыңгыз һәм Батый ханнар, Аксак Тимер (Тамерлан), Туктамыш, Иван III һәм Иван IV хакында мәгълүматлар теркәлгән. Автор үзен татарның бер вәкиле буларак тоя, аның дәүләтчелектән, мөстәкыйльлектән мәхрүм ителүен үкенү аһәңендә белдерә.

Г.Дашкин язмаларында җирле төбәк

тарихына мөнәсәбәтле мәгълүматлар да бар. Хәзерге Пенза тарафларында ул элек болгарлар, буртаслар, мукшылар яшәвен искәртә. Алтын Урда чорында биредә шәһәрләр булуын (Наручат, Мухшы һ.б.), аларда мәчетләр, ташпулатлар корылуын да әйтеп китә. Шәхси архивтагы бер өлеш материалларда XVII-XX йөзләргә кагылышлы тарихи, икътисади, дини-мәдәни факт-мәгълүматлар теркәлгән. Автор фикеренчә, Әлзән XVII-XVIII гасырларда ныклап үсеп китә. Аның бер өлеш халкы Арзамас, Алапаев якларыннан XVII йөзләрдә үк бирегә күчеп килә. Үзенең туган авылында ул 1900 елларда — 550, 1935 елда —1012, 1947 елда 850 хуҗалык булуын әйтә. Ватан сугышында 350 әлзәнле катнаша, күпчелеге төрле бүләкләргә ия була.

Г.Дашкин язмаларында авыл тормышындагы аерым вакыйгалар, мәчет-мәхәлләләр һәм имамнар хакында белешмәләр, якташларының эш-шөгыльләре (иген игү, мал асрау, һөнәрчелек...) хакында да фикерләр әйтелгән. Хәтта «Себергә, каторгага сөрелүчеләрнең» дә кайберләре телгә алына. Юкарак кына бер дәфтәрдә «Йокы һәм төш күрү» темасы яктыртыла. Шәхси эчтәлектәге берничә хат та бар.

Г.Дашкин архивындагы бу төр язмаларны һәм әдәби әсәрләрне күздән кичергәч, бу затның шактый белемле, мәгълүматлы, күзәтүчән, кызыксынучан кеше булуына янә бер мәртәбә ышанасың. Язма теле дә ярыйсы гына. Нигездә, ул XX йөз башы татар әдәби теле традицияләренә таянып эш итә. Гарәп, фарсы, төрки сүзләрен дә белеп, урынлы куллана. Шуның белән бергә Г.Дашкин язмаларында сөйләм теленә, аеруча шул тараф шивә-диалектына хас сүзләр һәм шәкелләр, урыс теле алынмалары да күзгә ташлана.

II

Г.Дашкинның минем кулдагы язмаларының төп өлешен шигъри текстлар алып тора. Алдан ук шунысын да искәртик: бу зат профессиональ шагыйрь түгел, әйткәнебезчә, аның парчалары, минем белүемчә, басылмаган да, тәнкыйди иләктән үткәрелеп тикшерелмәгән дә. Алар, кыскартуүзгәртүләргә дучар булмыйча, башкалар тарафыннан редакцияләнмичә, ничек язылган, шулай сакланган. Әлеге хосусиятләре белән аның шигырьләре нәшер ителгән язмалардан теге яки бу дәрәҗәдә аерылып та тора. Чөнки алар як-якка каранмыйча, цензура, рәсми мөхәррир киртәләрен уйламыйча, иҗат ирегенә, күңел ихтыяҗларына тугры калып язылганнар. Бу сыйфатлары белән «пензяк» шагыйренең парчалары мөһаҗир татарларның, җөмләдән Финляндиядә яшәп иҗат иткән Хәсән Хәмидулланың (1900-1988) әсәрләренә дә охшап китә.

Гомәр Дашкин шигырьләре, гәрчә аларда объектив һәм субъектив характердагы аерым җитешсезлекләр (рифма һәм ритм төгәлсезлекләре, тел-стиль кытыршылыклары, фикри буталчыклыклар, кабатланулар...) булса да, гомумән алып караганда, укучылар, әдәбият тарихын өйрәнүчеләр, рухи мирас белән кызыксынучылар өчен билгеле бер әһәмияткә ия. Шулай ук бу парчалар үткән тормышны, шул чор кешеләренең, шул исәптән авторның да рухи халәтен, шатлык-кайгыларын, мәшһүр Әлзән төбәгендә яшәүчеләрнең тереклеген, гореф-гадәтләрен, телен танып-белү ягыннан да дикъкатькә лаек.

Гомәр Дашкин шигырьләренә нинди сыйфатлар хас соң? Хәзер аларның кайберләренә кыскача гына тукталып китик.

«Пензяк» шагыйренең әсәрләре идеятематик яктан шактый бай. Аны инсан рухы, кеше яшәешенең, милләт, ил,

җәмгыятьнең төрле мәсьәләләре, факт-күренешләре борчый; автор алар хакындагы уй-кичерешләрен, эмоциональ һәм фикри бәя-мөнәсәбәтләрен шигъри юлларда белдерергә омтыла.

Мәгълүм ки, совет чоры басма әдәбиятында XX йөз башы сүз сәнгатенә хас булган милли мотивлар чагыштырмача кими һәм хәтта югала да бара. Г.Дашкин шигырьләрендә исә татар тематикасы, милли хәят шактый зур урынны били. 1934 елда иҗат ителгән «Ярлылык(ның) башы нәрсәдә?» шигырендә автор, мәгърифәтчелек рухында: *«Милләтемез тора калып, Алга илтүче юк алып», «Кызганыч милли хәлемез»,* — дип искәртә, гафләт йокысыннан уянырга чакыра. «Аңла, татар» исемле парчасында (ул сугыштан соңгы елларда язылган булса кирәк) шагыйрь милләт язмышын аның газиз теле белән тыгыз бәйләнештә карый; милли тәрәккыяткә иман-ышанычын белдерә.

Әй татар, булдыклы татар, килмәсен сезгә хәтәр,
Юкмы арагызда дошман — булса, ул сезне сатар.
Иң җитешкән өлге — инсан — хәятыңны беләсең,
Кызганыч, телен югалта, татар була керәшен.
Татар теле — кыйммәтле тел, дөньяда юк мисле аның,
Тел күтәрә иң югары тәхетенә дөньяның...

Юк, синең яшерен татардан гади халыктан сере(ң),
Син, татар, сөй үз телеңне мәрҗан кеби һәрбере.

Бабаларымыз изелгән, булып замана коллары,
Әле безгә бу көн ачык теләсәң күк юллары.

Социализм чорында, бигрәк тә 30 нчы еллардан башлап, илдә дингә каршы көрәш чын мәгънәсендә көчәя. Басма сүз сәнгатендә ул аеруча калку гәүдәләнә. Г.Дашкин — дини, милли тәрбия алган зат. Бу сыйфатларына ул һәрчак тугры кала. Хәтта атеизм котырган елларда да дингә тел-теш тидерү юк. Киресенчә, автор Аллаһны зурларга, үз тереклегеңне ислам кануннары нигезендә алып барырга чакыра. Аның «Дога» шигыре чын мәгънәсендә Аллаһка хөрмәт, ялвару, аннан рәхим-шәфкать көтү рухы белән сугарылган. 8 строфалык бу парчаның һәрберсендә «Иляһи» сүзе телгә алына, аңа мөрәҗәгать ителә:

Йа Иляһи, кул күтәреп, нечкә күңел, яшь белән,
Каршыңа килдек, Йарабби, рәхмәтең теләп синдән.

...Йа Иляһи, бу галәмдә хәлләремез аяныч,
Сач гыйбрәт илһамыңны синдә генә таяныч...

Шагыйрь фикеренчә, динсезлек, имансызлык һәртөрле әхлаксыз эшгамәлләргә китерә. Авторны аеруча совет чорында киң колач алган хәмер эчү, зина кылу кебек күренешләр борчый. «Шәйатыйн (шайтаннар) кемнәрне үзенә ияртә» шигырендә ул җиһанны «исереклек туе», «аракы, зина, усал сүз» каплап алган, ди. Мондый хәлдән котылуда шагыйрь Аллаһтан ярдәм сорый. Автор күзаллавында дини һәм милли барлык бер-берсе белән тыгыз бәйләнешле:

Укы намаз, шаулап азан.
Яңгырасын милли ягаң.

Белем-мәгърифәтне зурлау, матур әхлакый сыйфатларны мактау, аларның капма-каршылыкларын тәнкыйтьләү татар сүз сәнгатендә элек-электән күзәтелә. Г.Дашкин да бу төр традицияләрне дәвам иттерә. Аның карашынча, белем — чын «дус», «тормыш бирүче», «шатлык» китерүче, «наданлык» исә «ярлылык җимешен» бирүче, бер «егач тик». Мәктәп — балага белем-тәрбия бирүнең төп учагы. Әмма әле ул, шагыйрь уйлавынча, үз вазифаларын тиешенчә үтәми. Хәзерлексез, тупас, исерек мөгаллимнәр,

ришвәтчелек укучыларга тискәре йогынты ясый, алар бозыла, шуның нәтиҗәсендә җәмгыятьтә исереклек, зина кылу, караклык кебек күренешләр киң тарала. Бүгенге тормышта да күзәтелә торган «диплом сатып алу»га да авторның карашы тискәре:

Сатып алган диплом, аңла, наданлыкка ишарә,
Укып надан калдырган учительләргә ләгънәт, нәләт (1977 ел).

Шагыйрь үз укучыларын гадел, намуслы, шәфкатьле, бер-берсенә дус булырга өнди:

...Усаллыкны читкә ташла,
Кара эчеңне кыл ап-ак.

*****
Иптәшкәем, бир кулыңны, яңадан дуст булаек,
Дошманлыкны кырып түгеп, дустлык белән тораек.

Дустларым меңләп булса да, һаман тырышам көн дә,
Дустларым артсын диеп көндә, дошман калмасын кем дә...

Теләсә нинди чор, кыйтга, ил, халык, җәмгыять яшәешенең нигезен, асылын тәшкил иткән хезмәттән, гомере буе эш-шөгыльдән аерылмаган Гомәр Билал углы да үз уйлануларын, фикеркичерешләрен бәян итә. Бер шигырен ул мондый юллар белән башлый:

Яшь идем мин, яшь чагымда иген эшен эшләдем,
Ат, сука, чалгы, урактан башка корал ишетмәдем.

Аерым парчаларында шагыйрь һөнәрсезлекне, ялкаулыкны бәхетсезлекнең, фәкыйрьлекнең, көферлекнең нигезе дә дип карый:

...Һөнәрсез дөньяда ач,
Чын мәгыйшәткә ул мохтаҗ,
Дин гыйлемен белмәгәннән кач, —
Көферлеккә чумма инде.

Гомәр Дашкин аерым тарихи вакыйгаларны, иҗтимагый факт-күренешләрне дә читләтеп үтми. 1943 елның гыйнвар башында, ягъни сугышның иң каты чорында ул үз көндәлегенә мондый парчаны теркәп куя:

Уйнамаска, көлмәскә халык күзе яшьле чакта,
Туганнар дошманга каршы елап сугышкан чакта.

Сугыш сафында үсмерләр унар меңләп үлгәндә,
Кемнәр гаклы бар әйтер шул вакытта көлгәнгә.

Бу юлларда автор ил белән безгә сулаучы, аның кайгы-газапларын үзенеке итеп тоючы ватанпәрвәр, халыкпәрвәр буларак чыгыш ясый. «Тарих» шигырендә Россиядәге ачлык елы (1921 ел күздә тотыла), аның коточкыч афәтләр китерүе рәсемләнә. Парча бик тә аянычлы, үкенечле фикер белән төгәлләнә:

...Каршы елы зур уңышлар бик халыкны шатлаган,
Лик (ләкин. — Х.М.) халыкның ул бәхеткә яртысы да калмаган.

«Әләзәнлеләрнең киләчәге» әсәрендә Иван Грозныйның татарларны тар-мар итүе, аларның «тәрәккыять юлына» төрле «киртәләр салуы», милләттәшләребезне таркатуы, урыс, мордвалар белән катнаштыруы, «урыс нәзарәте астында сәяси кол итәргә» омтылуы гәүдәләндерелә.

Гаилә — хезмәт кебек үк, кешелек җәмгыятенең һәм инсани тереклек дәвамчанлыгының нигезе, төп буыны. Бу мәңгелек мәсьәлә дә зур гаиләдә туып-үскән, үзе дә дистәләгән баланың, күпләгән оныкларының атасы, бабасы булган Г.Дашкин шигырьләрендә чагылыш таба. Бер парчасында ул әткәйәнкәйләр булуны, хатының («иптәш») белән гомер кичерүне «табигый бәхет» дип саный, буыннар дәвамчанлыгын «алмагач»ның алма бирүе белән чагыштыра. Шагыйрьнең «сөекле балалары» Сәгыйд белән Рифатка багышлап язылган мәдхия-мәрсиясе дә самими хисләр, чын сөю-ярату тойгылары белән суга-

рылган. Автор аларны үзенең «бәгырь җимеше», «былбылы», «сандугачы», «шадлыгы» дип атый.

...Мин синең һәрбер сүзеңдән мәгънә, гайрәт алып,
Икъбалга (бәхеткә, киләчәккә. — Х.М.) салдым эзләр, гайрәтемдән шатланып.

***

...Туймадым күзе нуры
Туяр кадәр карамадың.
Аһәңлелек шатлыкларыңа
Безне дә туйдырмадың...

Гаугалы гаиләләрне, исерек һәм тугрылыксыз ир-хатыннарны, ата-анасы була торып, ятимлек язмышына дучар ителгән балаларны күреп, шагыйрьнең йөрәге телгәләнә. Шундыйларның берсе исеменнән язылган әсәрдә мондый әрнүле юллар бар:

Кем мин, нинди аталамын, мин бит юктан килмәгән,
Атасыз-анасыз диеп әйтмәсен кем белмәгән.
Әтием эчкегә баткан, әнием Мәскәүгә качкан,
Исереккә әнием үзе үләнүгә (өйләнүгә. — Х.М.) юл ачкан...
...Әтием эзли хатын, тикшереп ил марҗасын,
Прокатка түләп бетерә нибар таптан акчасын...

Бу хәлне кәгазьгә теркәгәннән соң, автор үз исеменнән мондый нәтиҗә ясый:

...Күпчелекнең гомре үтә, сөешергә кемнедер көтә-көтә,
Туза үзе, бәхте кача, картлык белән үлем җитә.

Күп кенә башка каләм әһелләре кебек, Г.Дашкин да туган авылы хакында үзенең фикер кичерешләрен бәян итә. Аның 1947 елда язылган «Авыл халкыма» шигыре туган төбәгенә, аның кешеләренә ихтирам, хөрмәт хисләре белән сугарылган. Кече ватанын бәхетле, аңлы, нурлы итәр өчен, автор, гәрчә каршы төшүчеләр булса да, бөтен «җанын», «кодрәтен» бирергә әзер:

Әй сөям сине, Әләзән, җан куяр идем сиңа,
Ни сәбәптер каршы төшә күп вакыт халкың миңа.

Аттырыр идем, Әләзәнем, өстләреңә нурлы таң,
Үстереп кояш нурыннан башларыңда көчле аң.

Никадәр бар миндә кодрәт, шул кадәрле эш бирәм,
Мин аларга нур чәчеп, бәхет дигән иген бирәм.

Гөлләренә су сибәм, нәфис хуш исләр иснәтәм,
Мәңгелеккә алар өчен мин исле гөлләр үстерәм...

Һәрбер инсан — анабыз Табигатьнең баласы. Бу хакыйкатьне Г.Дашкин да тирәнтен тоя. Аның өчен аеруча кояш якын. «Җир кояшы» шигырендә ул, мәсәлән, табигатьнең бу җисемен, борынгы мифлардагы кебек, изгеләштерә, аны бөтен тереклекнең, матурлыкның чыганагы дип карый:

...Тыгыз болытларны сөзеп, кояш чыгып нурын сибәр,
Мәңгелек бозлар эреп, сулар китеп, җире кибәр...

Шул вакыт гөлләр үсеп, атыр алар матур чәчәк,
Чәчеп алар нәфис исләр бөтен илдә исәчәк...

«Җәйдән файдаланып» парчасында автор «кояш чыгу»ны, «матур язны» мактый да, табигатьнең бер җимеше булган адәм баласына дәшеп, болай ди:

...Хисләреңне уят, тарат,
Җәй нурлары белән агарт.
Тәнең саулык белән җәен,
Гаклың шатлык белән тазарт.

Г.Дашкин, башка күп кенә каләм әһелләре кебек, мәхәббәт темасын да читтә калдырмый. Аның бу төр парчаларында, яшь-җилкенчәккә хас хисләр белән бергә, ир белән хатын

мөнәсәбәтләре дә гәүдәләнеш тапкан. Автор мәхәббәткә корылган гаиләви тормышны, балалар үстерүне кеше өчен бәхет, рухи комфорт дип саный.

Г.Дашкинның әдәби мирасында башка темаларга язылган шигырьләр дә бар. Хәтта ул, Ибне Синаның синкретик традицияләрен дәвам итеп, тыйбка (медицинага, дәва-шифага) мөнәсәбәтле фикерләрен дә тезмә юллар белән белдерә. Мәсәлән, бер парчасында шагыйрь витаминның балалар өчен кирәклеге, аның A, B, C, D төрләре нәрсәгә файдалы булуы хакында яза:

...Витамин A үстерә, буй-әгъзаларны ныгыта,

B дигәне ми үстереп, нервларны ныгыта...

Г.Дашкин олыгая барган саен яшәү һәм үлем, тереклек мәгънәсе кебек фәлсәфи мәсьәләләр турында күбрәк уйлана башлый. Кайбер парчаларында хәтта ул үзен хыялый рәвештә якты дөньяда гүя «ахыры» көнен уздыручы, китеп баручы рәвешендә күзаллый, табигать, гаиләсе, таныш-белешләре белән бәхилләшә. Үлеменә өч ел кала язылган бер шигырен ул мондый юллар белән башлый:

Көн бетә, күренә килә шәфәкъ таңы да иңә,

Истә калыр үткән эшләр төштә күренгән тик кенә.

Һәркемнең гомере чикле, үлем котылгысыз. Шуңа күрә һәр инсан Ходай Тәгалә тарафыннан үзенә бирелгән гомерне «тырышып», башкаларга «сүзләре», «эше» белән үрнәк булырлык итеп яшәргә чакыра:

Ил кашында иң сөекле, иң бәхетле шул кеше:

Илдә үрнәк йөрсә аның сүзләре һәм дә эше;

Макталу, изге булып, һәркем аны искә алыр,

Күп халык үрнәк алыр, үзләре дә макталыр.

«...Тырышлык — бетмәс исем» дип аталган бу шигырь Йосыф Баласагунлы, Сәйф Сараи, Габдулла Тукайлар җырлаган «камил инсан», «игү ат», «гүзәл эз» калдыру мотивларына авазлаш юллар белән төгәлләнә:

...Ул тырышлык аркасында «чын кеше» исмен алыр,

Үзе төзеп мәңгегә тере булып исме калыр.

***

Г.Дашкин шигырьләренең күпчелеге лирик эчтәлектә. Арада лиро-эпик характердагы язмалар да очрап куя. Шундыйларның берсе – «Сәяхәтем» әсәре. Анда каһарманның төшендә күргән-кичергән хәлләре, кичерешләре бәян ителә. Сәфәр алымын куллану авторның кайбер башка шигырьләре өчен дә чит түгел. Кайбер әсәрләре әңгәмә-диалогка корылган. Мәсәлән, бер язмада ата һәм бала әңгәмәсе аркылы тормыш тәҗрибәсе, әхлакый һәм инсани кыйммәтләр гәүдәләндерелә. Шагыйрь иҗатында робагый (дүртьюллык), фәрд (икеюллык), мәдхия, мәрсия, хат, пейзаж лирикасы, эпиграмма, мөнәҗәт һәм кайбер башка жанрдагы әсәрләр бар. Урыны белән сатирик һәм юмористик табигатьтәге парчалар да, бәет-җырларга тартым, аларга иярү, «стилизация» рәвешендә язылган юллар да күзгә ташлана.

...Тагын җырлыйм бер генә җыр шушы кызга карата,

Татлы ашарга, аз эшләргә, күп йокларга ярата.

...Носовой платокларым: берсе аклы, берсе күк,

Теләгән иптәшем бер син, теләмәгәнем илдә күп...

***

Тилегә сез ни барыгыз гаклы юк дип әйтәсез,

Ишетә дә тагын тилерә, гакыл юлын бигәйтәсез.

***

...Хурлый башласаң иреңне, аузың күбекләнә,

Котырган эт тик ырлап юк-барын эзләкләнә...

Г.Дашкин шигырьләре, нигездә, ике-юллык һәм дүртьюллык строфалар белән язылган. Тәүгеләре аа бб рәвешендә кафияләшкән. Ә дүртьюллык строфаларда рифмалашуның абаб, абвб, aaaб һәм башка төрләре күзәтелә. Мәсәлән, «Ярлылык башы нәрсәдә?» шигыре aaaб вввб... шәкелендә рифмалашкан. Шигъри үлчәмнәрдә дә төрлелек бар. Күбрәк 15-15, 8-8 иҗекле строфалар өстенлек итә. Арада гаруз, ягъни классик шигырь белән язылган әсәрләр дә шактый. Шигырьләрнең бер өлеше төп эчтәлеккә, мәгънәгә туры килешле атамалар белән исемләнгән. Аерым парчалар хикмәтле сүз әйтүгә, афористик фикерләүгә корылган.

Йокы алмый кешене, кайгы керсә эченә,

Борча тешләгән шикелле төн каталап (төн буенча. – Х.М.) кычына...

***

...Табигатьтә һәр бала тик тумаган юк булмаган,

Тәрбия булмаса, мәгълүм, ул бала кала надан...

Гомәр Дашкин, гәрчә матди тереклекнең исәпсез-хисапсыз эш-мәшәкатьләре белән мәшгуль булса да, гомере буе әдәби иҗатына хыянәт итми, аңа тугры кала. Шигърият, язусызу — аның өчен күңел канәгатьлеге, куаныч-шатлык бирә торган бер дөнья. Бу хакта, мөгаен, авторның үзеннән дә артык әйтеп булмый торгандыр.

Укысам бер язу, дөнья иңәм (иңлим. — Х.М.),
Гизәм дөнья, ахирәткә дә тиенәм.

Ниләр килми, ниләр булмый кашымда (каршымда. — Х.М.),
Бары көләм, якты уйлый башым да.
Менәм аена, һава эчендә йөзәм,
Чыдыйм куркынычларга да – түзәм.

Шулар бары күз алдымда, юлымдин,
Чыга алар шигырь булып каләмдин.

Гомәр Дашкин шигърияттә, әлбәттә, югары дәрәҗәләргә ирешә алмаган. Әмма аның бар булган иҗаты ихласи, табигый-тормышчан. Шагыйрьнең теләк-максатлары изге, игелекле: илгә, халыкка хезмәт итү. Аның «Теләк» исемле парчасы (1947) бу хакта ачык сөйли:

Күңлем уйлап,
Телем сөйләп,
Кулым язган
Көйле җөмләләрем
Ил каршында шифа булып
саналсын.
Җаным сөйгән
Ил халкының
Зиһененә
Шигырьләрем
Якты йолдыз булып нур салсын!

***

Озакламый тууына 100 ел тулачак Гомәр Дашкинның күләмле генә язма мирасында идея-сәнгати яктан төрле дәрәҗәдәге шигырьләр бар. Кабатланулар, тупасрак сүз-гыйбарәләр дә очрап куя. Аерым язмалар үтә дә шәхси характерда. Биредә исә без игътибарга лаеклы шигырьләрне сайлап алырга тырыштык. Әйткәнебезчә, Г.Дашкин әсәрләренең барысы да диярлек иске имла белән шул чор орфографиясенә туры китереп язылган. Хәзерге графикага күчергәндә, аларның оригиналда язылыш үзенчәлекләрен өлешчә сакларга тырыштык. Авторның язу рәвеше (почеркы) урыны белән уку өчен чагыштырмача авыр. Фотокүчермәдә бирелгән аерым текстлар тонык, хәтта кайчак алардагы аерым юлларны укып та булмый. Шул сәбәпле, бер графикадан икенчесенә күчергәндә, аерым төгәлсезлекләр китүе дә табигый. Мондый җитешсезлекләр өчен укучыдан алдан ук гафу үтенәбез.

Гыйнвар, 2012 ел.

УЙГАНУ ВӘ ЯҢАЛЫК ТАРИХЫ

Ризаэтдин Фәхретдин

Игътибарыгызга танылган татар мәгърифәтчесе, тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, «Шура» журналының баш мөхәррире Р.Фәхретдиннең «Уйгану вә яңалык тарихы» исемле күләмле мәкаләсен тәкъдим итәбез. Мәкалә 1913-1914 елларда 5 санда басылып чыккан һәм билгесез сәбәпләр аркасында хәзерге заман укучысы игътибарыннан читтә кала килгән. Р.Фәхретдин бу мәкаләсендә татар мәгарифе тарихын, аеруча аның кадимчелек чорын, үзенең хатирәләренә, замандашларының сөйләвенә, төрле шәхси хатларга нигезләнеп яктырта. Моннан тыш мәкаләдә уку-укыту системасында булган җитешсезлекләрне тәнкыйтьләү, фәлсәфи уйланулар, укучыга карата риторик сораулар бирү урын алган.

Галим татар халкының гыйльми үсешен 1880 елга кадәр «схоластика» һәм аннан соңгы чорны «интибаһ», ягъни «уяну» һәм «яңару» дәверләренә бүлә. Мәгълүм булганча, 1874 елда мәгърифәтче Исмәгыйль бәк Гаспринский чит илләргә сәяхәтеннән соң, Бакчасарай шәһәренә кайтып, Зынҗырлы мәдрәсәсендә яңа метод буенча укыта башлый. Нәтиҗәдә, иске иҗек методы белән икешәр ел буе хәреф танырга өйрәнгән шәкертләр, аваз ысулы белән ике-өч ай эчендә укырга-язарга өйрәнгәннәр. И.Гаспринский 1880 елларда Казан каласында була, ә 1883 елдан башлап беренче төрки-татар газетасы «Тәрҗеман»ны чыгара башлый. Нәкъ шул еллардан, аның идеяләрен татар милли буржуазиясе һәм зыялылары күтәреп ала, татарлар арасында җәдидчелек хәрәкәте барлыкка килә. Р.Фәхретдин «Уйгану вә яңалык тарихы» исемле мәкаләсендә, нигездә, кадими мәктәп һәм мәдрәсәләрне, аеруча, шәкертләрнең берничә еллар буе язуга өйрәнүләрендә сүз, тамыр, кушымча һәм иҗекләрдән торган хәрефләр комбинациясен ятлауларын, мөгаллимнәрнең имамлык-мөәзинлек эшенә сәләтсез булуларын, мәктәп-мәдрәсәләрдә дәрес аз укылып, гыйлем дә шуңа нисбәт белән аз бирелгәнлеген тәнкыйтьли. Автор язуынча, кадими мәдрәсәләрдә шәкертләр язуны, тәһарәт вә намаз рәвешләрен бер-береннән күреп кенә белгәннәр. Боларга бәйле кадими мәктәп-мәдрәсәдә укучыларга тәҗвид белән Коръән укуга, догаларны дөрес кылуга әһәмият бирелмәүдә бик күп карт муллаларны наданлыкта гаепли. Р.Фәхретдин билгеләвенчә, унбер ел гына түгел, хәтта егерме бер ел торып та язу-сызу, динне яхшылап белми дөньяга чыгу зур гаеп саналмаган. Шундый кадими мәктәп-мәдрәсәләрдә Утыз-Имәни, Мәрҗани, Курсави, шул исәптән, Р.Фәхретдин кебек галимнәребезнең ничек «дөньяга күзләре ачылган» соң? Р.Фәхретдин моның сәбәбен аларның программадан тыш өстәмә китаплар укуларында, гыйлемле остазларга очрауларында, сәләтле, тырыш булуларында күрә, «Габделхәбир, Хөсәен Фәезхановларның Габделхәбир вә

Хөсәен булуларына Мәрҗани сәбәп булса, Мәрҗанинең Мәрҗани булуына Хөсәеннәр, Габделхәбирләр сәбәп булуында да безнең шөбһәбез юк», — дип яза. Бу урында шунысын да искә төшерү урынлы булыр: Р.Фәхретдин — гыйлемне шул заманнар өчен популяр Урта Азия, Мисыр һәм Төркия илләреннән түгел, ә бары тик җирле татар мәктәп-мәдрәсәләреннән алып, бөек галим, мәгърифәтче булып җитешкән шәхес.

XX йөз башы татар әдипләре әсәрләренә нигезләнеп, кадими мәктәп-мәдрәсәләргә катгый тәнкыйть күзлегеннән генә карарга ярамый. Бу мәдрәсәләр заманы өчен татар зыялылары тәрбияләүдә мөһим роль уйнаганнар. Тарихи чыганаклар һәм әдәбиятта XIX гасырның беренче яртысында кадими мәдрәсәләрдә татар, гарәп, фарсы телләрен, дин дәресләрен, Коръән укыту өстенә, арифметика, геометрия, физика, астрономия нигезләрен, Аристотель философиясен өйрәнүләре, мөселман халыкларының тарихын тикшерүләре, төрле дини йолагадәтләрне укытулары турында языла. Кадими мәдрәсәләрдә йөзләрчә китап укылган, Кышкар мәдрәсәсе мантыйк (логика) фәне, Сатыш авылы нәхү (синтаксис) белән дан тоткан, ягъни шул тармакта махсуслашканнар. XIX йөзнең беренче яртысында Казан университеты профессоры, татар халкының этнографиясе, гореф-гадәтләре белгече, танылган врач Карл Фукс татар халкының укымышлылыгы турында: «Читтән килгәннәргә Казан татарларының хәтта кайбер Аурупа халыкларына караганда да белемлерәк икәнен белү сәер тоеладыр. Укый-яза белмәгән татарны үз милләттәшләре дә санга санамый. Һәм ул гражданин буларак хөрмәткә лаек була алмый», — дип яза. Шунысын да әйтергә кирәк: татар халкы кадими китаплардан Болгар дәүләте чорыннан ук гыйлем алган, яшәү серләренә төшенгән, ә шул ук вакытта урыс мәктәпләрендә, галимнәр язуынча, бердәнбер ике уку китабы — «Часословец» һәм «Псалтырь» булган. 1907 елда профессор А.С.-ов тарафыннан урыс классик гимназияләре турында менә нилəр языла: «Хәзерге урта мәктәпнең иң аяныч ягы — укучы яшьләр арасында белемгә омтылучанлыкның тулысынча җуелуы. Барысы да, әйтерсең, класстан класска күчү максатыннан, канәгатьләнерлек балл өчен генә укыйлар... Гимназияләрнең чыгарылыш имтиханнарына кереп карагыз: бередә 8 ел укуның аяныч нәтиҗәләреннән мәгълүматлы кешенең коты алыныр иде. Һәм менә шушы аңгыралар университетлар һәм башка уку йортларына юнәләләр; биредә алар беренче адымнарыннан ук үзләренең тулы хәзерлексезлекләрен тоя башлыйлар һәм иң гүзәл яшьлек елларын харап иткән урта мәктәпкә ләгънәт укыйлар. Барлык бу гаепләрне без тулысы белән урта мәктәпнең үзенә кайтарып калдырабыз. Чөнки ул балаларда теләсә нинди фәнни кызыксынуны басып-томалап тора». XX йөз башы урыс гимназиясен тасвирлаган бу кимчелекләр, Р.Фәхретдин язган XIX гасыр башы һәм уртасындагы кадими мәдрәсәләрнекенә охшаш. Шунысын да әйтергә кирәк: революциягә кадәр төбәгебездәге мари кебек угро-фин халыклары уку-язуны бөтенләй белмәгәннәр. Күрүебезчә, татарлар уку-укыту җәһәтеннән Россия империясе милләтләре арасында иң алдынгылардан булганнар. Р.Фәхретдин искәртүенчә, шәкертләрнең 20 ел кадими мәдрәсәдә ятуларына сәбәп — берәр мәхәлләгә мулла булу теләге, «карт меллаларның дөнья куюларын вә яки указлары алынуны дүрт күз берлә көтеп торулары» белән бәйле булган. Алар «гыйлем алып» кара дөнья эшләре, игенчелек, сәүдәгәрлек белән шөгыльләнүне зур фаҗигагә, түбәнгә төшүгә тиңләгәннәр.

1874 елгы хәрби закон буенча мөселманнар да руслар белән бергә гаскәри хезмәткә алына башлый. Нәкъ менә шул канунның тәэсире, Р.Фәхретдин фикеренчә, татарларның уянуына иҗтимагый инкыйлаб тарихында беренче адым булган. Бу законның йогынтысы түбәндәгечә чагылыш таба: 1879-1880 елларда гаскәр хезмәтеннән татар солдатлары дөнья күреп, русчага берникадәр өйрәнеп, шактый җитдиләнеп кайтканнар. Әмма аларны мәгърифәткә кертеп җибәрер өчен Россия мөселманнары арасында уңдырышлы җирлек булмаган.

1888 елның июль аенда игълан ителгән фәрман буенча шәһәрләрдә ахун һәм хатип урыннарына керүчеләр өчен русча уку-язу, авылларда имам булучылар өчен бераз русча сөйләшә һәм дә укый белү шарт итеп куела. Әлеге канун шактый бәхәсләр тудырса да, мулла булырга җыенучы татар шәкертләре, шәһәрләргә, рус авылларына китеп, русча

укырга-язарга өйрәнә башлаганнар. Бу канун татарларның уяну дәверендә икенче этап булырлык файда калдырдымы, юкмы? Сорауны автор «Шура» укучылары өчен ачык калдыра.

Шулай итеп, Р.Фәхретдин татар җирлегендәге проблемаларны «эчтән» күрә, тасвирлый, тәнкыйтьли. Шунлыктан аның бу мәкаләсе милли мәгарифебез һәм иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүдә мөһим чыганак булып тора.

Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН,
басмага әзерләүче текстолог

I

«Өммәтләр өсләренә килгән инкыйлабларны халыклар түгел, бәлки заман ясыйдыр», — диләр. Бу сүз дөрес булса кирәк. Милләтләр башына килгән инкыйлабларның тарихлары, сәбәпләре тикшерелсә, иң беренче гамәл заман булуы күрелер. Соңгы вакытларда без — Русия мөселманнары өстенә дә зур бер инкыйлаб килде. Моның сәбәбе дә замандыр. Дөрес, әлеге эштә адәм балалары катышып йөриләр, күпме-азмы хезмәтләр итәләр, инкыйлаб тарихларында исемнәр күреләләр, ләкин бу эш адәм балаларының мөстәкыйль эш эшләүләреннән түгел, бәлки заманның коралларыннан бер корал булып вә аның иҗбар кыйлуыннан гына [мәҗбүри эшләтүеннән] буладыр.

Милләтләрдә булган инкыйлаблар: сәяси, иҗтимагый, икътисади, гомрани [мәдәни], гыйльми кыйсемнәргә аерылалар. Без исә бу җирдә максуд итеп иң соң кыйсемне генә язачакбыз. Ул да хәтер дәфтәрләре кабиленнән кыска булачак вә иң олуг дип зан ителгән нәрсәләргә генә ишарәт кылынып үтеләчәктер. Хәзерендә шуннан артык язарга икътидарыбыз [куәтебез] юк. Бу тугрыда җыйган мәгълүматыбыз, язганнарыбыз вә һәртөрле хаҗәт кәгазьләре вә документларыбыз казага очрап тәлиф булдылар [юкка чыктылар]. Бу кадәресен инде язмасак та, безне гаеп итүче булмас.

II

Русиядә Волга вә Урал буендагы мөселманнарның соңгы тарихлары тәхминә [якынча] 1880 елларны (ундүртенче гасыр һиҗри башы буладыр) бер фасыйлә ясап икегә аерырга буладыр. Аннан югарысы гыйлем җәһәтеннән «схоластика дәвере» булса, аннан соңгысы исә «интибаһ (уйгану вә яңару) дәвере» дер. Һәрхәлдә, Русия мөселманнарының (шимал төрекләрнең) уйгану дәверләре утыз вә утыз биш еллык бер вакыттан артык түгелдер.

Схоластика дәверендә ошбу мөселманнарда хәлфә илә мөдәррис сүзләре бер-береннән аерым мәгънәләрдә йөрсәләр дә, мәктәп илә мәдрәсә арасында күп аермалык юк иде. Мелла яки мөәзин булыр өчен дип имтихан кылынган шәкертләргә, Оренбург Духовный собраниесе тарафыннан бирелә торган мөгаллимлек ганвәне [дәрәҗәсе] игътибарга алынмаса, мөгаллим сүзе дә надир [сирәк] истигъмаль кылыныр иде.

Телләре ачылыр-ачылмас вакытларыннан игътибарга балаларның аналары яки йорт эчендәге карчыклар вә хатыннар үзләренең эш араларында сөйләшеп утырган вакытларында балаларга «әлип, пи, ти, си...», дип ялгыш буларак әлифба ятлатулары, балаларның күбесе ошбу вакытларында ятладыклары сәбәбеннән (ирләр вә хатыннар) ялгыш рәвештә булса да әлифба вә әбҗәдне күңелләреннән белерләр вә мәртәб укырлар иде. Фәкать балаларның ошбу әлифба бикләү вакытлары тәсыйл [уку] елларыннан хисаб ителмәскә тиешле. Моннан башка балаларның әлифба ятлаулары хәлфәләргә йөреп укырга башладыкларында язу таный алмаска көчле бер сәбәп булыр иде. Кәгазьләргә яки агач такталарга бер-береннән аерым ителеп язылган әлифбадан хәлфә: «Әлиф, би, ти.... укы!» — дип сабак биреп җибәрер, бала да һәрбер шәкелне бармагы илә төртеп укыр, танып укыймы, яки анасы бикләткән нәрсәләрне генә тезәме? — шул вакытта ачык аңлашылмас

иде. Мәктәпләр (бу көндәге ибтидаи мәктәпләр җирендә булган уку урыннары) бик аз карьяләрдә генә булып, алар да берәр указлы мелла химаятендә вә күбесенчә күзсез вә чулаклар, аксактуксак хәлфәләр нәзарәтендә торырлар иде. Мондый мәктәпләрдә хәлфәлек (мөгаллимлек) итүчеләр, гомумән диярлек имамлык вә мөәзинлек һәм дә башка хезмәтләрне кылырга икътидарсыз [сәләтсез] мәгъзүрләр [эшне эшли алмаучылар] булыр иде.

Хәлфәләрнең вазифалары исә һәр пәнҗешәмбе көн, балалар тарафыннан бирелә торган сәдакалардан (бер тиеннән башлап биш вә бәгъзе бер урында ун тиенгә кадәр), ашка вә мунчага йөрүдән, сирәк кенә булса да фитыр сәдакалары, корбан тиреләре, гошерләрдән гыйбарәт булыр иде.

Хакыйкать хәлдә бу мәдрәсәләрдә дәрес аз укылыр, гыйлем исә укуга нисбәт илә дә аз алыныр, авыл егетләренең җыелышып сафсата сөйләп утырачак, әкият илә гомер үткәрәчәк урыннары булыр иде. Гөнаһлы яки гафиф [саф] вә гөнаһсыз адәмнәр хакында такмаклар шушы мәктәпләрдә тәэллиф ителер [барлыкка килер], кызларга хатлар вә җырлар ошбу җирләрдә язылыр вә һәртөрле бозыклык планнар шунда төзелер иде.

Мин үзем бу мәктәпләрдә тормадым вә яшь вакытымда эчләрен күрмәдем, ләкин безнең бик күп сабакташларыбыз шушы мәктәпләрдә торган булдыкларыннан, аннардан күп сүзләр ишетер идем. Ишеткән нәрсәләрне, хәтеремдә калган кадәр бу җирдә тәлхыйс кылып [сүзне кыскартып] яздым. Мондый хөкемнәр күбрәк урынга карап булдыгыннан, бәгъзе бер урында яхшы мәктәпләр булган булса, моның зарары юк.

Һәр авылда түгел, бәлки дүрт-биш авыл өчен дә бер мәктәп булмас, әмма кызлар өчен мәктәп һич булмас, бәлки һәр мәхәллә имамы вә яки имамнарның ашханәләре «мәктәплек» вазифасын башкарып торыр, мәхәлләнең ир вә кыз балалары, гомумән шушы ашханәләргә җыелып, имамның хатыныннан вә җиткән кызларыннан сабак укырлар иде. Бәгъзе имамнар, үзләре дә вә бәгъзе бер сабакка йөрүче буйга җиткән кызлар да, мелла хатыннарына булышлык кылырлар иде. Укучылар таң беленгәннән соң җыела башлап, кояш чыккач таралырлар вә өйләдән соң тәкрар җыелып, икенде вакытлырында китәрләр иде. Моның әүвәлгесе «иртәнге сабак» вә соңгысы да «кичке сабак» исемендә булыр иде.

Дәресләрнең тәртибе, гомумән, бу рәвештә булыр иде: сабак башлаучы балалар өйләреннән бер такта ясатып алып килерләр, мелла исә шуңа бөтен әлифбаны язып, хатыны да шунда язылган әлифбаны һәрбер баланың үзенә аерым-аерым укытыр иде. Әлифба укытылып тәмам булдыгыннан соң, тактада булган әлифбаның бөтенесенә фәтхә (өс галәмәте) куелып, балага иҗек дәресе башланыр. Фәтхә галәмәте үгрәтелеп беттегеннән соң, кәсрә (ас галәмәте) вә аннан соң заммә (өтер галәмәте) үгрәтелер, соңрак, бере артыннан икенчесе буларак, өч төрле тәнвин галәмәтләре куелып укытылыр иде. Бу галәмәтләрнең һәрберен үз урыннарына сыйдырырга мөмкин булмадыгыннан, тактада булган әлифба, берничә мәртәбә пыяла белән ышкып алынып, тәкрар язылыр иде.

Әлифба хезмәте тәмам булдыгыннан соң, такта янәдән пыяла илә шомартылып, әлифба карасының әсәре бетерелер. Аның урынына «Әбҗәд» китабы язылыр, балалар да «Әбҗәд»не моның бәгъдендә «Шәригател иман» исеме илә басылган бер нөсхәдән «Кәлимәтел тыйбәт»не иҗекләп укырлар иде.

Ошбу дәресләрне бәгъзе балалар ике-өч кыш укыр булсалар да, ата хисапка күрә болар бер кыш укыла торган дәресләр булыр вә күп балалар ошбу дәресләр берлә тукталып калырлар. Өмми [уку-язу белми торган] булып калырлар вә өмми хәлдә картаеп вафат итәрләр иде.

Икенче кыш дәресләре: «Һәфтияк иҗеге».

Өченче кыш дәресләре: «Һәфтияк сүрәсе», «Бәдәвам китабы».

Дүртенче кыш дәресләре: «Фәзаил әшшөһүр», «Тәкый гаҗәб», «Йосыф китабы» кебиләрнең бәгъзеләре.

Бишенче кыш дәресләре: «Сөбател-гаҗизин», «Рахәтдел», «Могъҗизатнамә», «Нәссыйхәтәс-салихин», «Һәфтияк тәфсире», «Устуани», «Бакырган», «Сәйфелмөлек» кеби китаплардан бәгъзеләр.

Алтынчы кыш дәресләре: (инде гарәп, фарсы китаплары башлана): «Кырык хәдис», «Шорутес-салават», «Әмали», «Тәгаллимес-салават», «Икхикәят», «Мәниятел-моссали», «Төхфәтелмөлек», «Кафия» (көйле бер гарәпчә китап) вә шулар кеби китаплардан бәгъзеләр.

Җиденче кыш дәресләре: «Мәҗмүгеттаиф», «Китабел-баб», «Дәкаикел-әхбар», «Хәмед би Хәд», «Хәләби», «Морадел-гарифин», «Шәригател-ислам», «Сәваних», «Һәдиятес-сәгълүк», «Нисабел-әхбәр» китапларыннан бәгъзеләр.

Монда зикер ителгән китаплар урынында бәгъзе җирләрдә икенче бер әсәрләрдән укытырлар исә дә, уку тәртибе гомумән бер рәвештә булыр, матбагалар булмадыгы сәбәпле, дәрес өчен китап табу хакында бик зур мөшкеллек күрелер вә һәрбер бала, вә шәкерт аерым-аерым укыдыгыннан, һәрбер бала өчен аерым дәрес бирелер иде. (Бик аз вакытларда гына ике баланың бер дәрестә укулары күрелмештер).

Шәкертләр октябрь башыннан гыйнвар башына кадәр берәр-берәр җыелырлар вә февраль башыннан апрель башына кадәр берәр-берәр тукталып торырлар, аталары кунакка киткән вә үзләренә кунак килгән вакытларда һәфтәләр вә ун көннәр илә сабакка килми йөрүчеләр булыр. Бәгъзеләре бер көн килсә, бер-ике көн килми калыр. Бу эшләр, гадәти нәрсәләр хисап ителеп, дикъкатькә алынмас иде.

Инде ысуле җәдидә илә дәрес укуларны инкарь кылучылар вә: «Искечә, ягъни сәләф [борынгылар] ысулынча укырга тиешле», — диючеләр ошбу хаталыкларны (чөнки бу ысул, нигездә, сәләф ысулы түгел) вә ошбу сәфаһәт [бозык], фәхеш дәверләрен кире кайтармак фикерендәләрме, гаҗәбән?.. Фәкать бу дәвер һичвакытта кире кайтмас. Ул заманнарның кайтуы өчен, әүвәлге заманнардагы иркенчелек вә фәрагатьләрнең [буш вакытның] кайтуы лязим. Инде ул хәлләрне төштә күрмәк ихтималы да бетте. Алар кинематограф киндерендә үтеп киткән рәсемнәр мисалында хыяллардан да үтеп китәләр.

Аз гына җаннардан гыйбарәт мөселманнар тора торган урыннарга хәзерендә бишәр-унар латыш вә хохол авыллары урнашты. Өйләрнең ишекләренә терәлеп тора торган кара урманнарның хәтта тамырлары да калмады. Хохоллар, латышлар төннәрен көннәргә катып кәсеп вә хезмәт итеп йөрдекләрендә, бала-чагалары, хатын-кызлары илә иҗтимагый вә икътисади мөхарәбәләрдә [көрәштә] булдыкларында, мөселман авылларына утыз вә кырык еллар элек булган иске мәктәпләрне кайтарып та, мыеклы вә сакаллы сабыйларның күз йоммыш, тәңкә салмыш уйнап ятуларына, көрәшеп мендәрләшүләренә, тула басучы кызлар янына йөреп, кичләр уздыруларына, такмаклар чыгарып, рекрутлар илә гармун уйнап йөрүләренә инде заманнар мөсагәдә [мөмкинлек] кыйлмас.

(Шура, 1913. — № 14. — Б.436-438)

III

Югарыда мәзкүр рәвеш илә җиде кыш гомерләрен меллаларның өйләренә йөреп укучы ир балаларның дәресләре тәмам булган хисап ителеп, шуннан соң дәрестән тукталырлар иде. Әмма кызлар дәрескә дип йөрсәләр дә, үзләре укудан бигрәк, укучы кызларның дәресләрен үгрәтер һәм дә иптәшләре берлә «Әхмәдия», «Мөхәммәдия»ләр көйләр, әкият вә әфсеннәр сөйләп тыңлар өчен генә йөрерләр иде. (Үз аталарыннан сарыф вә нәхү гарәби, мантыйк вә фикъһе укучы бәгъзе бер мөдәррис кызлары мөстәсни [чыгарма]).

Вак мәктәпләрдәге шәкертләр дә ошбу җиде елны тәмам иткән соңгында, я

тукталырлар, вә яки читләрдәге, ерак җирләрдәге зур мәдрәсәләргә китәрләр иде. Зур мәдрәсәләрдә укучы яшь балалар да шушы дәресләр соңгында, дәрестән тукталып, йорт эшләренә керешерләр, ялгыз мелла вә мөәзин булырга өмид кылучыларга сигезенче кыштан игътибара «Бәдан» китабыннан сарыф гарәби башларлар иде.

Игътикад вә гамәл рәвешләрен, дога вә язу үгрәтүләр бик аз җирләрдә генә булып, шушы җиде ел мөддәдендә [эчендә] күп балалар ни язу белмәделәр, ни аңлап вә дөрес рәвештә гакаидә вә гамәл хакында бер нәрсәгә дә төшенмәдекләре хәлдә дәрестән аерылырлар иде. Бәгъзе бер җирләрдә язу вә гыйбадәт рәвешләре үгрәтүләр булса, бу эш гомуми дөрес программа буенча түгел, бәлки бәгъзе бер хосусый адәмнәрнең игътикадларыннан вә фәүкыльгадә [гадәттән тыш] иҗтиһадларыннан [тырышлыкларыннан] булыр иде. Дөресен сөйләмәк лязим булса, шәкертләр язуны, тәһарәт вә намаз рәвешләрен бер-береннән күреп кенә белер иде.

Мин үзем җиде яшемнән укырга башлап, егерме өч ел микъдар гомеремне мәдрәсәдә үткәрдем исә дә, бер генә мәртәбә булсын каләм юнып бирүче, каләмне ничек тотарга кирәк вә ни рәвештә язарга идеген үгрәтүче, язу вә имля тугрысындагы ялгышларымны карап төзәтүче булмады. Шуның өчен үземнең күчереп язган нөсхәләрем гарәби булдыклары һәм дә күчерелеп язылдыклары хәлдә рәсем хатлары ялгыштыр. Моны бик соң аңладым, инде анларны төзәтеп торырга вакыт та юк, мәгънә дә юк. Моннан соң безнең тарафтан нөсхә кылынган шәрех вә хашияләр музәханәләрдә генә ятсалар, анлардан дәрес укучы вә ничек булса да файдаланучы булмас һәм булмаска тиешле. Безнең гомер заигъ булган. Инде башкаларның гомерләре мондый мәгънәсез вә файдасыз нәрсәләр өчен тәлиф булмасын иде. Хөласә [нәтиҗә]: бу тугрыларда бер хәрефлек остазым юктыр. Имля вә иншаның рәсем хат вә хөсне хат кеби нәрсәләрнең ни идекләрен түгел, хәтта исемнәрен дә ишетмәдем. Тәһарәт вә намаз рәвешләрен дә кешеләрнең гамәлләренә карап торып кына үгрәндем, гарәби (мөселманча) рәкымнәрне [саннарны] үзем укый торган басма «Фәзаил шөһүр» китабының бит саннары өчен куелган гадедләрен тикшереп вә русча рәкемнәрне дә олуг юл читенә утырткан чакрым баганаларыннан карап үгрәндем. Гыйльме хисаптан җәмигъ вә тарых [кушу һәм алу] кагыйдәләрендә «Кыекбаш» исемле уен уйнау сәбәбеннән белдем. Шушы хосусларда минем иптәшләрем бик күп булуында шөбһә юктыр.

Остазбикәләрдә язу үгрәтү мотлакан булмас, әмма аның бәрабәренә болар «Күңел сабак» исеме илә кирәкле догалар ятлатырлар. Шул сәбәптән боларның дәресләре авыл халыклары өчен мәктәпләрдәге хәлфәләр дәресләренә күрә файдалырак булыр иде.

Иске мәдрәсәләребездә тәҗвид илә Коръән укуга, догаларны дөресләүгә әһәмият бирмәдегеннән, бик күп карт меллаларның (ихтимал үзем дә шуларның бере булырмын) догалары ялгыш булыр. Моңга гаҗәп итүчеләр исә боларның яннарына килсеннәр дә укуларына дикъкать илә колак салып торсыннар.

Оренбург Духовный собраниесендә имтихан кылынучы мөәзиннәр арасында мәэсүр догаларны дөрес укучы меңнән бер дә булмас. Иң бозык укыла торган дога азан догасы булып, аннан соң «сөбханәкәллләһем»дер. Бу соңгысында «...» илә «...» һәмзәләрен катгый, «тәгали»не әмер рәвешендә, ләкин фәтхә илә, «җәдек»не «ядек» рәвешендә укуда бу бозык укучылар шактый күрелер иде. Моннан соң «Кунут» догасы вә аннан соң да «Җеназа» догалары ялгыштыр.

Бик күп имтихан кылынучылар азан догасында ... не ... рәвешендә, ... не ... рәвешендә укырлар иде.

Мөхтәлиф [төрле] губерналарда булган бу халыкларның иттифакъ белән ялгыш укулары хакында күп фикер

йөрттем вә моның сәбәбе дә бу догалар хатыннар арасында шулай шаигъ булып та, шулардан укыдыклары сәбәбеннән, бөтен дөньяга хаталык таралуы илә хөкем кылдым. Икенче сәбәп исә бәгъзе бер догаларның Казанда йөз елдан бирле басылып, «Шәригател иман» исемле рисаләдә ялгыш басылып тормакыдыр. Мисла «Җеназа» догасыннан булган … сүзе монда … сурәтендә вә … сүзе … сурәтендә басылмыштыр. Мин моның дөрес басылган нөсхәсен күрмәдем. Шуның өчен «Шәригател-иман»да булган догаларны каләм илә дөресләп вә шул рәвештә бастыруларын үтенеп, шул вакытта Казанда мәшһүр китапханәчеләргә хосусый мәктүпләр язган идем. Ләкин мәктүпләрне игътибарга алынып алынмавын белмәдем.

Мәгълүм хәзрәтләрдән бере «Аллаһы әкбәр» урынына «Аллаһы әкфәр» диюе вә «Әлхәмде» сүрәсен бөтенләй Коръәнлектән чыгарып укуын дөрес сөйләүчеләр тарафыннан риваять кылыныр иде.

Моннан утыз биш сәнәләр мөкаддәм вафат булган мөхтәрәм галимнәребезнең бере булган Габделхәбир Мөслими хәзрәтләре фазыйл Мәрҗани үзенә язган хосусый мәктүпләрендә мәктәп вә мәдрәсәләрдә булган дәресләрнең низамсыз вә тәртипсезлекләреннән һәм дә анларның ни рәвештә ислах итәргә тиешле идекләреннән күп мәртәбәләр бәхәс иткән, бу тугрыда артык янып көйгән. «Асар» да Габделхәбир тәрҗемәсендә күчерелгән ошбу мәктүпләрдән икътибас кылып [алып] түбәндәге җөмләләрне язабыз:

«Әүляд мөслимин [мөселман балалары] җиде яшьләреннән башлап унсигез-унтугыз яшьләренә кадәр укысалар да, әгъзам фәраиз [мөселманнар] исламны белмәктән дә мәхрүм каладыр. Гыйльме хисап, тарих вә җәгърәфия кебиләрне сөйләргә дә урын юк. Хальбуки, ауропалылар ысулынча тәгаллим ителсә [укытылса], бу мөддәттә күп нәрсә тәхсыйл кылырга [укырга] мөмкин. Безнең шәмсия вә гакаиде укыган шәкертләребезнең күбесендә намаз дөрес булыр кадәр кыйраәт тә булмый. Ошбу хастәлектән котылмак өчен, сабыйларны тәгаллим хосусында бер канун төзеп, тиешле мәхкәмәләрдән тасдыйк иттерергә [раслатырга] вә һәрбер мөгаллимне шуңа муафикъ укытмак хакында әхбәр кылырга тиешле иде. Әгәр дә тиешсез вә мәгънәсез нәрсәләрдән сафлап төркичә буларак халис кирәкле нәрсәләр генә укытылса, балалар бик күп нәрсәләрдән хәбәрдар булачаклары мәгълүм. Хәзерендә мөгаллимнәр мосхәф шәрифләрне балаларга белдермиләр генә түгел, хәтта үзләре дә белмиләр. Ифадәсе [аңлатмасы] аз булган гарип төрки китапларыннан атлатып, балаларны диван Мөхәммәдиягә төшерәләр. «Мөхәммәдия»не мөгаллим вә мөтәгаллим түгел, мәдрәсәләрнең дә бик күпләре идарәк кыла белмәсләр. Ул ара да булмый, гарәби бер-ике китап укытып куялар, фарсыча ялгыш-юңлыш язылган китаплардан да бер-икене укыталар. Гүя үз фиһемнәренә күрә сабый, берничә лисаннан хәбәрдар булып, тиз арада мелла буладыр. Хальбуки, бу рәвештә дәрес укытмак балаларның бәһрәсез [аң-белемсез] вә җәһил калмакларына сәбәбтер. Зәйрә сабый бала, әҗенби төрки шивәләре илә язылган әсәрләрдән мәгънә хасыйл кыйла алмый, гарәби вә фарсыча язылган бер-ике китап уку илә ул лисаннарда мөлкә хасыйл кыла алмый. Гарәп китапларында «әлиф» «ләм» илә язылмакта булган кәлимәләр төркидә юк, шуның өчен гарәби укып суад чыгармак мөмкин булмас. Ошбу сәбәптән сабыйларны үзләренең ана лисаннарында укытырга тиешле. Башкалар исә шуннан соң укырлар. Ауропалылар тәгаллим кулай кылмак өчен һәр фәнне үз лисаннарына тәрҗемә кылмышлар вә үз лисаннары илә укытырлар. Хәтта үз лисаннарына махсус сарыф вә нәхү вазыйг итмешләр [төзерләр]. Ошбуның сәбәбеннән аз вакытта күп файда тәхсыйл кылалар. Безләр һәм болардан гыйбрәт алып, гомеребезне мөһмиәл [буш] үткәрми, ибтидаи [башлангыч] сыйныфыбызны тәрбия итмәк хакында сәгый итәргә [тырышырга], һәрбер мәгарифне үз лисаныбызга тәрҗемә

кылырга вә монасыйб [тиешле] рәвештә дәрес китаплары хәзерләргә тиешле. Мелла Хөсәен тәгаллим кануны лаихәсенә [программасына] рус лисанын да кергездеге сәбәбеннән, гавамнең [халыкның] нәфрәт кылуларына бәгыйс [сәбәп] булды. Шуның өчен (хәзерге) рус лисанын тәгаллим кануныңа дәреҗ кылмаска [кертмәскә] кирәк. Сабыйларның вакытлары аңа мөсәгыйд [мөмкинлек бирә]. Әмма һәркем мәгарифнең ләззәтен татыганнан соң, үзе һәртөрле мәгарифкә таләб була барыр. Мәдрәсәләрдә ничә еллар ятып, сәүдәгәр кадәр намаз укый белмәгән вә урыс кадәр җир йөзенең уң вә сулын аермаган талибәләр ислам тәгаллименең абруен сындыралар вә күбесе дөнья вә ахирәтенә файдасы юк нәрсәләр берлән вакыт үткәрәләр. Мәдрәсәдән чыктыкларыннан соң, файдасыз булган шул гыйлемнәреннән дә аерылып, халис [саф] надан булып калалар. Ахирәт өчен намаз мәсьәләсен, фикъһе вә әхлак гыйлемнәрен белергә, кыйраәтне тәҗвид илә тасхих вә иткан кылырга, дөнья өчен лай акыл, үз телен яхшы белеп, инша вә имляга икътидар пәйда кылырга, матур булмаса да, рәсем хатын дөресләргә тиешле. Бездә тәгаллимнән максуд бер җиргә указ алу гына дип беләләр. Шуның өчен бай бәчәләр тәхсыйл гыйлемнән истинкяф кылып [кире кагып] газиз вакытларын биһудә [файдасыз], ләһү [күңел ачу] вә хайванияттә заигъ кылалар [бушка уздыралар]. Рифагә Париж әһалисе хакында: «Бай бәчәләр, 20-25 яшьләргә кадәр тәхсыйл илә шөгыльләнеп, мән бәгыд тәзвиҗ кылалар вә кәсепкә керешәләр», —дияр.

Габделхәбир әл-Мөслими хәзрәтләре мәктүбләреннән икътибас иткән нәрсәләребез шушы кадәрдер. «Асар»ны моталләга кылучылар аның мәктүбләрендә бу кабилдән күп бәхәсләр күрерләр.

Олуг мәдрәсәләргә вә анларның шәкертләренә гаид булган хәлләр киләчәк мәкаләдә язылыр.

(Шура, 1913. — № 16. — Б.494-496)

БӨЕК ШӘХЕСЛӘР МӘХӘББӘТЕ

Азат Ахунов,
филология фәннәре кандидаты

Кешелек тарихында мәхәббәтне зурлап йөз меңләгән романнар һәм поэмалар язылган, миллионлап җырлар туган, картиналар иҗат ителгән. Мәүзугъ бер үк — ир белән хатын арасындагы мәхәббәт. Хәзер инде моның белән беркемне дә гаҗәпләндереп булмый сыман. Әмма, шагыйрь әйтмешли, «мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта». Гаҗәп бит, яңадан яңа буыннар мәхәббәт җырын ишетергә тели. Югыйсә, чынбарлыктагы мәхәббәт «сабын күбегедәй опера»лардагыга һич охшамаган. Чын мәхәббәт — күңел батырлыгы ул. Хикмәтле сүз бар бит: чын гашыйклар бер-берсенә карашып торган кешеләр түгел, ә икесе дә бер

якка карауччылар. Зөһрә Акчурина белән Исмәгыйль Гаспралыны шундый гашыйклар рәтенә кертергә мөмкин.

Зөһрә, аның яшендәге күп кызлар кебек үк, иң әүвәл яшь Исмәгыйльгә карата табигый хисләр белән яна, әмма ул тойгы тора-бара ныгый, ике шәхесне изге максатта берләштереп торучы олы бер мөнәсәбәткә әверелә.

Исмәгыйль Гаспралы — Кырым татарлары арасыннан чыккан бөек төрек мәгърифәтчесе, ислахчы, галим, әдип, журналист. Нәкъ менә ул төрек-татар дөньясының иҗтимагый тормышын яңартыр өчен беренче адымны ясаган шәхес. Ә Зөһрә Акчурина — Сембер фабриканты Әсфәндияр Акчуринның кызы. Аларны нәрсә берләштергән? Алар арасында мәхәббәт очкыны кабынырга нәрсә сәбәп булган? Ул очкыннан тора-бара бөтен төрки дөньяны яктырткан ялкын кабына. Бу ялкыннан соң кисәүләр түгел, ә йөзләгән, меңләгән китаплар, журналлар, мәктәпләр, идеяләр рәвешендә төрек-татар җәмгыятен асылдан үзгәрткән җимешләр калган.

Дөньяда бер генә нәрсә дә очраклы булмый. Һәрнәрсә Аллаһ ихтыярында һәм беркем дә билгеләнгән вакыттан алдарак гомер сәхифәләрен актара алмый. Сембер (хәзерге Ульяновск) кайда да Кырым кайда? Һәм анда туып-үскән кешеләр кайда очраша ала да мәхәббәттә аңлаша ала?

Зөһрә 1862 елда Сембер губернасында туа һәм әтисенең постау мануфактурасы белән бергә сатып алган утарында үсә. Әсфәндияр белән Фатыйма кызларын бик яраталар, аның өчен берни дә кызганмыйлар. Чибәр булуы өстенә, Зөһрә бик акыллы бала була, һәрдаим гыйлемгә омтыла. Затлы әйберләр чолгап алса да, кыз күңел самимилеген, гадилеген югалтмый. Чын мөселман кызы булып үссә дә, ул Европа тәрбиясен дә ала — әти-әнисе аңа марҗа-барышняны гувернантка итеп яллый, ул исә кызга көнбатыш телләрен өйрәтә, төрле фәннәрдән мәгълүмат бирә һәм, әлбәттә, рус мәдәниятенә мәхәббәт уята. Зөһрә дөньяда бернинди дә мохтаҗлык кичерми, көндәлек мәшәкатьләрдән азат була, әмма аның яшәешен алтын читлектәге тормышка охшатып булыр иде. Акчуриннар үз биләмәләрендә кырыс шәригать кануннарына өстенлек бирәләр һәм яшь кызның нindидер хыялый теләк-омтылышлары белән исәпләшеп тормыйлар. Романнар укып, кырыс дөньядан аерылган кыз олы, керсез мәхәббәт турында хыяллана... Хыялланырга гына кала шул, чөнки аның язмышы үз кулында булмый, ул заманнарда кем белән «алдым-бирдем» ясарга икәнен ата-аналар хәл иткән.

Ләкин дөньяда гел бәхет янәшәсендә хәсрәт тә йөри, бервакыт Зөһрәнең әнисе каты авырый башлый. Әсфәндияр агай дәваланыр өчен аны кызы белән Серноводскига хастаханәгә җибәрә. Әмма дәвалауның файдасы тими, бераздан Фатыйма ханым вафат була. Бу олы кайгы Зөһрәне уятып җибәрә. Кыз дөньяга икенче күз белән карый, татар хатын-кызларының яшәеше турында уйлана. Ул ни өчен дөньяга килгән? Ни өчен яши? Яшәүнең мәгънәсе нидә? Ләкин Зөһрә әле алтын читлектән чыгу юлын белми. Шуңа да чарасызлыктан төшенкелеккә бирелә, яшәүнең тәмен тапмый башлый.

Әсфәндияр Акчурин, олы байлыкка ия һәр ир кеше кебек үк, кырыс холыклы, үз сүзен генә сүз итә торган кеше булса да, яраткан кызының рухи газапларын күреп, үзе дә сызлана.

Күңел төшенкелегеннән котылыр өчен, мохитне алмаштырырга кирәклеген аңлап, Зөһрәне ул Ибраһим абзасы белән Ялтага дәваланырга җибәрә. Ял итсен, күңел ачсын! Язмыш шулай кушкандыр инде, нәкъ менә шул сәфәрендә Зөһрә Исмәгыйль Гаспралы белән күрешә. Исмәгыйль бәк инде төрек-татар дөньясында билгеле кеше — аның язганнары белән укымышлы татарлар таныш

була. Зөһрәне аның белән Ибраһим абзасы таныштыра, алар Петербургта бергә хәрби училищеда укыган булалар. Татар халкының киләчәге өчен борчыл да аларны якынайта.

Исмәгыйль бәк Гаспралы бу вакытта Бакчасарай шәһәренең башлыгы — бөтен төрек-татар дөньясы өчен газета чыгару хыялы белән яши. Әлбәттә, алар үзара бу турыда да сөйләшәләр. Үзе чибәр, үзе берничә тел белгән акыллы Зөһрәне Исмәгыйль бәк бик ошата. Зөһрә дә аңа битараф булмый, нәтиҗәдә күңел төшенкелеге дә юып алгандай юкка чыга.

Шунысын да әйтергә кирәк, Исмәгыйль бәк Зөһрә белән танышканда өйләнеп аерылган ир-ат була инде. Шактый гына еллар чит илләрдә яшәгәннән соң, ул туган иленә кайтып мөгаллимлек итә башлый. Шул вакытта яшь мөгаллим Ялтада кунакханә һәм бакча хуҗасы Мулла Әсән белән таныша. Ә Әсәннең чибәрлеге өчен Сәмур (кеш) кушаматы алган ундүрт яшьлек кызы була. Бераздан Исмәгыйль аңа яучы җибәрә. Белемле, затлы нәселдән булган егетнең теләгенә Мулла Әсән каршы килми. Туй итәләр. Яшьләр матур гына яши башлый. Әмма эшлекле, иҗтимагый тормышта үз сүзен әйтергә күнеккән яшь бәкне тыныч гаилә тормышы гына канәгатьләндерә алмый. Ул, әйткәнебезчә, бу вакытта ук төрекләр өчен газета чыгару уе белән янып яши. Уй бер хәл, ә газета чыгарыр өчен күп акча кирәк. Яшь кияү бу эштә бабасы Мулла Әсәнгә өмет итә. Әсән дә башта кияүнең ниятен хуплый. Тик хуплауны бит акча белән сипләргә кирәк, ярлы, әмма хыялга бай бәк шуны өмет итә. Коры хуплау аңа нәрсәгә? Башта Мулла Әсән Гаспралыга ике мең сум бирә, аннары тагын меңне өсти. Ләкин газета чыгара башлау өчен бу акчалар гына җитми, Мулла Әсән инде бакчасын, йортын сата, гаиләсе белән кунакханәсенә күчеп яши башлый. Ә газетаның әле исе дә юк! Акча басмаханә өчен җиһазлар алырга гына җитә. И.Гаспралының «Русское мусульманство» дигән беренче китапчыгын чыгарырга да күпмедер кала. Исмәгыйль бәк, күрәсең, Мулла Әсәнне тиз генә зур керем алачакларына ышандыргандыр. Керем урынына бәк хатынына атасын кунакханәне залогка салырга үгетләргә куша. Мулла Әсәннең түземлеге төкәнә. «Мин аңа бирәсен биреп бетердем! — дип кычкыра ул кызына. — Кунакханә — минем өем. Ирең мине хәерче хәлендә урамга куып чыгарырга тели!» Мондый гаугадан соң Сәмур ире янына кире кайтмый.

1882 елда Исмәгыйль Гаспралы Зөһрәнең әтисе белән күрешер өчен Мәкәрҗә ярминкәсенә килә. Кырым татарының ниятен белеп алгач, атаклы Акчуралар токымы Әсфәндияр бай чыгырыннан чыга. Әлбәттә, Исмәгыйль затлы нәселдән, бәк... тик коры бәклек белән Акчураларны кызыктырып буламы? Кыскасы, Әсфәндияр Акчурин Исмәгыйль бәкне үзләренә тиң күрми. Тик Исмәгыйль бәк тә максатчан, үҗәт кеше була, ул туп-туры Зөһрә яшәгән Коромысловка авылына юнәлә. Кыз инде аны көтеп тора. Һәм алар шаһитләр каршында «алдым-бирдем» (никах килешүе) ясап, мулладан никах та укыталар. Кайсы мулла җөрьәт иткәндер?

Инде Кырым татары, никах кәгазен тотып, яңадан Әсфәндияр бай янына килә. Булачак бабай, ярсып, аны бөтенләй өеннән кудыра. Шул вакытта Зөһрә балконга йөгереп чыгып: «Мин синеке! Мин мәңгегә синеке!» — дип кычкырган, имеш. Мәхәббәт риваятьләре шулай туа.

И.Гаспралы күңелен төшерми, шәһадәтнамә кәгазен тотып, туп-туры Уфага, мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев хозурына китә. Мөфти, шәһадәтнамә белән танышкач, Кырым бәгенең хаклыгын таный, Әсфәндияр байга үзенең хөкемен җиткерә. Акчура булсаң да, мөфтигә каршы барып булмый, Әсфәндияр да язмышына күнәргә мәҗбүр була. Әмма ике мең сум күләмендә зур калым сорый.

Исмәгыйль бу акчаны вексель белән түли. Бәхетнең аръягына чыккан кияү белән кәләш Кырымга китеп бара.

Газета чыгару уен Исмәгыйль бәк хатынына да йоктыра. Зөһрә бөтен кыйммәтле әйберләрен, асылташларын сатып, кергән акчаны газета нәшер итүгә сарыф итә. Ниһаять, алар икәү эшкә тотыналар. Башта бөтенесен үзләренә кулдан эшләргә туры килә: газетаны бастыралар, үзләре үк абунәчеләргә җибәрәләр. Зөһрә, текстларны Идел буе татарларына аңлаешлырак итү өчен, кайчакта мөхәррирлек дилбегәсен дә үз кулына ала. «Тәрҗеман» газетасының тарихы шулай башлана.

Зөһрә Акчуринаның «Тәрҗеман» газетасын чыгарудагы роле бәяләп бетермәслек. Әгәр дә ул бу эштәге бөтен авырлыкны ире белән тигез бүлешмәсә, газета дөньяга чыга алмас иде. Ул үзенең байлыгын да, хезмәтен дә кызганмый. Риза Фәхретдин үзенең «Мәшһүр хатыннар» китабында язганча, Зөһрә Исмәгыйль бәкне беркайчан да ярдәменнән ташламый. Газета чыга башлаганда, аларның ярдәмчеләр ялларга да мөмкинлекләре булмый. Исмәгыйль бәк тәмам төшенкелеккә бирелгәндә дә, Зөһрә ханым аны юата, дәртләндерә, бу игелекле эштә Аллаһның ярдәменә ышандыра. Ул һич тә үз мәнфәгатьләре турында уйламый, үз нәфесе өчен акча сарыф итми, балаларын да шул рухта тәрбияли.

Бу гаиләнең игелеге турында әле дә риваятьләр сөйлиләр. Инде «Тәрҗеман» бөтен төрек-татар дөньясында дан алгач, гаиләнең дә матди хәле яхшыргач, имеш, аларның өендә тәмам ярлыланган Әсфәндияр Акчурин пәйда була. Аны бик сөенеп каршы алалар, ярдәмнән ташламыйлар.

1893 елда Бакчасарайда «Тәрҗеман»ның 10 еллыгын тантаналы рәвештә билгеләп үтәләр. Россиянең төрле төбәкләреннән килгән кунаклар гына түгел, биредә Төркиянең, Иранның рәсми кешеләре катнаша. Иран шаһы һәм Бохара әмире исеменнән Исмәгыйль бәк Гаспралыга орденнар тапшыралар. Зөһрә ханымны да «милләт анасы» дигән рәсми булмаган исеме белән олылыйлар, аңа бүләкләр бирәләр.

Зөһрә ханымга «Тәрҗеман»ның 20 еллык бәйрәмендә катнашырга насыйп булмый. Ул 1903 елның 13 апрелендә тифтан вафат була. Аңа 41 генә яшь була әле. Әлеге кайгылы хәбәр газета аша бөтен төрек-татар дөньясына тарала. Редакциягә кайгылы телеграммалар ява. Зөһрә ханымның милләт өчен башкарган зур хезмәтен бөтен татар укымышлылары таный, аның гомер юлын фидакарьлек дип бәяли. Газетада язганча, соңгы сулышында да Зөһрә ханым үзе турында түгел, төрек кардәшләре турында борчыла. Ул көннәрдә Шемахада җир тетри, шунда мәктәп җимерелгәннән соң, балалар арасында корбаннар булуын ишетеп, ул елап җибәрә һәм иренә мәктәпне яңадан корырга ярдәм күрсәтүен үтенеп васыятен әйтә.

И.Гаспралы хатынынннан соң әле тагын 11 ел яши, төрек-татар дөньясындагы иҗтимагый тормышта кайнап, 1914 елның 11 сентябрендә үпкә чиреннән 63 яшьтә вафат була. Совет хакимияте тарафыннан Кырым татарлары үз илләреннән куылгач, аның кабере дә башкаларныкы кебек үк җир белән тигезләнә. Туксанынчы еллар башында гына Кырым татарлары кабер өстенә янә таш куя алды.



БОРЫНГЫ БОЛГАРДА

Разил Вәлиев

Болгар җире, Бөек Болгар иле…
Тарихка мин саклыйм зур үпкә.
Бабамнарның мәгърур җаны кебек
Күтәрелә тургай биеккә.

Басу буйлап берәү җырлап килә,
Чал тарихтан килә диярсең.
Барысы да мең ел элеккедәй…
Аргамаклар чаба иярсез.

Барысы да мең ел элеккедәй:
Ай-кояшы, зәңгәр күге дә…
Бөек илдән чүлмәк ватыклары
Бүләк булып калган бүгенгә.

Бөтен нәрсә монда якын миңа,
Әйтерсең, мин әнкәм куйнында.
Бөтен нәрсә монда Болгарымның
Оныклары кебек тоела.

Хәрабәләр, ташлар арасында
Башын иеп тора кылганнар…
Бабайларның сүзен сөйләр өчен,
Тик кылганнар гына калганнар.

…Болгар иле – бабамнарның иле,
Тургай моңы – минем моңнарым.
Мин тургайны түгел, бүген гүя
Бабамнарның җырын тыңладым.

ӘХМӘТҖАН БИКМИЕВНЕҢ
ТАТАР АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ӘДӘБИЯТЫ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Ленар Гобәйдуллин,
КФУ ның татар халкы тарихы кафедрасы аспиранты, «Казан арты» тарих-этнография музееның туган якны өйрәнү бүлеге мөдире

Татар басма китабының бай тарихы бар. Танылган китап белгече Ә.Кәримуллин фикерләвенчә, революциягә кадәрге татар китабының исемлеге 15 мең данәгә якынлаша [6]. Басма китап тарихыбыз Ә.Кәримуллиннан кала аның шәкертләре А.Габделхакова [1], Р.Сафиуллина [7], З.Гыйләҗев [3], Р.Вәлиуллин [2] хезмәтләрендә тикшерелсә дә, XX йөз башында басылган фәнни-техник, кооперация, авыл хуҗалыгына багышланган гыйльми әдәбият бик аз өйрәнелгән [4]. XIX гасыр азагы — XX йөз башында К.Насыйри, Ф.Фәхри, Ш.Шиһабзадә, М.Мөхәммәтшин, М.Дибирдиев, И.Тегергулов, З.Шәрифуллин Ә.Бикмиев кебек авыл хуҗалыгы темасына язучы авторлар барлыкка килә. Нигездә алар, үз әсәрләрен рус хезмәтләренә таянып язсалар да, татар җирлегендәге проблемаларны барлаганнар, үзләре тәҗрибә ясап исбатлаганнар һәм шуны укучыларга җиткергәннәр. Без бу мәкаләдә Әхмәтҗан Бикмиев тарафыннан иҗат ителгән китапларга берникадәр күзәтү ясыйбыз.

Әхмәтҗан Бикмиев — прозаик, тәрҗемәче, китап сәүдәгәре, практик агроном [8]. Әлеге шәхеснең тормыш юлы һәм иҗаты бик аз өйрәнелгән. Аның XX йөз башында татар авылы халкы өчен игенчелек, бакчачылык, умартачылык һәм башка социаль-көнкүреш проблемаларга караган мәкаләләре һәм бу темаларга нисбәтле рус теленнән төрле китаплар тәрҗемә итүе тарихи әһәмияткә лаек.

Ә.Бикмиев иҗатында XX йөз башының

күп әдипләренә хас булган алымнар тәнкыйтьләү һәм чагыштыру киң кулланыла. Ә.Бикмиевнең авыл хуҗалыгына багышланган хезмәтләрендә татар игенчеләренең проблемалары барлана һәм аларның бу өлкәдә җитешсезлекләре тәнкыйть ителә. Ә чагыштыруга килгәндә, ул татар игенчеләрен башка милләтләр белән чагыштырып үрнәк яки гыйбрәт алырга өнди, тәрбияви максатны алга куя.

Мәгълүм ки, XX йөз башында Россия аграр ил булып кала бирә һәм аграр сәнәгать традицияләрен дәвам итә. Шул исәптән татарларның да 90% артыгы авылда яшәп, игенчелек, терлекчелек белән көн күргән. Без бу мәкаләдә XX йөз башында татарларда игенчелек, җир эшкәртү ысуллары турында язып тормыйбыз, ә бары тик Ә.Бикмиевнең хезмәтләрен генә игътибарга алабыз. Бу китаплар тәрҗемә хезмәт булсалар да, аларның тәрҗемәче Ә.Бикмиев тарафыннан язылган кереш өлешләрендә һәм аерым мәкаләләрендә шул чорда татарларда игенчелек торышы, аның проблемалары күтәрелә. Татар игенчеләренә мөнәсәбәтле проблемаларның иң зурысы — аларның иген игүдә ата-бабаларыннан калган гадәт-традицияләргә ябышып ятулары. Ә.Бикмиев язуынча, ата-бабаларыбыз моннан бер гасыр элек кырларын, игеннәрен ничек тәрбияләгән булсалар, XX йөз башында да шулай эшлиләр: басуларын, катырып, көтү кыры итеп тоталар, начар орлык чәчәләр һәм сукалыйлар. Ә бу чорда игенчелек проблемасы аеруча калку торган, чөнки җир мәйданы аз булган, җир милке мәсьәләсе кискенләшкәннән-кискенләшә барган. Мәгълүм ки, татар авылларында игенчелекнең техник яктан артта калуында тышкы һәм эчке сәбәпләр булган: 1) земстволарда күпчелекне христиан динле милләт вәкилләре тәшкил итеп, аларның татар авылларына хезмәт күрсәтмәүләре; 2) авыл җирлегендә татар телендә эшли, халыкка аңлата белүче агроном, ветеринария белгечләре аз булу; 3) татар вакытлы матбугатыннан күренгәнчә, кайбер авылларда, аеруча кадими муллалар тарафыннан: «Ни өчен без урыс (земство) биргән акчаны мәктәп-мәдрәсә өчен тотыйк, урыс малы безгә хәләл түгел», — дигән кебек каршылыклы бәхәсләр еш булган; 4) авыл халкының «XX гасырның кояшы кеби ачык нурлы һәдия вә бүләкләреннән файдалана белмәүләре һәм файдаланырга теләмәүләре». Бу аеруча земствоның гомумхалык файдасы өчен нәшер ителгән китаплардан, иген коралларын киләчәктә түләү шарты белән бирү, складлардагы иген һәм үлән орлыкларыннан, нәсел үгезләреннән һ.б. файдалана белмәүләре.

Ә.Бикмиев хезмәтләреннән күренгәнчә, земствоның татар игенчеләре файдасына эшләмәвенә крестьяннар үзләре дә гаепле. Алар: «Айгыр поп, үгез дьякон — боларны приговор белән кабул итү шуларны кабул итү була, имеш. Иген орлыгы өчен яхшы орлыкның файдасы бер дә юк, имеш, бары Ходай бирсә, шул чүпле гадәти орлыклардан да яхшы иген була, имеш, җирне тиресләү бары зарар, имеш, чөнки, тиресләгәндә, иген буш башаклы була һәм ава, имеш, земство складларындагы китаплар машина сатар өчен, фәлән өчен үзләре файдасына гына, имеш», — дигән фикердә торганнар. Моңа каршы Ә.Бикмиев игенчелектә яңа эш кораллары, орлыклар һәм тиешле агротехника кертергә кирәклекне генә аңлатып калмый, ә татар крестьяны психологиясенә хас булган дини-дидактик, татар халкының үзендә һәм ислам динендә булган тәрбияви мотивларны да уңышлы файдаланган. Игенчелекне изге эш буларак тасвирлау: «Бер кеше иген иксә, агач утыртса, хасиленнән кош-кортлар, кешеләр ашатса, шул кешегә бу сәдакадыр», «Алла тырышучыларның хезмәтен буш куймыйдыр», «Аллага тапшыр, үзең гафил булма!» — кебек хәдис шәрифләрне, мәкаль-әйтемнәрне уңышлы куллану — шуның мисалыннан. Әлбәттә, болар гади игенчегә психологик яктан тәэсир итү көченә ия булганнар.

Билгеле булганча, игенчелектә агротехник кимчелекләр уңыш түбәнәюгә китергән. Ә.Бикмиев тарафыннан бу кимчелекләрне бетерүдә берничә сәбәп-юнәлеш күрсәтелә. Алар — җирне тиресләү, сыйфатлы орлык чәчү һәм заманча агротехника. Мөселманнар арасында революциягә кадәр җирне тиресләү бик аз таралган була, кайберәүләр тиресне зарарлы дип тә белгәннәр, аны нәҗес дип, гомумән, инкар иткәннәр. Авыл халкы тиресне ерактагы җирләргә алып барып тормаган, җиргә, аеруча елга буйларына, кибән итеп кенә өеп куйган. Монда классик әдип Галимҗан Ибраһимовның XX йөз башы татар авылы тормышын тасвирлаган «Кызыл чәчәкләр» хикәясенә игътибарны юнәлтү урынлы булыр иде. Бу әсәрдә ав-

тор тирес түгү күренешен вакыйга-метафора буларак тасвирласа да, анда шул чор игенчелек культурасының реаль сюжеты ята. Нәтиҗәдә, яңгырлар булганда, төрле начар исләр чыгарып тирә-юньгә таралу табигый күренеш булган. Халыкның күпчелеге җир бер тиресләнсә, яңгырлы елда иген була, яңгырсыз елда иген егыла, дигән карашта торган. Моңа каршы Ә.Бикмиев, тиешле рәвештә органик ашлама керткәндә, уңышның ике тапкыр күп булачагын исбатлый. Ә мөселман игенчесенең тиреслəгән җирендә игеннең төптән кузгалып егылуын, тиресне черетмичә түгүләре һәм туфрак белән яхшы итеп катыштырмауларына бәйләп аңлата.

Мөселман игенчеләре урып-җыю эшләрендә дә шактый кимчелекләр күрсәткәннәр: алар, кыш саламга мохтаҗ булачакларын уйламыйча, башка милләт халыкларыннан аермалы буларак, камылны озынрак калдырып урганнар. Шулай ук җитлегеп бетмәвенә, яңгырда юешләнгәнлегенә игътибар итмәгәннәр һәм шундый халәттә урылган игеннәрне чәчкәннәр. Игенне ындырга кертеп, кирәк вакытта гына сугып алмыйча, тиз-тиз суккалап эшне бетергәннәр. Ә.Бикмиев язуынча: «Табигый, көлтәсендә тормаган иген икътисадтан хәбәре булмаган мөселманнарның бүлмәсендә тормый, октябрь, ноябрьгә кадәр сатылып беткән булып, үзенә хаҗәткә дә сатып алырга эше терәлгән буладыр», — дип яза. Ә.Бикмиев, бу проблемаларны бетерү максатыннан, җирләрне яхшырак эшкәртергә, яхшы орлык чәчәргә, яңа иген коралларын гамәлгә кертергә, көзен сукалау кебек алымнарның кирәклеген исбатлый.

Ә.Бикмиев фикеренчә, игенче халкы үз эшенең остасы булып, «игенче игенче булып яшәргә», «игенче булып дөньяда тора белергә», «чын мәгънәсе белән игенче булырга» тиеш. Ул читтән продукция кертүне тәнкыйтьли: «...Ауропадагы һәм Идел-Кама буйларындагы игенчеләрне чагыштырып карасак, күрәбез ки, алар бу көндә игенче ата-бабалары юлларыннан аерылганнар, вә шул аерылуны алар иң зарарлы булган ашау-эчү, йорт-җир вә кием-салымнан башлаганнар. Бу үзгәрешләр алар өчен шулчаклы бер зарар биргән ки, безнең игенче сыйныфы — авыл халкын тәмам бөлгенлеккә илтеп терәгән. Хәл шулай булса, бу көндә ата-бабаларыбыз ашаган арзанлы, туклыклы ашлар урынына, кыйммәтле, ләкин күп мосарифле [чыгымлы] ашлар, арзанлы һәм сәламәтлеккә файдалы эчемлекләр урынына, кешенең табигый сәламәтлеген җуя торган шикәрле (кыйммәт бәһагә алып булса да) бөртек вә башка чәйләр, сүс, җитеннән тукылган киндер күлмәк, алача ыштан урынына кыйммәтле ситса вә сатиннар; өйдә эшләнгән тула чикмән, юкәдән тукылган чабата, итек урынына трика, постау, бишмәт туннар, кыйммәтле кәвеш һәм резиналар күрәбез. Бу көндә коточкыч кыйммәтчелек булуына карамыйча, игенчеләрнең тормышлары шул көйләнгән рәвешчә бара. Алар ата-баба юлына кире кайтып төшүне уйламыйлар да һәм уйласалар да, ул инде тиз булмаячак». Автор бу күренешнең нәтиҗәсе тискәре булачагын яза: «Әгәр безнең игенчеләребез зирагать голәмәсенең [агрономнарның] сүзләренә колак салмый, иген игүдә йөз ел элеккеге тәртип белән барып, башкасында Ауропаның, тугрысы шәһәрнең соң модаларына иярсәләр, игенчеләребезнең киләчәге өметсез вә айнымас бөлгенлек булачактыр». Бу юллардан Ә.Бикмиевнең XX йөз башы татар икътисади фикерендә киң таралган, авыл халкының булган матди байлыгын читкә чыгармыйча, халыкның үзендә җитештерү, ә бар акчаларны яңа иген кораллары һәм бу турыдагы китапларны алыр өчен тотарга кирәклеге турындагы фикерне куәтләве ачык чагыла. Шунысы игътибарга лаек: галим XX йөз башында күтәргән проблемалар хәзерге җәмгыять өчен дә актуаль булып кала.

Ә.Бикмиев билгеләвенчә, татар телендә игенчелеккә нисбәтле мәгълүмат базасы булмау игенчелекнең заман таләпләренә җавап бирмәвенә этәргән. Мәгълүм булганча, татар крестьяннары рус телендәге бу темага мөнәсәбәтле әдәбиятны бик аз укыганнар яки бөтенләй белмәгәннәр диярлек. Ә.Бикмиев үзенең гыйльми-фәнни эшчәнлеген менә шушы бушлыкны тутыруга багышлаган. Ул татар игенчеләрендә икътисади аң-фикер кузгатуда, агротехник белем бирүдә, заман яңалыклары белән бергә атларга берникадәр этәргеч биргән.

Ә.Бикмиев 1910-1911 елларда игенчелек, бакчачылык турындагы китапларын Сембер губернасы Буа земствосы белән килешеп нәшер иткән, Казан Император университеты басмаханәсендә бастырган. Шулай ук Буа шәһәрендә «Заман» исемле китапханә

ачкан һәм анда төрле әсәрләр, шул исәптән үзенең тәрҗемә китапларын саткан. Автор-тәрҗемәченең Буа өязе земствосы белән килешүе буенча, бу китаплар шул өязнең мөселманнарына бушлай таратылган, ә башка өязләр халкына арзан хакка сатып бирелгән [5].

Галим мондый китаплар язуның максатларын билгеләп китә: «Безнең максатыбыз мөселман игенечеләренең малын яхшыртудыр. Бу рисалә аларның хәлен яхшыртырга хезмәт итәчәк рисалә булганлыктан, кардәшләребезнең укуларына тапшырдык». Нәтиҗәдә, 1910 елда гына да дистәдән артык шундый тәрҗемә китаплары дөнья күрә һәм татар игенчеләренә таратыла. Ә.Бикмиев үзенең тәрҗемә китапларын халык арасында таратып кына калмый, ә игенчеләрнең гамәли максатларда тәкъдим-тәҗрибәләрне файдаланганлыкларын күзәтә һәм бу турыда яза.

Ә.Бикмиевнең терлекчелек, кошчылык, умартачылык, кооперация, бакчачылык әдәбияты буенча да китаплары бар. Ул 1915 елда умарта кортлары турындагы хезмәтендә: «Бу әсәр авыл көнкүрешенә даир язган әсәр вә тәрҗемәләребездән илле беренчеседер», — дип яза, әмма, кызганыч, безгә әлегә шуларның берничәсе генә мәгълүм.

Шулай итеп, Ә.Бикмиев — татар игенчеләренә аң-гыйлем бирү, игенчелек өлкәсендә заманча казанышлар белән таныштыруда шактый зур өлеш керткән шәхес. Аның эшчәнлеге, китаплары татар тарихында, әдәбиятында агрономия гыйлемендә игътибарга лаек.

Әхмәтҗан Бикмиевнең безгә мәгълүм хезмәтләре библиографиясе

Китаплары:

1. Басулардан ничек яхшы иген алырга? / Тәрҗ. Ә.Бикмиев. — Казан: Буа земствосы, Типо-лит. Импер. ун-та, 1910. — 32 б.
2. Безнең чалуларны ничек яхшыртырга? / Тәрҗ. Ә.Бикмиев. — Казан: Буа земствосы, Типо-лит. Импер. ун-та, 1911. — 15 б.
3. Зубрилин А.А. Игеннәр хәлен ничек яхшыртырга? / Тәрҗ. Әхмәтҗан Бикмиев. — Казан: Буа земсвтосы, Типо-лит. Импер. ун-та, 1911. — 15 б.
4. Зубрилин А.А. Тиресләргә. Тирес җитмәгәндә, ничек яхшы иген алырга? / Тәрҗ. Әхмәтҗан Бикмиев. — Казан: Буа земствосы, Тип-лит. Импер. ун-та, 1911. — 62 б.
5. Иген яхшы булсын өчен нинди орлык чәчәргә кирәк? / Тәрҗ. Әхмәтҗан Бикмиев. — Казан: Буа земствосы, Тип-лит. ун-та, 1910. — 40 б.
6. Кечкенә җимеш бакчасын ничек булдырырга кирәк? / Тәрҗ. Ә.Бикмиев. — Казан, 1912. — 32 б.
7. Люцерна үләннәрен чәчү хакында / Тәрҗ. Ә.Бикмиев. — Казан, 1910. — 14 б.
8. Потехин А.Л. Умарта кортлары һәм аларны тәрбия / Русчадан тәрҗемә Әхмәтҗан Бикмиев. — Казан: Нашире Бр. Кәримовлар, матб. «Кәримия», 1915. — 28 б.

Вакытлы матбугатта дөнья күргән кайбер мәкаләләре:

1. Ат тояклары // Икътисад. — 1911. — №5-6. — Б.181-183; № 7. — Б.218-219.
2. Җыентыклар берлә җир тиресләү // Икътисад. — 1911. — №11-12. — Б.335-337.
3. Зирагать // Икътисад. — 1911. — №8-10. — Б.266-267.
4. Качаклар һәм безнең игенчеләр // Йолдыз. — 1916. — 5 сент.
5. Крестьянка [дигән махсус кул урак машинасы] // Икътисад. — 1909. — №10. — Б.310-311.
6. Кырда орлык участоклары // Икътисад. — 1910. — №8. — Б.243-244.
7. Сачәргә орлык // Икътисад. — 1910. — №5. — Б.149-150.
8. Сугыш һәм потребительное общество // Йолдыз. — 1916. — 13 июль.
9. Тавык тәрбиясе // Икътисад. — 1911. — №8-10. — Б.279-280.
10. Тонытмак // Икътисад. — 1910. — №7. — Б.209-210.
11. Файдалы киңәшләр // Икътисад. — 1911. — №8-10. — Б.278-279.
12. Яхшы сачү орлыгы ничек юнәлтергә? // Икътисад. — 1911. — №5-6. — Б.171-174.

Әдәбият

1. Абдулхакова А.Р. Татарская детская книга начала XX века: 1901-1917 гг. / А.Р.Абдулхакова. Автореф. дис. канд. филолог. наук. — Казань, 1998.
2. Валиуллин Р.Н. Татарские учебники по гуманитарным дисциплинам (конец XIX — начало XX века). / Р.Н.Валиуллин. Автореферат дис. кандидата филологических наук. — Казань, 2001. — 28 с.
3. Гилязев З.З. Татарская книга начала XX века в книжных изданиях / З.З.Гилязов. — Казань, 2005.
4. Гобәйдуллин Л.И. ТР Милли китапханәсе кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондларында XIX йөз азагы — XX йөз башы татар телендәге терлекчелек һәм умартачылык китаплары / Л.И.Гобәйдуллин // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. — 2009. — №2 (28). — Б.27-29.
5. Зирагать рисаләләре // Икътисад. — 1910. — №12. — Б.365-367.
6. Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века / А.Г.Каримуллин. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. — 319 с.; Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги / А.Г.Каримуллин. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. — 224 с.
7. Сафиуллина Р.Р. Арабская книга в духовной культуре татарского народа. — Казань: Издат. «Алма-Лит», 2003. — 214 с.
8. Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. — Казан, 2005. — Б. 243.
9. Халиков Н.А.Хозяйство татар Поволжья и Урала (сер. XIX — нач. XX вв.) / Н.А.Халиков. — Казань: ИЯЛИ, 1995. — 195 с.; Халиков Н.А. Промыслы и ремесла татар Поволжья и Урала / Н.А.Халиков. — Казань: Институт истории АН РТ. — 1998.

ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ПРОТОТИПЛАР ДӨНЬЯСЫ
ЯКИ ЧЫНБАРЛЫКТАГЫЧА ГАДӘТИ КАҺАРМАННАР

Әлфия Мотыйгуллина,
филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты

Әмирхан Еники татар әдәбиятын күп төрле типлар, тормышчан образлар белән баетты. Ул әдәби әсәрләрендә заман героеның катлаулы язмышын, каршылыклы характерларын сурәтли. Әдәби әсәрләренең үзәгенә катлаулы шәхесләрне куя, аларның кабатланмас язмышын чагылдырырга омтыла. Әлеге геройларны әдип үзе яшәгән җирлектән, күргән, ишеткән, белгәннәреннән ала. Шуның нәтиҗәсендә прототипларга нигезләнгән әсәрләр дөнья күрә. Әлеге кыйбласына ул гомере буе тугры булып кала. Үз фикерләрен дәлилләп, вакытлы матбугат битләрендә даими басылып торган мәкаләләрен, «Хәтердәге төеннәр» истәлек-хатирәләр җыентыгын, «Соңгы китап» автобиографик повестен, иҗтимагый-сәяси карашларын чагылдырган «Кояш баер алдыннан» дип исемләнгән китабын атарга мөмкин.

Ә.Еникинең беренче хикәяләреннән башлап, иҗатының иң биек ноктасы булган «Гөләндәм туташ хатирәсе»нә кадәр нинди дә булса истәлеккә, документка, хатка, көндәлеккә нигезләнә. Әдип иҗатындагы барлык ачышларны бер генә сүз белән билгеләп, «затлылык» дип атаган Ф.Миңнуллинның хаклылыгын әдәби тәнкыйть даими рәвештә дәлилләп тора.

Чынбарлыктан алынган геройларны башлангыч чор иҗатында язылган хикәяләрендә үк очратабыз. «Ана һәм кыз» хикәясенең геройлары Ә.Еникиләр нәселеннән. Дүрт кыз һәм бер малай тәрбияләп үстергән Кәримә апа чынбарлыктан алынган реаль образ. Нәкъ әсәрдәге кебек ул сугышка алынган бердәнбер улыннан үлеме турында хәбәр

генә ала. Дөрес, Ә.Еники вакыйгаларны типиклаштыра, геройлар арасындагы җылы мөнәсәбәтләрне сәнгатьчә югары дәрәҗәгә күтәрә.

«Вөҗдан» повестенең герое Хәбиб Юлдашев — репрессия шаукымыннан куркып калган, әмма заман белән бергә атларга, белем алырга, үзен төрле яктан үстерергә омтылган шәхес. Бу образга хас сыйфатларны Ә.Еникинең үзендә очратабыз. Шуны дәлилләп, әдип бу мәсьәләгә «Соңгы китап» битләрендә дә ачыклык кертә. Аның үзен «Йөрәк сере» повестенда да күрәбез. Биредә ул яшь кызның эчке серләрен ачарга булышкан Идрис буларак гәүдәләндерелә.

Әдип һәрдаим үзе узган юлга әйләнеп карый, үткән көннәрдә булган вакыйгаларны күңеле аша үткәреп, әдәби иҗатының нигезенә салып бара. Ә.Еникинең Бөек Ватан сугышы белән бәйле хатирәләре «Без дә солдатлар идек» әсәрендә торгызыла. Әдипнең сугыш вакыйгаларына әйләнеп кайтуы да башка әдипләрдән аерылып торды. Аның геройлары — сугыш кырында дошман белән даими очрашып, көрәш кырында батырлыклары белән аерылып торган геройлар булудан бигрәк, бераз тынычрак шартларда (штраф ротасы язмышы сурәтләнә) вәкарь белән сайланып, милли йөзне саклап калырга омтылган, халыктан килгән йолаларга нигезләнеп яшәүче персонажлар. Алар заман кушкан кырыс таләпләрне милли йолаларга буйсындыруга ирешкәннәр.

Шундый ук милли характерларны Ә.Еники «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестенда да тасвирлый. Аның үзәгендә — татар халкының күренекле композиторы Салих Сәйдәшев. Әлеге образ очраклы рәвештә генә тумаган. Ә.Еники повестенда Сәйдәшнең танылган композитор вакытын түгел, ә бу өлкәдә ясаган беренче адымнарын күз алдына бастыру бурычы куя.

Ә.Еники Салих Сәйдәшев образын гәүдәләндерүнең бик уңышлы бер юлын тапкан. Әсәр «Гөләндәм туташ хатирәсе»


Хөрмәтле Зайнәп ханым!
Сәләм. Хатегезне алдым [illegible] рәхмәт.
Сез язгансез минем үз турымда язарга нәрсә язым:
Мин шул гасырдагы татар кызларының берсе.
1905 нче ел Казан шәһәрендә тугганмын.
[illegible] Атам сәүдәгәр Ахмәд-
җан Салтанов дигән кеше. Ул бик иске фикерле
булган ләкин музыка [illegible]
Музыка [illegible] иске көенд[illegible] базарга разы
булган.
Анам идел буе шәһәрләренең берсендән мишәр кызы.
Ул [illegible] гаиләләренә катнашып үскән.
[illegible]
[illegible] русча укырга бирә.
Шунда әсүле җәдид мәктәбе Ләбибә ханым Хөсәения
бере мин шул мәктәпне [illegible]. Атам [illegible]
[illegible] каршы торган, анам белә атам уртасында
минем турымда күп урышканнар.
Атам музыки ярату сәбәбле, бүтен искелекләргә
бу эш ярамасада мине Сәйдашевлардан музыка
үйрәтергә разы булга.
[illegible]
[illegible]
[illegible]
[illegible] уйныйбез көләбез. Иделдә көймәдә йөремез
китаплар укыймез

повесте героеның прототибы Фатимаи-Зөһрә истәлекләренә нигезләнеп язылган. Бу турыда Ә.Еники белән булган бер сөйләшү вакытында ачыкланды.

Әдипнең кулына 16 биттән торган көндәлек дәфтәре килеп керә. Аны кайчандыр Казанда яшәгән, соңыннан Ташкент шәһәрендә гомер кичергән бер яшь кыз яза. Башта кулына төшкән истәлек дәфтәрен кире кайтарып биргән булса да, Ә.Еники, еллар узганнан соң, Ташкентка барып, адресы буенча дәфтәрне эзләп таба. Бу вакытта аның авторы Фатимаи-Зөһрә инде вафат булган була. Бары тик аның кызы гына әнисенең интим тормышы белән бәйле хатирәләрне туплаган көндәлекне саклап кала. Әлеге истәлек дәфтәре Салих Сәйдәшев музеена тапшырыла.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Ә.Еники истәлек мәгълүматларына таянып, Салих Сәйдәшевнең музыкага булган мәхәббәтенең нигезләрен татар халкының буыннан-буынга күчеп килгән җырларын белүе, аның нечкәлекләрен

өйрәнеп, алдагы буыннарга тапшыруга омтылышын сурәтләү аша ачып салган. Икенче төрле әйткәндә, мәшһүр композитор булып танылган Сәйдәшнең башлангыч чор иҗат эшчәнлеге үк халык җырларына барып тоташа. Шуңа күрә аның ягымлы, моңлы көйләренең нигезен халык җәүһәрләреннән эзләү максатка ярашлы. Сәйдәшев шәкерте Гөләндәмгә «Агыйдел»не нота буенча уйнарга өйрәтеп кенә калмый, барыннан да бигрәк аның гүзәллеген тоярга, көйгә салынган табигый бизәкләрне күзалларга өнди: *«Мәсәлән, ярларына сыя алмагандай бөтерелеп, кызу гына аккан Идел үзе… Аргы якта, киң тугайда киез эшләпә кигән агайлар тезелешеп печән чабалар… Ә бирге якта, су читендә ап-ак казлар кагына» [1, 272].*

Повесть битләреннән күренгәнчә, Сәйдәшев шәкертен музыка серләренә өйрәткәндә, җырны, көйне төшендереп кенә калмый, татар музыкасының барлык нечкәлекләрен белеп, аны тоеп уйнау, җырлау өчен бар мөмкинлекләрне ачып бирә. Әйтик, (Сәйдәшев) авыл көе «Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем»не шәкертенә төшендергән вакытта, үз халәтен болай аңлата: *«…минем күз алдына гел генә гаҗәп бер күренеш килә: авыл, кояш баеп бара торган вакыт, көтү кайткан, сөт исе аңкый, кызлар, яшь киленнәр ак чиләкләренә тыныч кына күшәп торган сыерларны савалар» [1, 272].*

Әдипнең «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестеның лейтмотивы булып татар халкының музыка сәнгатенә карата кызыксынуы үсә бару тора. Шушы үзенчәлек гади, тәрбияле гаиләдә татар кызының музыкага тартылуы мисалында тасвирлана. Музыка, татар көе, җыры үзе дә образ дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнә.

Салих Сәйдәшев шәкертенә биргән белемнәрне киң катлау укучылары да ишетә. Композитор иҗат иткән көйләрнең тарихы, музыка сәнгатен үстерүгә керткән өлеше бәяләнә. Гомумән, повесть аның музыка сәнгатендә ясаган адымнарын, беренче уңышларын ачып бирә. Ә.Еники Салих Сәйдәшевнең югары уңышка ирешүенең нигезендә халык көйләренә таянуы, аны өйрәнүе, иҗади эшкәртүе ятуына басым ясый. Сәйдәш һәм халык арасындагы якынлык аның даһи композитор булып җитешүендә әһәмиятле роль уйнаган. Гөләндәмгә биргән дәресләрендә аларны тыңлап утырган Әхмәтҗан абзыйны: «Яхшымы-начармы, үзебезнеке безгә ана сөте белән кергән, Әхмәтҗан абзый! Безнең бөтен моңыбыз, дәртебез, юанычыбыз халык көйләрендә», — дип ышандыра Сәйдәшев.

«Гөләндәм туташ хатирәсе» повестенда әдип музыканың кеше күңеленә ясаган тәэсир көчен ачып бирә. *«Ишетәсезме, бәгырь? — диде Салих, дәртләнеп уйный-уйный. — Күпме уй-хис музыкада! Олы хәсрәттән әрнү бар, хәтта тәкатьсез үксү дә ишетелеп кала, әмма шул ук вакытта ул кешенең рухын төшерми, өметсезләндерми, киресенчә, ул аны үстерә, дәртләндерә, гүя зур-зур эшләргә канатландыра!.. Ихлас! Ә менә бу җирендә тыңлагыз әле, тыңлагыз — ниндидер бер тантаналы горурлык яңгырый түгелме соң?! Тукай өчен, Тукайны тудырган халык өчен горурлык — ишетәсезме сез шунда?!» [1, 314].* Әйе, ишетә аны шәкерте. Алай гына да түгел, татар халкы ишетә һәм Гөләндәмнең: *«Әйе, ишетәм мин, ишетәм! Ишетү генә түгел, әллә нинди бер сызланулы ләззәттән, билгесез бер сөенечтән хәтта елыйсым да килеп китте», [1, 314]* — дигән сүзләрендә героиняның халык белән теләктәшлеге ишетелә. Музыканың сихри көчен Гөләндәм болай дип тә аңлата: *«Музыка һәм халык икесе бергә кушылса, бик тирән яткан тойгыларны да кузгата икән ул» [1, 314].*

Ә.Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» повесте белән бәйле көндәлек дәфтәре генә түгел, ә әсәрнең прототибы

Фатимаи-Зөһрә язган һәм Казанда радиокомитетта эшли торган Зәйнәп ханымга җибәрелгән тагын бер хат әдипнең архивында сакланып калган була. Шул хат Салих Сәйдәшевнең җанлы образын тудыруда ярдәм итә. Шуңа күрә ул хатның авторы аерым кызыксыну уята. Әйтик, әлеге хатта Фатимаи-Зөһрә үзенең кем булуы белән таныштырып та куя: *«Мин — шул гасырдагы татар кызларыннан берсе. 1905 елда Казан шәһәрендә туганмын. Йортыбыз Захарский урамында урнашкан. Атам сәүдәгәр Әхмәтҗан Солтанов дигән кеше. Ул, бик иске фикерле булса да, музыка яраткан. Музыка өчен иске кагыйдәләрне бозарга риза булган» [3].* Шул ук хатта кызның әнисе турында мәгълүмат бирелә: *«... әнием минем заманына күрә алдынгы карашлы, мәдәниятә омтылучан хатын иде. Ул бит Сембердә туып-үскән, ә Сембер Казан түгел инде — саф рус шәһәре. Ахун хәзрәт кызы булуына һәм асылда мөселманча тәрбияләнеп үсүенә карамастан, әниемә барыбер рус кызлары белән аралашырга, телләрен, гадәтләрен өйрәнергә, өй-гаилә тормышын якыннан күрергә туры килгән... Бервакытта да йөзен ирләрдән яшерми, шулай ук абыстайлар шикелле укалы камзул, үкчәсез читекләр дә киеп йөрми.Ул европачарак киенергә ярата һәм күлмәкләрен дә рус хатыннарыннан тектерә» [3].* Повестьның герое Гөләндәм дә әнисе йогынтысында башкачарак тәрбия ала. *«Казанда иң яхшы саналган Ләбибә ханым мәктәбенә укырга бирде. Бу кызлар мәктәбендә безгә төрле фәннәр укыту белән бергә, рус телен дә укыттылар, шулай ук төрле кул эшенә дә өйрәттеләр» [3],* — дип язылa хатта.

Күреп үткәнебезчә, повестьның төп герое Гөләндәм образының реаль шәхес икәнлеге шик тудырмый. Шуңа күрә Салих Сәйдәшевнең аралашу даирәсендә булган яшь кыз истәлекләре һәм хаты әсәрдәге вакыйгаларның чынбарлыктан алынуын кат-кат дәлилли.

Мәгълүматлардан күренгәнчә, әдәби әсәрдә Сәйдәш образын тудырганчы, Ә.Еники аның шәхесен өйрәнә. Автор белән әңгәмә корган вакытта, Салих Сәйдәшевкә багышланган әсәре турында сүзен дәвам итеп, ул болай диде: «Соңыннан мине Сәйдәшнең танылган еллары турында язарга кыстый башладылар. Күпме уйласам да, хыяллансам да, ул эшкә керешә алмадым... Үземчә болай аңлата алам: иң беренче чиратта, композиторлык иҗаты миңа таныш нәрсә түгел. Музыка ничек туа? Ул бик нечкә нәрсә булса кирәк, шуңа күрә профан, дилетант булып язарга ярамый. Салих мәрхүм әйтә торган булган: «Минем колагымда һәрвакыт музыка яңгырап тора», — дип. Ничек яңгырый? Илһам аңа ничек килә? Аларны ничек белергә?»

Татар халкының бөек композиторы Салих Сәйдәшев — Ә.Еникинең күңелендә тирән эз калдырган шәхес. Ул аны «фаҗигале шәхес» дип атый. Әдип Сәйдәшнең, беренче чиратта, халык композиторы булуына игътибар юнәлтә: «Сәйдәшне исә халык таныды, халык күтәрде...» — дип күрсәтә ул.

Гомумән, Ә.Еники, 1970 елларда әлеге повестен иҗат итеп, халыкта югалып бара торган гореф-гадәтләрне, традицияләрне кайтаруның бер чарасы итеп музыка булуны күрсәтә. Милли музыка, аның танылган вәкилләре, татар профессиональ музыкасы турында шул чор белән бәйле әдәби әсәр язып, татар көе-моңының матурлыгын күрсәтүгә ирешә, музыканы иң тәэсирле сәнгать, иң бөек көч итеп сурәтли. Шуның белән бәйләп, чорның төрле дәрәҗәдәге шәхесләрен үлмәс образлар буларак калкыта.

Чыганаклар

1. Еники Ә. Гөләндәм туташ хатирәсе / Әмирхан Еники // Әсәрләр: өч томда: II том: Повестьлар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — Б.247-414.
2. Мотыйгуллина Ә. «Хатирәләр» яңарганда... (Әмирхан Еникигә 85 яшь) / Әлфия Мотыйгуллина. // Татарстан, 1994. — №3-4. — Б.94.
3. Шәхси хат.

БОЛГАРДА

Газинур Морат

Эргәсендә чиркәү тора,
Ирегемне чикләп тора.
Галиләре кол ителгән
Хан төрбәсе биктә тора.

ШӘҺРЕ БОЛГАР

Ркаил Зәйдулла

Салкын ташка учны тидердем дә
Зыңлап куйды кара манара...
Күзен кысып җиргә төбәлгән ул,
Урын эзли гүя аварга.
Шәһри Болгар — татар милләтенең
Җан җиредер...
Шул хис бу якта.
Үрчем орлыкларын чәчеп илгә,
Манарасы торган һәрчакта.
Бер кыз белән үрмәләдем өскә,
Астыртын хис миңа күчмәсме?
Тик диварлар шома, баскыч текә —
Сынды кызның туфли үкчәсе.
Кулын сузып, миңа авышты ул,
Бер мизгелгә бары... Берара...
Күк гөмбәзе баш түбәмә тамды,
Йолдызларга очты манара.
И табындык зирәк бабайларга, —
Без тезләнгән ташлар кап-кайнар!
Безнең дәртле сөю сүрәләрен
Тәңре тыңлар, Тәңре абайлар.
Диварлары шома, баскыч текә, —
Җитәкләшеп төштек.
Чорларны
Иярттек без... Алар, кайнарланып,
Муеннарга килеп чорналды.
Без китәбез акрын гына моннан,
Кан уйнатып килер тагын яз...
Күмелер дә киткән сукмагыбыз,
Беркем, беркем безне сагынмас.

«…Бабайлардан калган изге йола
Юлда юлдаш була».
Гамил Афзал

Халык авыз иҗаты

Мәдәнияте, икъдисади хәле, милләтләр хокукларын яклау мәсьәләләре җитди куелган, гомумән, алга киткән илләрдә халыкларның рухи, икенче төрле әйткәндә, материаль булмаган мирасын мирас буларак саклауны күз уңаена куйган халыкара программа булдырылганга быел 40 ел тула. 1972 елда ЮНЕСКО тарафыннан «Дөньяның мәдәни һәм табигый мирасын саклау Конвенциясе» бу юнәлештә, беркадәр юридик хокукы булган беренче документ буларак бәяләнә. Ул гына да түгел, халыкларның традицион мәдәниятен, фольклорын саклау мәсьәләсе дөньякүләм киң җәмәгатьчелекнең көн кадагына сугылган сораулары буларак бик еш кузгатыла. Халыкларның рухи мирасы күренешләре: культурология, антропология, этнография, этнология, фольклористика кебек шактый күп гуманитар фәннәрнең өйрәнү предметлары буларак та гамәлгә керде. Моның шулай күтәрелүенең объектив сәбәпләре дә бар. Беренче сәбәп буларак кешелекнең глобаль кулланучылар җәмгыятенә әверелеп баруы һәм аңа каршы торырлык кешелекне саклап калу механизмнарын эзләү куела. Ни өчен дигәндә, адәм баласын кеше буларак тәрбияләп, кешеләр арасында яшәү системасында тотрыклы калдыру нигезләре һәр халыкның мәдәни мирасында әллә кайчан барлыкка китерелгән. Алай гына да түгел, системаның үз регуляциясен тәэмин итү дә теләсә кайсы халыкның ата-бабадан калган гореф-гадәт системасына утыртылган. Моны аңлаган галимнәр, сәнгать һәм җәмәгать эшлеклеләре кешелек алдына үзеннән үзе килеп баскан афәттән чыгу юлын рухи мирас буларак бәяләнә ала торган халык мәдәниятендә күрделәр һәм дөньяга

РУХИ МИРАСЫБЫЗНЫ САКЛАУГА КАГЫЛГАН КАЙБЕР ФИКЕРЛӘР

Фәнзилә Җәүһәрова,
филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты

чаң кага башладылар. Бу югарылыктан торып сүз алганда, «татар халкы мәдәни мирасына караш ничек соң? Без татарлар боларны аңлап, нәрсә дә булса эшлибезме?» кебек сорауларның тууы табигый. Шушы сорауларга җавап биреп карыйк.

Татар халкының рухи мирасы дигәндә, без башлап, мирас исемлегенә халкыбызның кайсы мәдәни күренешләрен кертеп карый алабыз — шуны барлап алыйк. 2003 елгы Париж Конвенциясе нигезендә «материаль булмаган дөнья шедеврлары» исемлегенә теге яисә бу халыкның табигый яшәешендә хәзер дә сакланучы күренеш кенә кертелә ала. Алар арасында йола гадәтләре, бәйрәмнәр системасы; аларны башкару өчен кулланыла торган мәдәни пространстволар, предметлар; башкару традицияләре (вокаль, хореографик, музыка уен коралларында уйнау); теге яисә бу мәдәни күренешне тудыру технологияләре; халык авыз иҗаты әсәрләре, аларны башкару үзенчәлеге, сөйләү теле; табигать, галәм корылышына бәйле ышанулар системасы; мәдәни традицияләрне саклаучы, алар

белән эш итүче кешеләр, икенче төрле әйтсәк, традицияне йөртүчеләр карала. Шушылардан кайсы бүген «татар халкыны рухи мәдәни шедеврлары (гамәлдә булмаса да) исемлегенә» кертелә ала соң? Әлбәттә, барыбыз да бертавыштан Сабантуй, дияр. Кайсы Сабантуйны, дип сорасак та, урынлы булыр. Чөнки бүген халкыбызның бу матур бәйрәме бик тупас рәвештә калыплашып, рухи кыйммәтен, асылын югалтып бара торган, берничә мең кешенең игътибарын җәлеп итүне максат итеп куюга юнәлтелгән тамашага әйләнеп бара. Тыйнак кына үз авылы халкы өчен үткәрелә торган Сабантуй бәйрәмнәре, башлыча, хатирәләрдә генә сакланып калып бара. Сабантуй — тамашаны кертеп булмый бит инде. Шулай да кайбер районнарыбызда, татарлар яшәгән төбәкләребездә гүзәл күренешләр юк түгел. Алар арасыннан Свердлау өлкәсенең Түбән Сырга районындагы Үрмәкәй, Шәкүр авылларында яшәүче апалар тарафыннан Урал татарларына хас булган күлмәкләрне каеп эшләү технологиясен, Татарстанның Кукмара муниципаль районы Күкшел авылында үткәрелүче Сөрән йоласын, Себер татарларына хас төйдереп бию үрнәкләрен, аларда сакланучы Астаналарга бәйле ритуаллар системасын, Әстерхан татарларының бик аз сакланып калган булса да, хәзер дә югалып бетмәгән кабалда, сазда уйнау традицияләрен, Самара өлкәсендә сакланып калган Ярмәк, Балыклы вакларын (биюләрен), Балтач районында гына сакланып калган гөсләдә уйнау үзенчәлекләрен, Арча, Дөбъяз якларында хәзер дә эшләнүче чигүле (каюлы) читекләр технологияләрен, Казанда яшәп иҗат итүче берничә останың сәнгать дәрәҗәсендә алтын белән чигү технологияләрен, Урал татарларына хас туй йолалары комплексларын (берничә авылда гына сакланып калган булса да) һәм башка бик күп күренешләрне санап була. Ләкин бу күренешләрне санау мөмкинлеге вакыт ягыннан бик чикле. Ул чикне осталарның берән-сәрән генә калуы, яннарында бер генә өйрәнчекнең дә булмавы билгели. Мисалга бер генә фактны китереп үтик. Моннан өч ел элек Әстерханнан Казанга бу төбәктә яшәүче татарларның туй йоласында уйналган көйләрне яздырырга дип бердәнбер оста-сазчы (гармунчы) Алимуллаев Гарифулла абзыйны чакыртып, шактый күп көйләрне яздырган идек. Кызганыч ки, бер ел да узмады, олы яшьтәге оста каты авырып китеп, урын өстенә ятты. Бүгенге көндә бу традиция Әстерхан татарларында яши, дип һич тә әйтә алмыйбыз. Сакланып калган тардицияләрнең барысы белән дә хәл шулайрак. Ул гына да түгел, бүгенге көндә татар халкының материаль булмаган рухи мирасы күренешләренең сакланышын өйрәнүне күз уңында тоткан фәнни-тикшеренү эше дә алып барылмый. Иң кызганычы: мондый җитди эшләрне, шул исәптән, халык традицияләрен торгызу юнәлешендә хезмәт итәрлек кадрлар әзерләү системасы да бөтенләй юк дип әйтерлек. Шуларның кайберләренә игътибар биреп үтик. Мәсәлән, бүгенге көндә Татарстанның бер генә уку йортында, шул исәптән ВУЗында да, татар этнографиясенә кагылышлы бер сәгать күләмендә булса да лекцияләр укылмый. Татар этнографиясе кафедрасы ачу теләге бу очракта мәгънәсез, тормышка ашмас хыял кебек кенә чамалана башлый. Соңгы елларда Универсиадага бәйле Татарстан Милли музеенда татар этнографиясе чагылдырылган экспозицияләр кору турында күп кенә планнар корыла. Ул экспозицияләрне оештыру эшен җитәкләп, башкарып чыгучы этнографларыбыз бармы соң? Аларны кайда кем әзерли? Кызганычка каршы, «беркайда да беркем дә әзерләми», дип кенә җавап бирә алабыз. Татар халык хореографиясе белән дә ситуация шундыйрак. Дөресрәге, тагын да аянычрак. Ничә еллар дәвамында Татар фольклоры дәүләт үзәге (хәзер Республика традицион мәдәниятне

үстерү үзәге) бу мәсьәләнең ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген ассызыклап, берничә түгәрәк өстәл, конференцияләр үткәрде. Ул конференцияләрдә күтәрелгән мәсьәләләр вакытлы матбугат битләрендә яктыртылды. Бу хәлдән чыгу юлы буларак Казан Дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының хореография факультетында татар халык биюе кафедрасы ачу мәсьәләсе куелган иде. Ләкин бу чара хәзер дә хәл ителми кала бирә. Шуны аңларга кирәк: татар халык биюе кафедрасы булмый торып, студентларны елга бер мәртәбә булса да кыр фольклор практикаларына алып чыгып, халыктан аның төрле этник төркемнәренә хас бию үрнәкләрен җыйдырмый торып, без бию сәнгатебез үзенчәлеге, аның үзенә генә хас бизәкләре турында авыз ачып бер сүз дә әйтә алмаячакбыз. Без үзебезгә хас ничә төрле биюебез барлыгын да белмибез. Иң кызганычы: белергә тиешлегебезне дә аңламыйбыз. Ул гына да түгел, бүген татар кешесенең көндәлек яшәешеннән бию сәнгате тавыш-тынсыз гына китеп бара. Без — бу хәлнең тере шаһитлары. Сабантуйларда халыкның үз күңелен үзе күреп, рәхәтләнеп биюен соңгы вакытларда кайчан, кайда күргәнебез бар? Гаилә бәйрәме, мәҗлесләрендә дә татарча биимибез диярлек. Туйларда да кырыктан өстә булган кунаклар күп булса гына татарча бию оешып ала. Яшь буынның бию теләге юк кына түгел, аның биерлек ситуациясе дә юк, ул халык биюләрен күрми диярлек. 1939 елда Гай Гаджи улы Таһиров чыгарган «100 татар биюе» китабы белән генә канәгатьләнергә тиеш түгелдер бит инде татар. Димәк, бу өлкәдә дә җитди проблемалар бар. Алар да ниндидер гамәлләрнең системалы үтәлүен көтеп торалар. Заманында Советлар Союзының төрле шәһәрләрендәге көчле фәнни мәктәпләре булган вузларына, сәнгатьне өйрәнү институтларына Казаннан максатчан аспирантураларга студентлар җибәрү системасы бар иде. Совет иле бетү белән бу система да эшләми башлады. Нигә бөртекле генә булса да галимнәр әзерләүнең бу төр чарасына кабат кайтмаска?! Татарстан Хөкүмәтенә бер ике көчле студентны максатчан магистратураларга җибәрү

юлларын булдырмаска?! Казахстан бүген үзенең меңәрләгән кызларын, егетләрен үз акчасына дөньяның иң көчле уку йортларында укыта. Без бүген меңнәр димибез, ике-өч турында сүз алып барабыз. Кемдер «алар Мәскәү, Санкт-Петербургка киткәч, кире кайтмаслар», — дияр, безнеңчә моннан да куркырга кирәкми. Әгәр дә ул магистрант яки аспирант тикшерү обьекты буларак татар материалын алып эшли икән, ул барыбер татар файдасына эшли дигән сүз. Аны киләчәктә Казан вузларына лекцияләр укырга чакырып кайтарырга мөмкин була бит. Кайвакыт студентка зур галимне бер-ике тыңлау да көчле этәргеч ясый. Аннан ул галимнең үзенә дә Казаннан киләчәктә аспирантлар, магистрантлар җибәреп булыр иде.

Тукталырга кирәкле тагын бер мәсьәлә — халык уен коралларын популярлаштыру, кайберләрен кабат торгызу. Халыкка кайтару, торгызу дигәндә без еш кына уйланып бетмәгән, анда бер, монда бер үткәрелә торган Республикакүләм фестивальләр турында сүз алып барабыз да үзебезне канәгатьләндерәбез. Ләкин алар теге яисә бу уен коралын халык арасында популярлаштыруның әллә ни үтемле чарасы түгел. Бүгенге көндә уен коралларына кагылышлы үтә торган фестивальләргә, гадәттә, совет чорындагы чиксез смотр-конкурсларда шактый чарланган өлкән яшьтәге агайлар катнаша. Кайвакыт теге яисә бу музыка, сәнгать мәктәбе каршында оешкан ансамбльләр килеп керә. Ләкин алар да системалы рәвештә түгел.

Уен кораллары турында сүз кузгалдымы, тагын бер еш күтәрелә торган сорау куера башлый. Ул — татар халык музыка уен коралларының фабрикасын торгызу. Бу ике мәсьәлә бер-берсенә бик нык бәйләнгән. Ни өчен дигәндә, фабриканың тиешле эшләп җитештергән уен коралларын сату мөмкинлеге булсын өчен ул коралларда уйнаучыларның, уйнарга өйрәнергә теләге булганнарның бик күп булуы кирәк. Ә алар булсын өчен музыка, сәнгать мәктәпләрендә татар халык уен кораллары белән бәйле предметларның төп уку планнарында булуы мәҗбүри. Бүгенге көндә Татарстанның музыка мәктәпләрендә классик европа уен коралларын төп предмет исәпләнә. Халык уен коралларын аларда факультатив буларак куелган. Әлбәттә, бала төп предмет буларак флейта сайлаган икән, аның өстәмә тагын бер предмет белән шөгыльләнеп, вакытын әрәм итәсе килми. Казан музыка училищесында да, Казан дәүләт консерваториясендә дә, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында да хәл шушылайрак. Башкортстанда курайны Республиканың йөзек кашы дәрәҗәсенә күтәрү ихтыяҗы тугач, беренче эшне музыка һәм сәнгать мәктәпләренең укыту планнары, программаларына курайны төп предмет буларак мәҗбүри кертүдән башладылар. Шулай эшләмәгән мәктәпләргә Мортаза Рәхимов үзе үк лицензия бирдертмәгән, дип тә сөйлиләр. Бүген Башкортстаннан килгән, алар өчен урта кул исәпләнгән, курайчылар ансамбльләренә Татарстанда тиңнәр бөтенләй юк. Күргәнегезчә, халык сәнгатен саклау, үстерүгә бәйле кайсы гына тармакны алма, берсендә дә алга китеш түгел, ә бетүгә таба йөз тотуны күрәбез. Бүген бик еш кына Татарстанда «татарлар дөньяга төрле яклап интеграцияләнә, татарны дөнья таный башлады» дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Ләкин шул ук вакытта татар халык сәнгатен, рухи мирасын саклау, шуның нигезендә милли профессиональ сәнгатьне үстерү өлкәсендә берни эшләмибез. Бу эшләрне җайга салу өчен Дәүләтнең махсус карары яисә законы, шуның нигезендә төзелгән программасы булырга тиеш дип исәплибез. Шулай булмаганда безнең татарлыгыбыз бик чамалы калыр. Милләт, Халык буларак кына түгел, Кеше буларак та сакланып калу иммунитетына тиң рухи мирасыбыз үзенә җитди игътибар көтә.

«Ак тастымал булып юлым калды...»

Гамил Афзал

Хушлашу

ТАТАР ХАЛКЫ, РЕСПУБЛИКА ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕГЕ ЧИКСЕЗ ЗУР ЮГАЛТУ КИЧЕРӘ. 2012 ЕЛНЫҢ 2 МАЕНДА 77 НЧЕ ЯШЕНДӘ ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ, МӘШҺҮР ДРАМАТУРГ, ПРОЗАИК, ПУБЛИЦИСТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ ТУФАН ГАБДУЛЛА УЛЫ МИҢНУЛЛИН КИНӘТ ВАФАТ БУЛДЫ.

Туфан Миңнуллин 1935 елның 25 августында Татарстан АССРның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында игенче гаиләсендә туа. 1952 елда, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Олы Кариле һәм Кама Тамагы авылларында хисапчы булып эшли, аннан соң, Казанда бухгалтерлар курсын тәмамлап, комсомол юлламасы белән Казахстанның Кустанай өлкәсенә чирәм җирләрне күтәрергә китә. Анда совхоз кооперативларының берсендә баш бухгалтер вазифаларын башкара. 1956-1961 елларда Мәскәүдә М.С.Щепкин исемендәге театр училищесында укый. Училищены тәмамлаганнан соң беркадәр Минзәлә драма театрында, аннан соң Казанда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер булып эшли. 1964-1967 елларда Казан телевидение студиясендә баш мөхәррир вазифаларын башкара һәм «Чаян» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире була. 1968 елдан башлап әдәби эшчәнлек белән һөнәри төстә шөгыльләнә. 1975-1977 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый.

Т.Г.Миңнуллин әдәбият мәйданына узган гасырның 60 нчы елларында юмористик хикәяләр һәм кечкенә пьесалар белән килеп керә. Аннан соң ул иҗатын зур драматик формаларда дәвам итә. 1962 елда яшь авторның ике пьесасы сәхнәдә куела, алар шунда ук тамашачылар игътибарын җәлеп итә. Минзәлә драма театры сәхнәсендә өч пәрдәлек «Безнең авыл кешеләре» комедиясе күрсәтелә, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында балалар өчен «Азат» пьесасы сәхнәләштерелә. 1967-1969 елларда Әлмәт дәүләт театрында «Күрше кызы» спектакле, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Миләүшәнең туган көне», Татарстанның Республика күчмә театрында (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) «Нигез ташлары» һәм «Йөрәк янарга тиеш» дигән яңа пьесалары сәхнәләштерелгәннән соң, Туфан Миңнуллин әдәби тәнкыйть тарафыннан өлгереп җиткән драматург буларак телгә алына.

Узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларын Туфан Миңнуллинның табигый сәләте бөтен тулылыгы белән ачылган чор дип әйтергә мөмкин. Аның үткен каләменнән илледән артык драма һәм комедия, балалар өчен дистәләгән пьеса һәм әкият төшә. 1963 елдан алып 1999 елга кадәрге чорда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә генә дә Т.Миңнуллинның

26 пьесасы куела. Әлеге спектакльләрнең барысы да диярлек тамашачыларда зур кызыксыну тудыра һәм озын гомерле була. Т.Миңнуллин әсәрләре бүген дә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Әлмәт, Минзәлә һәм Чаллы һөнәри театрлары репертуарында үзәк урынны алып тора.

Авторның аерым әсәрләре, бигрәк тә «Әлдермештән Әлмәндәр» фәлсәфи комедиясе, «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы, «Диләфрүзгә дүрт кияү» водевиле Башкортстан, Мари Иле, Удмуртия, Бурятия, Дагыстан, Осетия, Ичкерия, Казахстан, Кыргызстан һәм Таҗикстан милли театрлары, шулай ук Омск, Воронеж, Әстерхан, Мурманск, Мичурин, Түбән Новгород һәм Новокузнецк рус театрлары сәхнәләрендә зур уңыш белән бара.

Туфан Миңнуллин татар балалар драматургиясен үстерүгә зур өлеш кертте. Аның «Азат», «Гафият турында әкият», «Айга сәяхәт», «Айбулат», «Авыл эте Акбай», «Акбай һәм Сарык малае» һәм башка әкияти пьесалар сериясе, «Иптәш командир!» һәм «Кайда халык, кайда дөреслек?» комедияләре республика курчак һәм драма театрлары репертуарларында мөһим урын алды.

Туфан Миңнуллин — үткен каләмле, принципиаль публицист һәм тәнкыйтьче. Аның «Минһаҗ маҗаралары» сатирик повестьлары сериясе, шулай ук «Татарстан яшьләре» газетасында басылып килгән җәмгыять турындагы язмалары укучылар арасында аеруча популярлык казанды.

Туфан Миңнуллин 1974 елда, «Нигез ташлары» комедиясе һәм «Үзебез сайлаган язмыш» драматик повесте өчен М.Җәлил исемендәге Дәүләт бүләгенә, 1979 елда «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 1979 елда «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен Туфан Миңнуллин, режиссер Марсель Сәлимҗанов һәм төп рольне башкаручы Шәүкәт Бикмимеров Россиянең К.Станиславский исемендәге Дәүләт бүләген алдылар. Театр сәнгатен үстерүдәге аеруча зур өлеше өчен, Т.Миңнуллинга 1978 елда «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе», 1984 елда «Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе», ә 2005 елда «Башкортостан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирелде. 1984 елда ул «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. 2005 елда Т.Миңнуллинга «Татарстан Республикасының Халык язучысы» исеме бирелде. Шул елда ук ул «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде. Т.Миңнуллин — Казан шәһәренең мактаулы гражданы.

1984 елдан алып 1989 елга кадәр Т.Миңнуллин Татарстан Республикасы Язучылар берлегенә җитәкчелек итте. 1997-2008 елларда ул Халыкара ПЕН-клубның Татар ПЕН-үзәге рәисе вазифаларын башкарды. 1984-1989 елларда Т.Миңнуллин Татарстан АССР Югары Советы депутаты, 1989-1991 елларда СССР Югары Советы депутаты булды. 1990 елдан — Татарстан Республикасы Югары Советы депутаты, 1995 елдан — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты.

Бөтен тормышын һәм иҗатын үз халкына багышлаган, гомеренең соңгы минутларына кадәр намуслы граждан позициясеннән тайпылмаган талантлы язучы һәм шәхес арабыздан китте. Туфан Габдулла улы Миңнуллин турындагы якты истәлек йөрәкләребездә мәңге сакланыр.

Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев,
Ф.Х.Мөхәммәтшин, И.Ш.Халиков,
Ю.З.Камалтынов, И.Р.Метшин,
З.Г.Гарәфиев, И.М.Ибраһимов,
Ф.Р.Бикчәнтәев, Р.Ф.Кәлимуллин,
Р.М.Заһидуллин

ТУФАН МИҢНУЛЛИН:
«КЕШЕ БЕЛӘН ЯЗЫЛМАГАН ЗАКОННАР ИДАРӘ ИТӘРГӘ ТИЕШ, АНЫҢ ЭЧКЕ ДӨНЬЯСЫ, АНЫҢ РУХЫ...»

(26 апрельдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының дүртенче чакырылышы, егерме сигезенче утырышында ясалган чыгыш)

Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич! Фәрит Хәйруллович! Хөрмәтле коллегалар! Кунаклар! Кәҗәнең җыры кәбестә турында дигәндәй, минем дә сүзем мәдәният, шуңа бәйле мәсьәләләр турында. Мин бу чыгышка инде күптән әзерләнеп киләм, бүген Илдар Шәфкатович чыгышыннан соң сөйләвем очраклы хәл генә.

Чыннан да, безнең мәдәният турында сөйләр сүзләребез бик күп. Ул аерым тикшерүне таләп итә. Әле күптән түгел генә мин «Семь дней» дигән тапшыруда Рөстәм Нургалиевичның Россия Президенты белән сөйләшеп утырганын тыңладым. Рөстәм Нургалиевичның сүзләреннән, бездә шулкадәр төзелеш барганлыгын, үзгәрешләр барлыгын тыңлап, мин сөенеп, горурланып утырдым. Ахырга таба мин Россия Президентының: «Как у вас, Рустам Нургалиевич, вопросы культуры, строительство объектов культуры?» — дигән соравын көттем. Ул сорау әйтелмәде. Күрәсең, мәдәният бу көндә безнең республикада гына түгел, Россиядә дә бик үк әһәмиятле әйбер түгел. Югыйсә, безнең горурланып әйтерлек сүзләребез дә бар, җитешмәгән якларыбыз да бар. Әгәр дә мондый сорау бирелгән булса, Рөстәм Нургалиевич болай дип җавап биргән булыр иде: «Без Әтнәдә яңа театр ачтык, Татарстан Язучылар берләшмәсен бик әйбәтләп ремонтлап ятабыз». Җитешмәгән яклар буенча да әйтер иде. Без инде менә якынча унбиш еллап Милли китапханә төзү турында уйлыйбыз, әле шушы төзелешне башларга уйлаганыбыз юк, бу безнең киләчәктәге проблемаларыбыз дип өстәр иде. Аннары 500 меңлек Чаллы шәһәрендә театр бинасы юклыгын искәртер иде. Югыйсә, Чаллы шәһәрендә бүген иң кимендә 4-5 театр эшләп торырга тиеш бит. Ул театрның бинасы өчен мин ул районның башлыгы буларак оялыр идем. Гомумән, ул хакта сүз башлауга ук, аның бу көндә нинди шартларда эшләп ятканына мин кызарыр идем.

Икенчесе — Түбән Камадагы театр мәсьәләсе. Без инде «Нефтехим» дибез, горурланабыз, мактанабыз. Ә шунда кеше рәхәтләнеп кереп карарлык, хәзерге вакыт таләпләренә җавап бирерлек театр юк. Әле мин бу өч объект турында сүз уңаеннан гына әйттем. Тирәнрәк уйлап карасак, әйткәнемчә, сөйләшер сүзләр, уйланырлык уйлар бар. Без хәзер культурага бер примитив нәрсәгә караган

кебек кенә карарга керештек. Ә культура бит ул кешенең яшәү рәвеше, аның рухы, иманы. Әгәр дә безнең эчке культурабыз җитми икән, без беркайчан да алдынгы ил, алдынгы милләт була алмаячакбыз.

Әгәр дә без бүген «Дальний» дигән полиция участогы турында сүз алып барабыз икән, без, иң беренче чиратта, моның нигезен табарга тиешбез. Нәрсәдә моның сере? Чөнки кешедәге культура дәрәҗәсе бездә шундый түбән, без инде хәзер күп нәрсәләрне аңламый башладык.

Әле бүген генә мин монда җәмәгать судьясына сорау бирдем. Язылган законнар өстенрәкме, әллә язылмаганнарымы дип. Хәтта ул да җавап бирә алмый, «язылган законнар», ди. Ә бит кеше белән язылмаган законнар идарә итәргә тиеш, аның эчке дөньясы, аның рухы. Менә шушыларны кеше үти алмаган вакытта, шуны үтәргә кешенең сәләте җитмәгән вакытта, законнар языла. Без ул законнарны язарга мәҗбүр булабыз. Менә ни өчен без бу мәсьәләгә кабат-кабат уйлап якын килергә тиеш.

Без бу көндә «Татарстан — спорт республикасы, Казан — спорт башкаласы» дип әйтәбез. Бик әйбәт. Спорт та кирәк. Барысы да кирәк. Әмма дә ләкин бер юнәлештә генә үсү безне мактамый. Сезнең, әйтик, театрдан спектакль карап чыкканнан соң, тамашачыларның җыелып сугышканын ишеткәнегез бармы? Юк. Ә хоккей карагач чыгып сугышалар. Бу нәрсә дигән сүз? Бу сугышучыларның культура дәрәҗәсе бик түбән, алар спортка «неандерталецлар» күзлегеннән генә карыйлар дигән сүз. Ә менә аерым бер кешенең рухи ихтыяҗы буларак карамыйлар. Шуңа күрә без бу әйберләргә аерым игътибар бирергә тиеш.

Культурага примитив карашның тагын бер мисалын гына китерәм. Менә мин «Пусть говорят» дигән тапшыруны карап ятам, анда ниндидер азгынлык турында сүз алып барыла, азып-тузып йөргән бер гаилә турында сөйләнелә. Ул тапшыру турында мин инде бер сүз әйтәсем килми, әмма бер кызыклы сүз. Юрист кеше әйтә: «Сабантуй устроили», — ди. Бу нинди Сабантуй булсын? Кайчан безнең Сабантуйның шундый азгынлык үрнәге булып торганы бар?!

Менә шушы әйберләр безнең сүзләргә дә, терминологиягә дә кереп китте. Безнең дәүләт җитәкчеләре дә еш кына «уничтожим», «мочить будем» дигән сүзләрне куллана башлады. Болар инде дәүләт җитәкчеләренең лексиконында булырга тиешле сүзләр түгел. Бөтен кешеләр белән без кешегә кеше итеп карау турында сөйләшергә тиешбездер.

Безнең культурага кагылган тагын бер зур чара үткәрелә башлады, ул — безнең тарихи истәлекләр. Тарихи истәлекләргә инде соңгы вакытта, бик зурлап, яңарыш дип, Болгар каласын, Зөя кирмәнен керттек, аларны торгызу турында сөйлибез. Ярый, Болгар Болгар инде ул. Безнең Зөя каласын изге урын дип әйтәләр. Биредә бервакыт депутат чыгыш ясаганда, мин әйткән идем: «Ул нинди изге урын булсын? Кем әйтте, кем уйлап чыгарган?» Бу — безнең культурабызның дәрәҗәсен күрсәтә торган мисал. Кеше җирен яулап алыр өчен төзелгән кирмән изге урын була алмый! Крепость, построенная для завоевания чужих земель, никогда не может быть святой! И для победителей, и тем более для побежденных. Мы должны историю знать. К сожалению, сейчас многие уже перестали читать книги. Я вот наблюдаю: на наши спектакли не ходят и депутаты, редко бывают. Я думаю, Фарид Хайруллович, как-нибудь найдем возможность, может быть, это будут парламентские слушания, где будем обсуждать наше духовное состояние. Безнең рухи дөньябыз ни хәлдә? Безнең кеше булып аталырга хакыбыз бармы? Әллә һаман да без артта калган кыргый халыклар булып яшәвебезне дәвам итәрбезме?

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

Бүген бөтен татар халкы үзенең затлы улын, бөек язучысын соңгы юлга озата.

Бу кадәрле сагышлы матәм, мөгаен, моннан 99 ел элек Габдулла Тукайны озатканда гына булгандыр!

Туфан ага Тукай һәм Туфан иҗатына мөкиббән иде. Аңар Тукай турылыгы, Тукай тапкырлыгы, Туфан үҗәтлеге, Туфан олпатлыгы хас иде!!!

Туфан ага Халык язучысы исемен йөрткән әдипләр арасында Халыкка иң якын торган, Халык күңеленең түренә үк кергән әдип иде! Ул моны үзе дә тоя, үзе дә сиземли иде. Халык төшенчәсе аның өчен газизләрдән газиз — татар милләте иде. Ул һәрчакта: «Минем милләтем, минем халкым җир йөзендәге бер генә милләттән дә, бер генә халыктан да өстен түгел, әмма ул бер генә халыктан да түбән дә түгел», — дияр иде.

Ул тагы да: «Татар язучылары холыклары, сәләтләре белән төрледән-төрле, ә милләт ихтыяҗлары дигәндә, алар һәрчак бер уйда, бер теләктә, бердәм», — дияр иде.

Ул тагы да: «Халыкны толпа белән бутарга ярамый», — дияр иде. Баксаң, ул безгә, иң беренче чиратта язучыларга, үзенең иҗат итү мәсләгеннән төшендергән, безне үз иҗаты үрнәгендә халыкның үзаңын үстерергә чакырган, өйрәткән икән бит!!!

Бүген Туфан Ага белән бөтен сәнгать дөньясы хушлаша. Туфан татар әдәбиятына, аның драматургиясенә хакыйкый чынбарлыкны, фәлсәфи чынбарлыкны алып кергән новатор булды. Ул милли драматургиябездә үз мәктәбен булдырды. Ул үзе ярты гасыр буена бөтен бер милләтне, аркадаш милләтләрне театрлы итте.

Ул үзе сәнгатьнең, әдәбиятның бер сурәте иде. Һәм ул үзе иҗат иткән йөзьяшәр Әлмәндәр булып та, самими Минһаҗ булып та, Каһарман Бәхтияр булып та, Тукай, Туфан, Җәлилләрнең образы булып та халык хәтерендә, халык күңелендә яшәячәк, халыкны искәртеп, уяу тотачак!!!

Туфан Ага соңгы елларда Милли әдәбиятыбызга өр-яңа яшь буын килүенә чиксез куанып яшәде. Аларның иҗатын күзәтә иде, аларны барлады, аларны нидәндер кисәтте, аларга үзенең киңәшләрен, фатихасын биреп калдырды.

Без бүген аның белән хушлашабыз.

Очрашканда кул биреп күрешсә дә, ул аерылышканда кулын биреп саубуллашмый иде. Кул биреп саубуллашсаң, озак күрешмисең дия иде…

Бүген олуг остазыбыз белән хушлашканда, барыбыз да аның безнең белән мәңгегә каласын тоябыз ич!!! Бу ышаныч безне, шөкер, кайгы-сагыштан да алып чыгар. Күңелебездә фәкать халкыбызның шундый бөек улы белән горурлану хисләре генә калыр!

Хушыгыз, Туфан ага!

Җаныгыз җәннәттә булсын!!!

Илфак Ибраһимов,
Татарстан Язучылар берлеге рәисе
2.05.2012

«Гүзәл-гашыйк җисемең булган,
Ташка язар исемең булган...»
Гамил Афзал

Чал гасырлар авазы

И ТАШ, СӨЙЛӘ...

Ирек Һадиев,
ТР Милли китапханәсенең фәнни эшләр буенча директор урынбасары
Раиф Мәрданов,
филология фәннәре кандидаты, ТР Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фәнни хезмәткәре

Күренекле тарихчы галим, академик Миркасыйм Госманов бер хезмәтендә әүвәлге кабер ташлары булган татар зиратларын үзенчәлекле «таш архив»лар дип атаган иде. Сүзебез тарихи чыганакларның нәкъ шушы төрен — эпиграфик истәлекләрне (каберташ язмаларын) өйрәнү һәм аларның сакланышын тәэмин итү зарурлыгы турында барачак.

Мәсьәләнең мөһимлеге бернинди дә бәхәс тудырмый. Чөнки, беренчедән, эпиграфик истәлекләрнең, тарихи чыганаклар буларак, фәнни кыйммәте бик зур, икенчедән, милли мирасыбызның бер өлеше булган әлеге истәлекләр елдан-ел кимеп, юкка чыгып бара, өченчедән, киң җәмәгатьчелектә дә аларга карата хөрмәт-ихтирам, сакчыл караш тәрбияләү, «зират культурасы»на өйрәтү зарурлыгы арта бара.

Ташъязмаларның тарихны өйрәнүдәге әһәмияте галимнәр тарафыннан күп мәртәбәләр расланган. Борынгы чорлардан башлап, XX гасыр башына кадәр кабер ташларында вафат булган шәхескә бәйле рәвештә милли тарихыбызның аерым бер фактлары, халыкның мәдәни һәм әхлакый үсеш дәрәҗәсе чагылыш тапкан. Ташъязмалар хәбәр иткән тарихи-документаль мәгълүматлар башка төрле чыганаклардан алынганнарына

бик саллы өстәмә, аерым очракларда эпитафияләр үзләре үк күпкырлы мөстәкыйль чыганаклар рәтенә кертелергә лаек. Халкыбыз тарихын өйрәнүнең кайбер бәхәсле мәсьәләләрен хәл итүдә комплексл ы эпиграфик тикшеренү эшләренең әһәмияте зур.

Татар зиратларында бөтенләй диярлек игътибарга алынмый торган, авып һәм уалып, кыйшаеп һәм җиргә иңеп, ахыр чиктә туфрак астына күмелеп бара торган элекке ташлар, тарихи мирасыбызның аяныч хәленә телсез шаһитлар шикелле, моңаеп торалар. Алар тарихка, шул исәптән әлеге эпиграфик истәлекләргә булган гамьсезлек һәм ваемсызлыкка әрниләр кебек.

Соңгы елларда тарихи мирасыбызның аяныч хәлен, тарих-архитектура истәлекләренә, шул исәптән эпиграфик истәлекләргә игътибарны көчәйтү кирәклеген яктырткан язмалар матбугатта еш күренә. Галимнәребезне, тарихчыларыбызны һәм, гомумән, милләтебезнең зыялы затларын мондый фикерләр электән үк борчыган. Мисалга, күренекле җәмәгать эшлеклесе Шәһәр Шәрәф «Шура» журналында дөнья күргән «Асаре гатыйка» [«Тарихи истәлекләр»] дип исемләнгән мәкаләсендә болай дип яза: «...Бабаларыбыздан калган бу кеби истәлекләрне сакларга вә милли музаханәләрне [музейларны] оештырырга өстебезгә алырга кирәк икәнлеген вә моның файдалары хакында сүз сөйләүне тиеш тә күрмим».

Татар тарихы өчен гомуми әһәмияткә ия булган Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверләренә караган кабер ташлары, тарихи чыганаклар буларак, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдин, Гайнетдин Әхмәрев, Гали Рәхим, Һарун Йосыпов, Фәрит

Салих мирза җәмәгате Мәдинә Йосыф мирза кызы каберенә куелган таш. 1834 ел. Әгерҗе районы Наҗар авылы зираты.

Хаҗи Габделгаффар мулла Габденнасыйр улы каберенә куелган таш. 1889 ел. Әгерҗе районы Салагыш авылының «Чапай зираты».

Ишморад Сәгыйдь улы һәм Шаһиәкбәр Ишморад улы каберләренә куелган ташлар. 1857 һәм 1863 еллар. Кукмара районы Зур Сәрдек авылы зираты.

Хөррәмшаһ хәләле Гөлҗамал Әдһәм кызы каберенә куелган таш. 1866 ел. Кукмара районы Янсыбы авылы зираты.

Хәкимҗанов, Җәмил Мөхәммәтшин, Марсель Әхмәтҗанов кебек галимнәр тарафыннан өйрәнелгәннәр. Ханлыклар дәверенә караган кабер ташлары әле һаман да табыла һәм өйрәнелә тора.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соңгы дәвердәге, ягъни XVI-XVII гасырлардан башлап XX йөз башына кадәрге меңләгән, хәтта дистәләрчә меңләгән татар кабер ташлары гыйльми җәһәттән аз тикшерелгән. Мондый кабер ташларының күпме булуы билгесез, шулай да татар авылларының яртысында ук булмаса, бик күбесендә, электән татарлар яшәгән шәһәр зиратларында мондый ташлар бар. Шушы уңайдан Марсель Әхмәтҗановның 2000 елда дөнья күргән «Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре» китабын телгә алып үтәргә кирәк. Бу хезмәт Әлмәт районына кергән авыллардагы мөселман татар, керәшен, христиан, мәҗүси һ.б. эпиграфик истәлекләрен өйрәнүгә багышланган.

Галим һәм язучы Нурулла Гариф 2010 елда «Казан ханлыгы чоры ташъязмалары» дип аталган бай мәгълүматлы каталог-белешмәлек төзеп нәшер итте.

Төп белгечлеге буенча рәссам-график, Башкортстанның данлыклы Эстәрлебаш ягында туып-үскән милләттәшебез Венер Усманов Эстәрлебашта һәм, гомумән, әлеге төбәктәге татар авылларында, шулай ук Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы авылы зиратларында сакланган XVIII гасыр – XX йөз башы татар эпиграфик истәлекләрен махсус өйрәнеп, йөзләгән ядкәрләрнең текстларын һәм күчереп ясалган график рәсемнәрен берничә китапка туплап нәшер итте. Мисал өчен, аның икенче китабында Каргалы зиратларындагы 368 ташъязма тексты һәм рәсеме урын алган, өченче китабында 468 ташъязма тасвирланган.

Соңгы елларда без фәкыйрьләрегез

— бу мәкалә авторлары — махсус экспедицияләр оештырып, Татарстанның берничә районындагы элекке кабер ташларын комплекслы өйрәнү һәм теркәү эшләрен башкардык.

Борынгы Болгар, Алтын Урда дәверләре, Казан ханлыгы кебек чорлардан калган ташъязмалар гына түгел, ә соңгырак чорларга караган истәлекләрнең дә әһәмияте зур. Фәкать алардагы мәгълүматларны тирәнтен өйрәнергә һәм лаеклы дәрәҗәдә кадерли, саклый белергә кирәк. Моннан йөз яки ике йөз ел элекке ташларны, борынгы түгелләр икән дип, битарафлык күрсәтү дәвам итсә, булганнары да уалып-ватылып юкка чыгып бетәчәк. Югыйсә алар безнең газиз тарихыбыз! Әллә кайчангы борынгылыкны гына эзләп йөреп, якынрак тарихтагы кыйммәтле чыганакларны да кадерсезләсәк, Ходай да кичермәс, киләсе буыннар да гафу итмәсләр! Шуларны фәһемләп без иң башта үзебезнең туган төбәкләребез Әгерҗе һәм Кукмара районнарындагы барлык мөселман татар зиратларын максатчан тикшереп чыктык, булган ташларның текстларын укып, күчереп алдык, фотога төшердек. Шулай ук безнең тарафтан Саба, Алабуга, Менделеев, Балтач районнарының зиратлары тулаем өйрәнелде, Удмуртиянең Можга, Алнаш, Кече Пурга, Кияс һәм Киров өлкәсенең Малмыж, Вятка Аланы, Слободской районнарындагы татар авылларына эпиграфик экспедицияләр үткәрдек.

Мәгълүмат өчен әйтеп үтик, 1998 һәм 1999 елларда Кукмара районына оештырылган фәнни экспедицияләребез нәтиҗәсендә 58 татар авылындагы 284 гарәп язулы кабер ташын өйрәндек. Әгерҗе районындагы 2000 елгы экспедицияләребез дәвамында 48 торак пунктка нисбәтле 226 кабер ташы исәпкә алынды һәм тикшерелде. Саба районын-

Шаһигаллләм исемле кеше каберенә куелган таш. XX гасыр башы. Алабуга районы Илмәт авылы зираты.

Әсфәндияр мулла Гаделшаһ улы Мозаффаров каберенә куелган таш. 1918 ел. Саба районы Казанчы Бигәнәй авылы зираты.

Фаизә Мөхәммәдәмин кызы каберенә куелган таш. 1849 ел. Саба районы Мишәбаш авылы зираты.

Сәүдәгәр Мостафа Муса улы Үтәмешев каберенә куелган таш. 1841 ел. Кукмара районының Мәчкәрә авылы зираты.

да исә 1994, 2001, 2002, 2004 елларда 62 авылдагы зиратларда гарәп язулы 218 ташъязма, Балтач районының 47 авылында 1997, 2001, 2002, 2006, 2007, 2008 елларда 214 ташъязма өйрәнелде. Борынгырак дәверләрдәгеләрен генә карасак, Саба районында Алтын Урда чорына караган бер таш һәм Казан ханлыгы дәвереңең моңарчы галимнәр тарафыннан өйрәнелмәгән ике ташын ачыкладык. XVII гасыр эпиграфик истәлекләреннән Кукмара районында биш, Әгерҗе районында тугыз таш өйрәнелде. Боларның кайберләре турында галимнәргә билгеле булса да, алар фәнни әйләнешкә кертелмәгән иде. Шул ук вакытта татар галимнәреннән Һ.Йосыпов һәм М.Әхмәтҗанов 1950-1970 елларда күргән борынгы дүрт ташның хәзергәчә сакланмаган булуы да ачыкланды. XIX гасыр һәм XX гасыр башындагы күренекле мәгърифәтчеләрнең, тарихта исемнәре билгеле башка шәхесләрнең ташъязма истәлекләре дә табылды. Болар турында тәфсилләп язылган махсус мәкаләләребез булганга күрә, монда киңәеп тукталмыйбыз. Менделеев һәм Алабуга районнарындагы татар авылларын да шушы ук максатта тикшерү ниятебезне, Аллага шөкер, гамәлгә ашырдык. Шушы ике райондагы татар зиратларын өйрәнү өчен 2004-2005 елларда берничә сәфәр-экспедиция оештырдык. Нәтиҗәдә, Алабуга районының 10 торак пунктындагы 407, Менделеев районының 13 торак пунктында 147 гарәп язулы ташъязма истәлек өйрәнелде. Шунысы игътибарга лаеклы, без өйрәнгән төбәкләр арасында Алабуга районы, татар авыллары исәбе буенча башкалардан калышса да, ташъязма истәлекләрнең саны ягыннан (барлыгы 407) иң беренче урында тора. Бу ике районда без өйрәнгән ташларның иң искеләре XVII гасырга карый, XVIII гасыр ташлары берәү дә юк,

аннан соңгылары XIX гасыр (күпчелеге гасырның икенче яртысыныкы) белән XX гасырның башына нисбәтлеләр.

Элекке дәверләрдән алып, 1920 елларга кадәр булган гарәп язулы барлык ташлар да (1920-1930 елларда куелганнары, фәнни әһәмиятләренә карап, сайланма рәвештә) безнең тарафтан исәпкә алынды, алардагы язмалар укылды һәм күчерелде, ташларның үлчәмнәре билгеләнде һәм ташлар үзләре фоторәсемгә төшерелде. Кызганычка каршы, ташларның сакланышы төрлечә. Элеккерәкләре генә түгел, XX гасыр башында куелган кайбер ташларның да кеше исеме һәм елы кебек фактик мәгълүмат язылган өлешләре ватылган яисә хәрефләре коелып-уалып беткән.

Үз тәҗрибәбездән чыгып шуны раслый алабыз: республикабыздагы һәр татар авылының зиратын тулаем, тәфсилләп тикшерү ысулы кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Эш уңайлыгы өчен без аларны хәзерге административ район чикләрендә өйрәнәбез. Гәрчә элекке төбәкара багланышлар (шул исәптән, эпиграфик чыганакларның үзенчәлекләре ягыннан карагаңда да) хәзерге район чикләре белән тәңгәл килми, һәм бу мөмкин дә түгел. Мәсәлән, шул ук Менделеев районындагы күпчелек авылларның тарихи үткәне Әгерҗе төбәге һәм Кама аръягы авыллары белән тыгыз бәйләнгән булса, Алабуга районындагы татарларның, нигездә, Мамадыш һәм Кукмара яклары халкы белән тарихи уртаклыклары күп. Өйрәнелгән ташъязма истәлекләр шушы төбәкләрдәге авыллар тарихы өчен кыйммәтле материал булып тора.

Мәгълүматларны йомгаклап шуны әйтик: Кукмара, Әгерҗе, Саба, Алабуга, Менделеев, Балтач районнарында урнашкан 238 торак пункттагы 1496 эпитафик истәлек өйрәнелгән икән — бу инде зур нәтиҗә, һәрхәлдә, табигый таушалу сәбәбеннән дә, адәм баласы үзе уйлап чыгарган ясалма афәтләр һәм игътибарсызлык аркасында да елдан-ел юкка чыгып, мәңгелеккә бетә баруларын исәпкә алганда, бигрәк тә мөһим нәтиҗә. Югыйсә 30-40 еллар элек кенә галимнәр күргән борынгы ташлардан кайберләренең хәзер әсәре дә юк. Шулай ук, соңгы елларда КамГЭСның су биеклеген күтәртергә җыену сәбәпле, берничә ел элек кенә Әгерҗе төбәгендә без күреп өйрәнгән 163 таш су төбенә олактырылырга тора. Ә борынгыдан татар авыллары урнашкан Ык һәм Агыйдел буйларындагы өйрәнелмәгән ташъязмаларның күпмесе су астында калачак?! Шулай итеп, ташка язылган татар тарихының йөзләгән нөсхәсе мәңгелеккә югала бара.

Үзебез өйрәнгән һәр төбәктәге эпиграфик истәлекләрнең фоторәсемнәрен һәм текстларын биреп, аерым китапҗыентыклар итеп бастырып халыкка җиткерү — эшебезнең башында ук күздә тотылган төп максат иде. Кыенлыкларга карамастан (мөмкинлекләре булган район хакимиятләре дә бу изге гамәлнең чыгымнарын үз өсләренә алырга ашыкмыйлар), әлеге максат тормышка ашып килә, «Татар эпиграфикасы» сериясеннән «Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре» дигән беренче китапны 2008 елда укучыларга тәкъдим иттек.

Мондый китаплар тәэсире белән күпләр үз кан-кардәшләренең кабер ташларын зиратлардан табып, тирәсен чистартып, ташын төзәтебрәк куяр, ихластан багышлап догасын кылыр. Туган-тумачасы булмаса да, тарихи ядкәрләрнең кадер һәм кыйммәтләрен аңлап, киләсе буыннарга да уалмыйча-ватылмыйча ирешүен хәстәрләр. Һәрхәлдә, без шундый теләктә һәм өметтә булдык. Арабызда игелекле

затлар бар бит, әүвәлге тарихи ташларны җил-давылдан, ватылудан саклауның менә дигән бер мисалын Менделеевск районының Песәй авылы зиратында күрдек. Анда XVII гасыр кабер ташына тимер-калайдан кием ясап кигерткәннәр. Уңайлы да, җиңел дә. Кирәк чагында күтәреп кенә ачасың. Чын-чынлап иманлы, ата-баба тарихын хөрмәт иткән зирәк милләттәшләребез моны үрнәк итеп тә алырлар, башкачарак ысулларын да кулланырлар әле.

Бу китаптан үзләренең нәселдәшләрен, элеккеге әби-бабаларының исемнәрен, ташларының рәсемнәрен табып куанучылар булыр. Андый бәхетле бәндәләр белән без дә бергә сөенәбез, тырышып эшләгән хезмәтебез бушка китмәгәнлеген тоябыз. Уртак шатлыкларыбыз китапта исемнәре искә алынган һәркемнең рухларына изге дога булып ирешсә иде.

Комплексլы тикшеренүләр татар зиратларында тарихи әһәмияткә ия әүвәлге кабер ташларының шактый күп санда сакланганлыгын күрсәтә. Кызганыч ки, әлеге биниһая мөһим чыганакларны, искиткеч кыйммәтле рухи-мәдәни мирасыбыз ядкәрләрен өйрәнүчеләр республикабыз галимнәре арасында санаулы гына.

Төбәк тарихлары белән кызыксынучы кайберәүләр, кабер ташларындагы даталар һиҗри ел исәбендә күрсәтелгәнлекне аңламыйча, ялгышлар да җибәргәлиләр. Мәсәлән, XIX гасыр ахырында куелган, һиҗри (мөселман календаре) буенча 1300 ел дип күрсәтелгән ташның датасын гамәлдәге милади ел исәбе белән бутап, ягъни аны XIV гасыр башына нисбәт итеп хаталаналар.

Кайбер авылларда зираттагы кабер ташларының иң әүвәлгесе XIX гасыр башында куелганлыгын белгәч, сөмсерләре коелучылар да бар. Нәрсә инде ул XIX гасыр, янәсе, менә XIV—XVI гасырлар булсын иде ул, дип әйтүчеләр очрый. Андыйлары юк дип, игътибарсызлык, битарафлык кылганда, табигый, болары да сакланмаска, җуелырга мөмкин. Шуны истә тотарга иде. Тарихыбызның һәр дәверенә: ерактагысына да, якындагысына да бер төрле ихтирамлы вә игътибарлы мөнәсәбәт булырга тиеш.

Гомумән, халкыбыз борынгылыкны бик тә сөя, шул сәбәпле, тарих төшенчәсен фиргавеннәр, ул гына да түгел, мамонтлар чоры белән тиңләп карарга ярата. Гәрчә XX гасыр башы да, безнең кичәге көнебез дә тарих бит. Мамонт кебек эре хайван сөякләре табылганга «аһ» иткән хәлдә, үз бабаларыңның, авылдашларыңның, нәселеңнең 100-150 ел элек үткәндәге тарихларына битарафлык күрсәтү, һич тә дөрес гамәл түгел.

Гарәп язулары белән чуарланган, гасырлар аша кичкән борынгы ташлар татарлар яшәгән һәр төбәктә, һәр авыл зиратында бар. Әмма, ни аяныч, алар вакытлар үтү белән уалып, авып, җиргә сеңеп, язулары коелып, мәңге кайтара алмаслык хәлдә тарих мәйданыннан юкка чыгып баралар. Шагыйрь әйтмешли, «...исә җилләр, бетә эз». Ташъязма истәлекләрне кичектермичә барлау, өйрәнү, мөмкинлек булганда, юкка чыгудан саклау — изге бурычларның берсе. Чөнки бу кабер ташларында бабаларыбызның газиз исемнәре уелган. Һәркемнең күңелендә иман, беренче нәүбәттә, ата-бабаларның изге рухларына ихтирамнан башлана. Һәммәбез халкыбызның, нәсел-нәсәпләребезнең, авылдаш һәм төбәктәшләребезнең исемнәрен һәм гамәлләрен белергә, өйрәнергә һәм күңелләрдә сакларга тиешбез.

Тарихыбызның кыйммәтле чыганакларына карата яшәп килгән мөнәсәбәткә мисал итеп Казан шәһәренең Яңа Бистә зиратын гына китерик. Җанны

өшетерлек әхлаксызлык күренешләре аз түгел монда. Элек кабер булган урында яңадан кабер казу, аны югары бәягә сату үзе үк әхлаксызлыкның зур бер чагылышы ләбаса. Борынгы кабер ташларын вату, сындыру, урыннарыннан алып ташлау, өсләренә чүп-чар өю кебек төрлечә мәсхәрәләүләр дә җитәрлек. Эшләр шулай барса, бу ташларга, кайчандыр шушы кабер ияләренә укыган кебек, җеназа укырга гына кала. Казан элек тә, хәзер дә бу өлкәдә үз өлешен кертеп килә — дистәләгән, йөзләгән ташлары булган татар зиратларының берсе — XVIII йөзгә караганы, инде күптән асфальт астында, Киров районындагы тагын берсе — Идел сулары белән юылып бетеп бара, шул ук райондагы икенчесе — элекке Пороховой бистәсенең хәзерге «Рамазан» мәчете янәшәсендәге зираты яңа төзелешләр белән һәрьяклап кысрыклана һәм бик начар хәлдә тотыла.

Төбәк һәм авыллардагы әүвәлге кабер ташларының да сакланышы мактанырлык түгел. Мәсәлән, Саба районы Кече һәм Олы Шыңар авылларындагы Казан ханлыгы дәвере ташларының, Казанчы Бигәнәйдәге «Ишан каберлеге»нең бүгенге торыш-халәте, Сабай зиратында Гыйльман Яхин ташының берничә кисәккә ватылып ятуы күңелләрдә борчу тудыра. Олы Арташның иске зиратындагы ялгыз таш та онытылып, караусыз калып югалмасмы, дип хафаланабыз.

Татарстан Республикасындагы зиратларны гизгәндә куандыргыч та, көендергеч тә хәлләр күп очрый. Бик күп авылларда зиратларны чистарту, коймаларны төзекләндерү белән мәшгуль кешеләр очрап сөендерсә, кайбер зиратларда төсле металлдан ясалган койма баганаларын җыеп киткәнлекләрен күреп, хәйран калырлык. Моннан да түбән вәхшилек була микән? Республикабызда бик яхшы тәртиптә тотыла торган, бик чиста һәм пөхтә зиратлар бар. Әмма кайбер зиратларга әле игътибар җитеп бетмәгәнлеге дә күренә, сизелә. Зиратлар бит — ата-бабаларыбыз җирләнгән һәм һәммәбез барачак изге йорт. Халкыбызның гадәтендә булган әхлак, пакьлек һәм сафлык зиратларда да чагылсын, мәрхүмнәрнең җаннары әрнемәсен, рухлары шат булсын иде.

Бер яки берничә дистә ел элек язулары укырлык хәлдә булып, төз басып торган кабер ташларының хәзерге көндә бөтенләй юкка чыгуын яисә сынып, ватылып ятуын күрү, таш өслегендәге язулар ашалу белән бергә тарихи хәтернең дә юкка чыга баруын аңлау, зират коймаларын җимерү һәм ташъязма истәлекләрне бозу очраклары турында ишетү-белү, ниһаять, ата-бабалар, туганнар, авылдашлар җирләнгән зираткаберлекләрнең бөтенләй каралмавы, чистартылмавы кебек әхлаксызлык күренешләренә елдан-ел ешрак шаһит булу йөрәкләрне сыкрата. Фәнни яктан караганда да, бәһасез мәгълүматлар тупланган бу төр тарихи чыганакларның һаман да игътибардан читтәрәк булуы бик кызганыч. Шуңа күрә, авылларда-шәһәрләрдә яшәүчеләргә, җирле хакимият вәкилләренә, дин әһелләренә, мәчетләргә йөрүчеләргә, мәктәп укучыларына мөрәҗәгать итәбез. Әйдәгез, зиратларны, каберләрне чистартып, койма-чардуганнарын төзәтеп, аеруча кадерле ташъязмаларның өсләренә түбәләр ясап, сынган-аерылган кисәкләрен үзара беркетеп, ауган-кыйшайганнарын турайтып яки башка юллар белән бер, ике гасыр, хәтта биш йөз елга якын торган истәлекләрнең гомерен тагын күп елларга озайтыйк! Бу фани дөньяга килеп киткәннәр дә бездән разый булсын, киләчәк буыннар алдында да йөзебез ак, күңелебез чиста торсын!

Мөхәммәт Мирза

***

Скифлар – ерак бабайлар,
шанлы тарих арбасыннан
барыбер төшеп калганнар…
Ике дистә гасырдан соң
оныклары сабак алсын
дип әйтеп ниләр кыласың:
таралганнар, югалганнар?..

Болгарлар – ерак бабайлар,
тагын сибелеп беткәннәр…
Шул хәленә төшүләрен
кемнәрдер бик тә көткәннәр…
Янып ауган шәһәрләрнең
көлләрен җилләр сипкәннәр…
Сәбәбен кем төшенгәндер?..

Казан ауганда бабайлар
бүлгәләнеп кырылганнар…
Казан-суның ярлары да
оешкан кан тутыгына
буылып гел тыгылганнар…
Биләгән тау, дала, кырда
өелеп калган курганнар?..

Гасырларның аръягыннан
саркып тора сагышлы моң:
искәртә ул, кисәтә ул…
Дөньяның шул куласасы
кинәт әйләнеп басарын…
Оныкларга әманәте –
Сакларга татар ыстанын…



«…Заман безгә җаваплылык өйде
Бүгенгесе, киләчәге өчен,
Әллә кайчан үткән өчен дә…»

Гамил Афзал

Мөнбәр

КОЛ ШӘРИФ МӘЧЕТЕ – ЯҢАРЫШ СИМВОЛЫ

Динара Әхмәтова,
КФУның «Darelfөnүn» газетасы хәбәрчесе



«Халкыбызның гасырлар буе күңел түрендә йөргән иң изге хыялы тормышка ашты. Без барыбыз да бу дулкынландыргыч вакыйганың шаһитлары: Кол Шәриф мәчете халкыбыз хозурына кире кайтарылды. 450 елдан артык вакыт узганнан соң, тарихның өзелер-өзелмәс җебен ялгап җибәрү һәм аны мәңгеләштерү бәхете нәкъ менә сезнең белән безгә насыйп булды. Бу гамәлебез белән үзебезнең горур, таза рухлы халык икәнлегебезне тулысынча расладык», — дигән сүзләр әйтте беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев Кол Шәриф мәчетен ачу тантанасында ясаган чыгышында. Бу көнгә дә 7 ел вакыт узган.

1996 елның февралендә, Татарстан Республикасы Президентының «Казан Кремле ансамблен саклау, үстерү һәм файдалану концепциясе турында» Указы нигезендә Кол Шәриф мәчете төзеләчәк урынга истәлекле төстә таш салына. Ачу тантанасы Казаныбызның меңьеллыгына туры килү дә очраклы хәл түгел. Моннан 100 еллар элек Кол Шәриф мәчете Казан ханлыгы башкаласын бизәп, үзенең мәһабәтлеге, матурлыгы һәм милли хәзинәсе белән бар кешене сокландырып тора. Мәчетнең атамасы соңгы имамы булган шагыйрь һәм дипломат Кол Шәриф исеме белән бәйле. Изге йорт Казанга Явыз Иван гаскәрләре һөҗүм иткән вакытта шәһәрнең бу өлешен саклауда зур таяныч була. Шул вакыт аларга каршы сәет Кол Шәриф башлыгында дин әһелләре һәм шәкертләр чыга. Һөҗүм итүчеләрнең беренче дулкынын кырып бетерсәләр дә, көчләр тигез булмый. «Мин яу кырын ташлап кача торган кеше түгелмен», — дип язган каһарман һәм гомеренең соңгы мизгелләренә кадәр үз мәчетен яклап, яу кырында ятып калган.

Тарихчы-галим Шиһабетдин Мәрҗанинең хезмәтләрендә Казан шәһәре кирмәнендәге сигез манаралы мәчет турында кыска белешмә бар. Ләкин анда мәчетнең исеме әйтелми. Кол Шәриф мәчетенең серләрен аеруча нигезле итеп 1920-1930 елларда тарихчы Михаил Худяков, ә 1990 елларда архитектура белгечләре Сәйяр Ситдыйк улы Айдаров һәм Нияз Хаҗи улы Халитов өйрәнә.

Кол Шәриф мәчете Казан Кремле ишегалдының көнбатыш өлешендә симметрик композиция ясап урнашкан. Бина, мөселман дөньясына таныш булган, «Аллаһы Тәгаләнең иминлеген белдергән», 45° почмак ясап кисешкән ике дүртпочмаклыктан гыйбарәт. Диварлары исә бер-берсе белән кисешкән сигез уксыман аркалы, ян-якларына Коръән аятьләре уеп язылган һәм орнаменталь толым рәвешен барлыкка китергән бизәкләрдән тора. Диварга төсле пыяладан бизәп ясалган биек уксыман тәрәзәләр уелган. Хасил булган пространство сигез улак рәвешен хәтерләткән түбә белән ябылган.

Корылманың үзәк өлешендәге биеклеге, идәннән алып гөмбәз төбәсенә кадәр 36 м тәшкил итә. Гөмбәзгә лалә чәчәге формасындагы тәрәзәләр уелган. Әлеге форма «Казан таҗы»н күз уңында тотып эшләнгән. Мәчетнең икенче каты, түгәрәк колонналар ярдәмендә беркетелеп, керү өлешенә кадәр китерелгән.

Мәчет үзәге өлешенең дүрт почмагыннан биеклеге 55 метрга кадәр җиткән дүрт төп манара күтәрелә. Мәчеттә шулай ук ике кечкенә һәм моннан тыш үзәк ишекнең ике ягында ике манара урнаштырылган. XVI гасыр Хан Кремле территориясендә балкыган тарихи Кол Шәриф мәчетенеке кебек үк, бүгенге мәчетнең манараларына да сигез ай куелган.

Корылма үзе биш каттан, катлар арасындагы ярдәмче һәм техник мәйданчыклардан тора. Ирләрнең һәм хатын-кызларның гыйбадәт кылу урыннары, тәһарәтханәләр дини кануннарга туры китереп эшләнгән.

Эчке бизәлешкә килгәндә, келәмнәр — Иран дәүләтенең махсус бүләге. Авырлыгы 2 тонна, ә диаметры 5 метрга җиткән төсле бәллүрдән булган люстра Чехиядә эшләнгән. Төсләр серлелегенә ия булган витражлар уеп ясалган челтәрле яки алтыннан эшләнгән бизәкләр — барысы да мәчеткә купшылык, мәһабәтлек кенә өсти. Детальләр,



орнаментлар белән эшләнгән гөмбәзгә әйләнәсе буенча гарәп хәрефләре белән Аллаһы Тәгаләнең исемнәре язылган. Архитектур-сәнгати бизәлеше (архитекторы А.Г.Саттаров) биредәге йолаларга, гореф-гадәтләргә якынайтып эшләнгән. Мәчет эчендә (төп залның уң һәм сул якларында) экскурсияләр өчен махсус балконнар каралган.

Мәчет комплексы үз эченә мәчет бинасын, нәшрият үзәген, музей-китапханә һәм имамның идарә бүлмәләрен ала. Мәчетнең төп залында мәчет төзелешенә акчалата ярдәм иткән хәйриячеләрнең исемнәре язылган китаплар урнаштырылган. Ә мәчетне чын мәгънәсендә халык төзеде, дип әйтергә була, чөнки әлеге изге эштән бер генә кеше дә читтә калмый. Бу залда шулай ук дөньяның төрле телләрендә дөнья күргән Коръән басмалары да урын алган. Еш кына беренче катта борынгы мөселман сәнгатен

— шамаилләрне язучы рәссамнарның күргәзмәләре оештырыла. Аны гыйбадәт кылу үзәге дип атау дөрес булмас. Ул мәдәни-агарту комплексы һәм фәнни үзәк тә булып тора. Аның составына Идел буе ислам мәдәнияте музее, фәнни тикшеренү эше алып барыла торган Борынгы кулъязмалар музее, китапханә керә. Мәчетнең ишекләре иманга омтылучы һәр кеше өчен ачык.

Шушы гүзәллекне тудыручы кешеләр быел Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләген алды. 8 кешелек коллектив (И.Ф.Сәйфуллин, С.П.Шәкүров, А.В.Головин, З.М.Садыйков, А.Г.Саттаров, А.К.Даишева, З.Ш.Галиуллин, Р.М.Зәбиров) әлеге дәрәҗәле исемгә икенче тапкыр тәкъдим ителгәннән соң ия булды. Кандидатлар арасында бердәнбер җиңүче соңгы тапкыр 2004 елда була. Җиңү яулаган коллектив әгъзалары арасында рәссам Леутин Александр Петр улы булмау — зур хата, дип саныйм. Милләте буенча рус булса да, ул татар милли орнаментларын тирәнтен өйрәнеп, мәчетне төзүдә зур эш башкара. Аның эскизларында геометрик һәм үсемлек орнаментлары чиратлаша. Түшәмгә аятьләрне язу өчен хәтта конкурс та игълан ителә. Төрек эшчеләреннән өстен чыккан Александр Леутин язмаларны башта киндер тукымага төшерә, аннары түшәмгә ябыштыра. Борынгы изге йортлардагы барлык язуларны да шулай төшерә торган булганнар.

«Казан Кремле» музей-тыюлыгының баш архитекторы Рөстәм Мөхәммәт улы Зәбиров: «Безнең эшне Европа дәрәҗәсендә күптән таныдылар инде. Үзебезнең республикада күрмәүләре күңелне тырнап тора иде», — ди. Казан инженер-төзү институтының (хәзер — КДАТУ) архитектура факультетын тәмамлаган Рөстәм абый 2 дистә елга якын музей-тыюлыкта баш архитектор вазифасын башкара. Кремльдәге барлык реставрацияләү эше аның күз алдында, үз катнашында уза. Кол Шәриф мәчетен төзүдә дә иң төп рольләрнең берсен башкара ул. Корылманың сәнгати төзелеш мәсьәләләрен чишүдә катнаша. Интерьер, агач эшләнмәләре өчен җавап бирә. Әлеге авыр-уникаль объектны төзү вакытында бик күп дөрес чишелешләр кабул итәргә, һәр туган проблеманы уңай якка чишү юлларын эзләргә кирәк. «Авырлыклар беренче көннән үк килеп чыкты, чөнки мәчетнең урыны бик проблемалы иде. Аның урыны тигез түгел. Шуңа башта монолит тимербетонлы плита куярга туры килде. Гомумән, бинаның конструкциясе бик катлаулы. Кисешә торган аркаларны эшләү өчен, хәтта махсус макет ясалды, чөнки подрядчылар сызымнар буенча гына аңлый алмады. Эшчеләрне төрек компаниясе җибәрде, ул вакытта Казанда андый осталар юк иде», — ди баш архитектор. Ләкин нинди генә кыенлыклар чыкса да, «карташ» яуса да, эш иң югары дәрҗәдә башкарыла.

Бүген инде Кол Шәриф мәчете Кремльгә, Казаныбызның тарихи үзәгенә, туган илебезгә, гомумән, бөтен мөселман дөньясына иман нуры сибеп тора торган яңарыш символы буларак балкый.

БОЛГАР

Әхмәт Рәшит

Сәер иде ул җыр.
Чорлар кичеп
Исән калган иске төрбәдә
Бик кисәктән генә башланды ул,
Гөмбәзләрдә иңри — тирбәлә.
Акустика монда әйбәт, дигәч,
Безнең белән килгән җырчы кыз
Борынгыдан истәлеккә калган
Бер җыр сузды…
Сузды…
Син дә суз…
Синең җыр ул, Болгар,
Синең кыз ул —
Шул ук аваз, шул моң, шул җисем…
Тик замана гына биргән аңа
Әллә кайдан килгән ят исем.
Хәер, анысы гаҗәпмени инде —
Кемдер, әнә, онытып барысын,
Карамзиннар, Аксаковлар булып,
Матурайткан Рәсәй тарихын.
Матурайтса, әйдә, матурайтсын,
Бу мизгелгә азрак тынып тор;
Үткәннәрдән бер кайтаваз булып
Яңгырый, әнә, яңгырый милли җыр.
Онытылган гамьнәр… Ә ул җырлый,
Җырлый гүя миллион тавыштан —
Илаһи бер рәхәт иңә җанга,
Йөрәккә кан сава сагыштан.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ
(2012 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕН
БИРҮ ТУРЫНДА)

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимен карап, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгең, «Кол Шәриф мәчете» архитектура комплексын иҗат иткән өчен, Зөфәр Шәйдулла улы Галиуллин, Андрей Вячеславович Головин, Альбина Кен кызы Даишева, Рөстәм Мөхәммәд улы Зәбиров, Зөфәр Мазһар улы Садыйков, Искәндәр Фуад улы Сәйфуллин, Айвар Гомәр улы Саттаров, Сергей Петрович Шәкүров составындагы коллективка бирергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н.МИҢНЕХАНОВ

Казан, Кремль
2012 ел, 25 апрель